№ 3 2018

ТҮГӘРӘК УЕН

ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫН ЯКТЫРТУЧЫ МӘГЪЛҮМАТИ-ПОПУЛЯР АЛЬМАНАХ

Энҗе бөртекләре мени, –
Күргән кеше хәйран калыр.
Үткәннәрне киләчәккә
Бу балалар ялгый алыр.

Равил Заһидуллин.
«Сабан туе. Көрәш.»
2014 ел. Киндер, майлы буяу.

Илсөяр ИКСАНОВА

Татар көрәше

Сабантуйның төп бәйгесе – көрәш.
Кыл шикелле һава тартылган, –
Бөтен халык бердәм өнсез калып,
Сулышын да ала бер тыннан.

Берләштергән,
укмаштырган көрәш, –
Монда бөтен мәйдан хөкемдар.
Бөек Гаделлекне саклый шулай, –
Уч төбендә кебек батырлар.

Хәрәмләшү, хәйлә коруларны
Бик тиз тотып ала ул халык.
Көрәшәсең икән, гадел көрәш! –
Милләтеңнең йөзен акларлык
Булсын синең һәрбер хәрәкәтең, –
Кыю, тегәл, матур, акыллы.
Бары шулай көрәшкәндә генә
Мәйдан таный асыл батырны.

Сабантуйның таҗы – милли көрәш.
Бил алышу гына түгел ул.
Карурманнар кичкән чакларда да
Кара ягылмаган күңел ул!

№ 3 2018

ТУГӘРӘК УЕН

Татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах

*«Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул,
моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул»*

16+

Гамәлгә куючылар:

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгы каршындагы
Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге

Редколлегия:

Әхмәтҗанов М.И.
Бакиров М.Х.
Вәлиева З.Р.
Вәлиев Р.И.
Гайсин И.З. (Мари Эл)
Деникаева В.А. (Ульян)
Заһидуллина Д.Ф.
Каюмова Э.Р.
Локманов А.Х. (Башкортостан)
Сибагатуллин А.М.
Тукаев М.Р.
Шәрәфиева Р.Г.
Юсупов Ф.Ю.

Директор: **Фәнзилә Җәүһәрева**

Баш мөхәррир: **Илсөяр Иксанова**

Альманахның иҗат төркеме:

Гөлсинә Хәмидуллина
Алсу Тимергалина
Раилә Хәялиева
Мөнирә Кузиева

Альманах 2014 елның 5 августында элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр даирәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсендә (Роскомнадзор) теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77-58939. Өч айга бер чыга.

Бу санны бизәүдә Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге фондындагы, Расыйх Фәсхетдинов, Илнар Хәнипов, Р. Хәялиева һәм авторларның шәхси архивларындагы фотолар файдаланылды.

Кәгазь форматы 60х90[1]/[8]. Күләме 8 басма табак.
Басарга кул куелды 06.08.2018 ел. Заказ Е-1963.
Тираж 1050 экз.

Редакциянең адресы: 420021, Казан, Тукай урамы, 74 а.
Хатлар язар өчен адрес:
420015, Казан, Пушкин урамы 66/33 йорт.
Телефон: 293-27-99. E-mail: tugarakuen@mail.ru

«ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Казан, Декабристлар ур., 2.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.
Күчереп басканда, «Түгәрәк уен»нан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

КАЗЫНГАН – КАЗНА ТАБАР

4 **Фестиваль**
Илсөяр Иксанова, Гөлсинә Хәмидуллина, Раилә Хәялиева
Кайту: «Түгәрәк уен» – 2018

17 **Шәхес**
Илдус Илдарханов
Чабаталы

19 *Николай Җөриле*
Тырлау аланында бәйрәм

22 **Фольклор туган җирдә**
Илсөяр Гарипова, Гөлсинә Хәмидуллина
Теләчедә бер көн

© «Түгәрәк уен», 2018

34

Раилә Сабирова
Кичке уенга чыгабызмы, ә?..

38

Им-том Раилә Хәялиева
Сүзләре хикмәтле, куллары сихәтле

41 **Вакыт көзгесе**
Сәвия Галиева
Искедә казынсаң, яңаны белерсең...

44 **Тарихын белмәгән халык – тамырсыз агач**
Гали Рәхим
Борынгы төрекләрдә дөньяга караш һәм халык әдәбияты

КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

48
Мәҗит Рафиков
Йомышчы Әбубәкер, яки «ни булса, ни була»

52

Кайтаваз
Нажия Гыймадиева
«Ал яулык, зәңгәр шәл...»

58 *Эльмира Шәрифуллина*
Дөнья өзгән безнең лә араны...

УЕНДА ЖИҢГӘН – ЖЫЕНДА ЖИҢӘР

60

Без, без, без идек...
Зәбәрҗәт
Сөйкемле шүрәле кайда яши?

64

Өй күрке – аш
Энҗе Садыйкова
Нурлатча тутырган тавык

Кайту: «Түгәрәк уен» – 2018

«Түгәрәк уен» Бөтенроссия татар фольклоры фестивале, ун елдан соң, үзенең «туган җиренә» – Ульян өлкәсенең тулаем дип әйтерлек татарлардан торган районына – Иске Кулаткыга әйләнеп кайтты. Әмма бу – гади генә кайту түгел: дистә ел арасында Россиянең төрле төбәкләрендә узган (Төмән, Екатеринбург, Пермь, Самара, Казан, Мари Эл, Кырым, Казан…) һәм һәрберсенең онытылмас үз йөзе, яшәеше-сулышы булган фестивальләрдән соң үсеп, ишәеп, көчәеп-ныгып, чарланып кайту иде.

«Мин сиңа иректем, Кулаткы!..»

Июнь ае ахырында, моннан нәкъ ун ел элеккечә, Иске Кулаткы бистәсенең механика-технология техникумы урнашкан тавына Россиянең 23 төбәгеннән килгән 500дән артык татар кешесе аяк басты. Тау өстеннән торып, аста җәелеп яткан бистә урамнарына, әле анда, әле монда балкып торган нәфис мәчет манараларына карап соклангында күпләрнең күңелендә, мөгаен, тәүге фестивальдә отып киткән җөмлә яңаргандыр: «Мин сиңа иректем, Кулаткы!» Хатирәләр, очрашу шатлыгы, яңа килгән коллективлар белән танышу… – әнә шул хисләр дулкынында халык фестивальнең ачылышына әзерләнә башлады. Һәм, озак та үтми, 500 дән артык кешене берләштергән колонна, күз камаштыргыч төсләр белән балкып, гармуннар уйнап, үзәккә юл алды… Иске Кулаткы районы башлыгы Эдуард Әнвәр улы Ганеев һәм башка рәсми затлар, Казаннан килгән жюри әгъзалары катнашындагы ачылыш тантанасыннан соң фестиваль үзенең җентекләп әзерләнгән программасы белән эшли башлады.



Алдан ук шуны әйтеп кую кирәк, дистә еллык юбилей дип сүз алып барсак та, фестивальнең тарихын төгәл ун елга чигенеп кенә яза башлау дөреслеккә туры килмәс иде.

«2004–2006 елларда, Татар фольклорын өйрәнү, туплау, җыйнау дәүләт үзәге, Бөтендөнья Татар конгрессы Башкарма комитеты белән берлектә, халкыбызның рухи мирасын туплап, аны үзенә кайтару юлларын барлауга багышланган түгәрәк өстәлләр, фәнни-гамәли конференцияләр үткәрде. Нәтиҗәдә, Россия күләмендә татар фольклор фестивале үткәрү зарурияте турындагы фикер туды. Әмма аны кайда, ни рәвешле, кемнәр ярдәме белән оештыру турындагы сораулар җавапсыз кала иде, – ди Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге директоры Фәнзилә Хәким кызы Җәүһәрева. – 2007 елда язмыш мине, шушы Иске Кулатки җирендә, әлеге төбәктә туыпүскән искиткеч акыллы, зирәк милләтпәрвәр зат – Эдуард Әнвәр улы Ганеев белән очраштырды. Аның белән әңгәмәләребез вакытында милләтне, телебезне, халкыбызның рухын саклап калуда Бөтенроссия фольклор фестиваленең бик тә үтемле чара булачагы турындагы фикер тагын да ныгыды. «Фестиваль Ульян өлкәсенең Иске Кулатки районында башланып китәргә тиеш, барлык чыгымнарны үзем күтәрәм, ә эчтәлеген бергәләп уйлап бетерегез. Әмма шуны истә тотыгыз: фестивальдә халык рухы бик көчле булырга тиеш, бер тапкыр фестивальгә килеп эләккән татар анда гел катнашу хыялы белән янарга тиеш. Фестиваль рухы һәр катнашучының төбәгенә, шәһәренә, авылына барып җитәрлек булсын!» – диде Эдуард әфәнде. Ул вакытлардан соң дистә ел узган да киткән! Шунысы куанычлы, бүген без Эдуард Әнвәр улы алдыбызга

Иске Кулаткы районы башлыгы Эдуард Әнвәр улы Ганеев кунакларны сәламли.

Казаннан килгән рәсми затлар: Бөтендөнья Татар конгрессы Башкарма комитетының аппарат җитәкчесе Артур Валерьевич Мендруль һәм Бөтендөнья Татар конгрессының «Милли шура» рәисе Васил Габделгаяз улы Шәйхразиев.

Казан, себер, кырым, әстерхан, урал, пермь (кый) татарлары, мишәрләр, керәшеннәр, нагайбәкләр, типтәрләр... без – төрле этник төркемнәрдән торган бүленмәс, зур бер халык!

куйган бурычларның байтагын үтәдек дип әйтә алабыз. Фестивальдә катнашырга теләк белдергән төбәкләрнең, катнашучы милләттәшләрнең саны елдан-ел арта, катнашучылар арасында яшьләр – балалар һәм үсмерләр күбәя бара. Нәкъ менә фестиваль кысаларында барлыкка килеп, аның йөзек кашына әйләнгән коллективлар – «Шытыр-шатыр» (Төмән өлкәсе), «Гүзәл Чулман» (Пермь крае), «Асылъяр» (Удмуртия Республикасы) һәм башкалар бүген инде үз төбәкләрендә генә түгел, алардан читтә дә танылу яулауга ирештеләр (мисал итеп «Шытыр-шатыр»ның Италиядә узган халыкара фольклор фестивалендә Гран-при яулап кайтуын әйтү дә җитә). Нәкъ менә шушы фестиваль нигезендә дөньяга «Түгәрәк уен» татар мәгълүмати-популяр журналы аваз салу шулай ук гаять сөенечле күренеш. Бүгенгә көндә татар фольклоры хәрәкәте җанланганнан-җанлана бара. Татарстанда эшләп килүче фольклор коллективларын барлап торучы «Иске Казан Түгәрәк уены», Себер татарларының «Төмән Түгәрәк уены» оешу да әлеге зур хәрәкәтнең ачык күрсәткечләре».

Фестивальнең үсеше турында сөйләгәндә, беренче «Түгәрәк уен»да Гран-при яулаган коллектив – Свердловск өлкәсенең Түбән Сырга районы Аракай авылындагы данлыклы «Сардария» халык фольклор ансамбле (җитәкчесе Салават Гобәев) турында әйтеп үтми мөмкин түгел. «Түгәрәк уен»ның дәрәҗә-кимәле нинди булырга тиешлеген нәкъ менә алар күрсәтте, алар билгеләп китте бит ул чакта. Моннан 100 еллар элек тегелгән каюлы күлмәкләрдәге, алъяпкычлардагы күз камаштыргыч орнаментлар, берсеннән-берсе сөйкемле солист әбиләр, бабайлар, шулай ук яшьләрдән торган 80 (!) кешелек ансамбльнең авыз гармунына сәхнәдә шулкадәр дә табигый рәвештә тере сурәт-бизәкләр үреп Кичке уен уйнавы жюрины да, тамашачыны да өнсез иткән иде. Фольклорны әле үзешчән сәнгатьтән аерып та бетерә алмаган коллективлар өчен чын мәгънәсендә осталык дәресе булды «Сардария»нең чыгышы.

Тәүге фестивальгә үзенең бай иҗат биографиясе белән килеп кергән «Ак каен» халык фольклор ансамбле дә (Самара өлкәсенең Камышлы районы, Иске Ярмәк авылы, җитәкчесе Наил Галимуллин) дистә ел дәвамында үрнәк коллективларның берсе булып кала килә. «Саз» фольклор коллективы (Төмән өлкәсенең Урта Тарман авылы, җитәкчесе Екатерина Әхмәтҗанова), «Наза» фольклор ансамбле (Омск өлкәсенең Большеречье районы, Үләнкүл авылы, җитәкчесе Нәҗибә Щербагина), «Тамаша» фольклор ансамбле (Төмән өлкәсенең Ялутор районы, Аслана авылы, җитәкчесе Ильяс Бакиев), «Ләйсән» фольклор ансамбле (Чиләбе өлкәсенең Нязепетровский районы, Арслан авылы, җитәкчесе Роза Мөхәрәмова), «Чишмә» фольклор ансамбле (Оренбург өлкәсенең Әсәкәй район Мәдәният йорты, җитәкчесе Зәйтүнә Вәлишина) һәм башкалар – үзләре эзләп тапкан җирле материалга нигезләнгән чыгышлары белән фестивальнең унъеллык тарихына кабатланмас сәхифәләр өстәгән әлеге фидакарьләр барысы да олы ихтирамга лаек.

2015 елда фестивальгә кырым татарларының килеп кушылуы исә, географиябезне киңәйтү белән бергә, татар тарихының, татар фольклорының яңа катламнарын ачып салды.

Килдем, күрдем, яраттым...

Быел фестивальдә беренче тапкыр катнашучы коллективлар белән аралашканда безне аеруча ул якларда бүгенге көндә татар мәдәниятенең торышы, туган телебезнең язмышы кызыксындырды. Сер түгел, бу – иң авырткан җиребез. Волгоград өлкәсенең Сведлоярск районы Кече Чапурники авылыннан килгән «Туган як» татар мәдәни-этнография үзәге җитәкчесе Сальфира Назимовна Рябова сүзен авыл тарихыннан башлады.

– Авылыбыз бик борынгы, – диде ул. – Документларга караганда, 1786 елда Царицынодан Кавказ линиясенә кадәр почта юлы төзегәндә патшабикә Екатерина II тарафыннан Пенза, Казан якларыннан күчереп утыртылган татарлар нигез салганнар. Сазлыклы урыннар булган монда. Шунда йөргән соры челәннәрне (чапура) күреп, авылга Чапурники дип исем биргәннәр. Ике мәчетле зур авыл булган ул заманында, совет вакытында бер мәчетне сүтеп алып киткәннәр. Икенче мәчетебез, Аллага шөкер, бүген дә эшли, авыл халкы гына түгел, күрше-тирәдән, бигрәк тә Янтыктан күпләп киләләр.

Гаҗәп хәл, сугыш вакытында авыл тулысынча диярлек җимерелеп беткәндә дә мәчеткә бер бомба да эләкмәгән. 1942 елның 8 августында безнең авыл тирәсендә бик каты сугыш булган, бөтен ызбалар җимерелеп беткән, клуб бинасы, бер байдан калган кирпеч ызба һәм мәчет кенә калган.

Бүгенге көндә авылда 900ләп кеше яши, тулысынча татар авылы дип әйтергә мөмкин, башка халыклар бер процент кына. «Туган як» үзәгебез эшли башлаганга быел 15 ел була. Музеебыз да бар, анда Татар йорты, Сугышчан дан залы эшли. Аны Шәрипов

В.Г.Шәйхразиев белән Иске Кулаткы районы башлыгы урынбасары В.А.Деникаева Сабан туенда хезмәт батырларын котлый.

«Түгәрәк уен» үстерә, күңелне баета, халыкка таныта...

Шакир Касыйм улы оештырган иде, кызганыч, 3 ел элек фаҗигале төстә һәлак булды. Хәзер музейны да үзем җитәклим. Үзәктә шулай ук «Туган як» хатын-кызлар вокаль төркеме, «Тамчы» балалар ансамбле, «Дуслык» триосы эшли. Хәлдән килгәнчә татар җырын-биюен өйрәнәбез. Шунысы бик кыен, авылда бер гармунчы да юк. Балаларга туган телебезне өйрәтү өчен «Ял түгәрәге» оештырдык, ул икенче ел эшли. Мәктәптә рус телендә генә белем алгач, рус арасында яшәгәч, туган телне өйрәнү өчен балаларга мохит юк. Кыенлыклар күп: һөнәри белемле татар теле укытучыбыз юк, үзебез ничек булдырабыз, шулай тырышабыз инде. Үзебез тырышмасак, безнең өчен беркем дә эшләмәячәк.

«Түгәрәк уен»нан бик канәгать булып, киләчәккә зур планнар белән кайтабыз. Фестивальгә ничек тә балаларны алып киләсе, аларга мондагы рухны тапшырасы иде!

Волгоград өлкәсе сәнгаткярләренең баянисты булып килгән егет – Шамил Камил улы Шәрипов өчен «Түгәрәк уен» чын мәгънәсендә ачыш булды. Шамил үзе запастагы хәрби, Волгоградта яши. Хәрби профессия сайласа да, бөтен күңелешеннән мәдәни рух бөркелеп тора.

– Бирегә аяк басканнан бирле, «Ник без бу «Түгәрәк уен» турында 10 ел элек белмәдек икән?!» – дип ачынып йөрим, – дип сөйләп китте ул. – Шулкадәр зур югалту бу безнең өчен! Берни ишетми яшәдек бит! Мондагы халыкка, мондагы тантаналы рухка сокланып туя алмыйм. «Мин дә шушы бөек халыкның бер улы бит!» дигән олы хис күңелемдә... Инде әллә никадәр кеше белән танышып, аралашып өлгердем.

Мин Кече Чапурникида туып-үстем. Бик музыкаль гаиләдә: әтием гармунда, мандолинада уйный, әнием бик матур итеп җырлый иде. Үзе татар теле укытучысы иде. Без, балалар, кайсыбыз Мәскәүдә, кайсыбыз Санкт-Петербургта, барыбыз да музыкаль белем алдык. Кечкенәбез консерватория тәмамлады. Өйдә 15 төрле музыка уен коралы бар, гаиләбез белән бөтен мәдәни чараларда катнаша идек.

Запаска чыккач, Кече Чапурникига барып, «Туган як» татар мәдәни-этнография үзәгенә аккомпаниатор буларак ярдәм итә башладым. Хатыным Зөлфия татар үзәгендәге балаларга татар теле укыта. Гаиләдә татарча сөйләшергә тырышабыз.

Безнең проблема – балаларны, яшьләрне татар мәдәниятенә якынайту өчен методик әсбаплар юк, белгечләр ярдәменә бик мохтаҗбыз. Тирә-якта татар авыллары бар, эзләнсәң, аларда күпме мәдәни мирас табарга булыр иде! Инде күпмесе югалган, онытылган... Ничек итеп эзләнүләр алып барырга, нәрсәдән башларга – менә шуларны аңлату, өйрәтү өчен Казаннан белгечләр китерәсе иде... Дөрес, без үзебез дә нидер эшләргә тырышабыз, Сабан туе бәйрәме, кичәләр оештырабыз. 2016 елда безнең Сабан туебызга Татарстан Президенты да килеп китте. Мин бу фестивальдән үзем өчен бик күп ачышлар ясап китәм. Дуслар табып, адреслар алмашып. Алга таба эшләр өчен маяклар билгеләп.

Курган өлкәсенең Сафакул районы, Карасу авылыннан килгән Эльза Дамир кызы Ризванова:

– Безнең ата-бабаларыбыз кайчандыр Идел буйларыннан килеп утырган булырга

тиеш. Авылыбызның исеме авыл уртасындагы күлдән алынган. Борынгылар бу тирәгә килеп чыкканда күл тирәли каеннар үсеп утырган. Шул каеннарның шәүләсе төшеп торганга, күлнең суы кара төстә булып күренгән.

Безнең авылда 1989 елда «Ак каен» фольклор коллективы оеша. Аны Мәдәният йорты директоры Халит абый Мөхәммәдьянов оештыра һәм җитәкчесе дә була. Бу абый инде вафат. Бүгенге коллективны 10 елдан артык мин җитәклим. Ул башлыча хатын-кызлардан тора. Репертуарыбыз Сафакүл районында яшәгән татарлар арасында йөреп үзебез җыйнаган җырлардан гыйбарәт. Шул ук вакытта, фольклорчы галим Фәрит Юсуповның «Сафакүл татарлары» җыентыгыннан да күп мәгълүмат алабыз. Безнең төбәктә яшәүче халык иҗаты үрнәкләрен җыеп кире халыкка кайтарган олы галимебезгә без чиксез рәхмәтле!

Мәдәният йортында балалар коллективыбыз да бар. Сигез бала йөри. Кызганычка, авылда мәктәбебез ябылды. Югыйсә, 400 кеше яши торган эре генә авыл Карасуыбыз. Балалар күрше авылга йөреп укыйлар. Анда татар теле дәресләре дә укытыла, шөкер. Телне саклау өчен бик тырышабыз, шуңа күрә мәдәни чараларда да балаларны актив катнаштырабыз.

«Түгәрәк уен» фестивалендә беренче катнашуыбыз. Узган ел миңа Татар конгрессы корылтае кысаларында Казанда узган фестивальне күрү бәхете тигән иде. Кремль буйлап сузылып киткән мәйданчыкларда шау-гөр килгән халыкны, аларның җырлы-биюле уеннарын күреп, төрле-төрле музыка уен коралы аһәңнәрен тыңлап исем китте ул чакта! Һәм үзебезнең коллективны да фестивальгә алып килү хыялы белән яна башладым. Әлеге хыялым Өлкә татар конгрессы җитәкчесе Морат Равил улы Юнысов булышлыгы белән чынга ашты. Моңа кадәр Курган, Чиләбе өлкәләреннән ары чыгып йөргәнебез юк иде. Офыкларыбыз киңәеп китә бу фестивальдән. Тагын-тагын килергә язсын иде!

Башкортостанның Дүртөйле районыннан килгән «Хәзинә» тальянчылар ансамбле һәм Янавыл районыннан килгән «Чулпан» фольклор коллективларының да фестивальдә беренче тапкыр катнашулары иде. «Түгәрәк уен»ның рухына шулкадәр кереп киттеләр, таңга кадәр дәвам иткән Кичке уеннарның үзәгендә кайнадылар алар. Шик юк, алдагы фестивальләрдә катнашу хокукын яулар өчен, үз җирлекләрендәге фольклор материалларын җентекләп өйрәнәчәкләр хәзер.

Тырышлык әҗере

Үзенең бөтен гомерен татар мәдәниятенә багышлаган музыкант, бүгенге көндә Йошкар-Олада Республика татар мәдәни үзәгендә хезмәт куючы Гәрәй Мәгъсүмҗановның онытылып барган уен коралыбыз – татар гөсләсен торгызып, гөсләчеләр ансамбле оештыруы, үз куллары белән гөсләләр ясый башлавы турында язган идек инде (№1, 2018). Быел, фестивальнең юбилей елында, Гәрәй әфәнденең үз куллары белән ясаган гөсләсен махсус приз-бүләк итеп әзерләве искиткеч күркәм гамәл иде. Бу уникаль бүләккә Татарстанның Алексеевск районыннан килгән «Бәрәнҗәр» халык фольклор коллективы лаек булды.

Эдуард Әнвәр улы Ганеев тарафыннан һәр фестивальдә тапшырылып килгән

бүләкләргә – бу төбәкне дөньяга танытҡан атаклы ишан Хәбибулла Хансөяров һәм танылган шагыйрь Сәгыйть Сүнчәләй исемендәге призларга – быел «Герой-патриот» дигән махсус приз да өстәлгән иде. Әлеге бүләк Иске Кулаткы районы Вязовый Гай авылында туып-үскән, 2016 елда Сириядә батырларча һәлак булган якташлары, Россия Герое Рәфәгать Хәбибуллин истәлеген мәңгеләштерү максатыннан булдырылган. Бүләк Самара өлкәсе Камышлы районы Иске Ярмәк авылының танылган «Ак каен» фольклор халык ансамбленә тапшырылды. Фестиваль кысаларында концертлар белән авылларга чыкканда, без геройның туган авылында да булып кайттык.

Бөтендөнья Татар Конгрессы Башкарма комитетының махсус бүләге – тальян гармун быел хуҗаларга – Иске Кулаткы район Мәдәният йортының «Чишмә» ансамбленә эләкте. Кырым Республикасының Бахчасарай районыннан килгән «Илһам» бию коллективы да махсус бүләк алып китте.

Төп номинацияләрдә җиңүчеләрне акчалата премияләр белән, ә «Татар халкының традицияләрен саклаган өчен» дигән махсус бүләккә лаек булучыларны бик матур агач сандыклар белән бүләкләделәр.

Сабан туенда «Түгәрәк уен»

Быелгы «Түгәрәк уен»ның бер үзенчәлеге – Гала-концерт Сабан туе кысаларында, бәйрәм мәйданында узды. Шулай итеп, Сабантуй кунаклары бөтен Россиядән җыелган иң яхшы фольклор коллективларының чыгышын карап, гаҗәеп киң татар дөньясы белән дә танышу мөмкинлегенә ия булдылар.

– «Түгәрәк уен» Бөтенроссия татар фольклоры фестивале, уникаль этномәдәни проект буларак, татар халык мәдәниятенең күп гасырларны эченә алган катламнарын ачарга ярдәм итә, – диде Эдуард Әнвәр улы Ганеев. – Әлеге фестивальнең масштаблары елдан-ел киңәя бара. Без бу чараны эчтәлекле һәм мавыктыргыч итеп үткәрү өчен бик зур тырышлык куйдык. Без «Түгәрәк уен»ны тагын 10 елдан соң да кабул итәргә әзербез! Иске Кулаткы җире үзенең бәрәкәтле туфрагы, динебезгә, милли гореф-гадәтләребезгә тугры булган эш сөючән халкы белән аерылып тора. Кирәк булганда җиң сызганып эшкә тотына торган, кирәксә, матур итеп ял оештыра, күңел ача белгән халык яши бездә. Җәмгыять нинди генә сәяси кыйблаларга таба атласа да, яшәешнең нигезе булып хезмәт кала.

Район башлыгының сүзләренә дәлилне Сабан туе мәйданына килеп кергәч тә күрдек. Һәр авыл җирлеге берсеннән-берсе матур агач йорт-ихаталар корып куйган. Мәйданга үткәнче әлеге ишегаллары аша узып, бу якларның тормыш-көнкүреше белән шактый гына танышып өлгерергә мөмкин. Без шуларның берсендә туктадык. Ирле-хатынлы Усаевлар безне табынга чакырдылар. Эльмира һәм Рафаэль икесе дә фермерлар, әмма икесе ике җирлектә эшли булып чыкты. Эльмира инде 8 ел Иске Кулаткыда сыер фермасы тота, сөт житештерү белән шөгыльләнә икән. Узган елны чәчүлек җирләр дә алып җибәргән. 70 баш сыер малы, алар янында бозаулары да бар, сөтне май заводына тапшырабыз, диде. Сөтне тапшыру бәясенең түбән булуы турында да сөйләшеп алдык: бензин бәясе 43 сумга

җиткән, бер литр «Волжанка» суы 30 сум торган вакытта, сөтнең литрын18 сумнан алалар. Ә бит аны җитештерү өчен күпме көч, күпме хезмәт куярга кирәк. Шуңа күрә яшьләр авыл хуҗалыгын күтәрәбез дип атлыгып тормый, шәһәргә китү ягын карыйлар да инде. Эльмира белән Рафаэльнең бердәнбер уллары киләчәктә табиб булырга җыена икән. «Яшьләрне махсус чакырып, фермаларны күрсәтеп, сөйләп тә карыйбыз инде», – ди Рафаэль. Ул үзе 10 ел Мәскәүдә эшләп кайткан да, тапкан акчасына Иске Яндукада җир алып эшкәртә башлаган. «Ташландык хуҗалыкны алды ул, хәзер шуны күтәрә, – дип сүзгә кушылды якташлары. – Инде җимерелеп беткән ферма биналарын торгызып килә». Киләчәктә ит җитештерү белән шөгыльләнергә исәбе бар икән.

Авылларны күтәрергә бүген нәкъ менә шундый булдыклы, җирнең кадерен белгән кешеләр кирәк шул. Бу бит авыл халкына эш урыннары да дигән сүз. Эльмираның фермасында хәзер өч кеше эшли, язгы чорда тагын 5 кеше алабыз, ди. Мәдәни чараларга да матди ярдәм күрсәтүчеләр шул ук фермерлар бит.

Буыннар чылбыры өзелми

Ерак Пермь шәһәреннән килгән «Гүзәл Чулман» ансамбленең туган көне дә фестивальнеке белән тәңгәл килә. «Беренче тапкыр фестивальдә җиде ел элек катнашкан идек, – ди, инде күп еллар «Гүзәл Чулман» ансамбленә йөрүче Мальвина Кадыйрова. – Фестиваль кайда гына узса да көтеп алабыз, бик яратып киләбез. Коллективыбыз бик дус, тату безнең. Монда йөреп, дуслашып гаилә корган дүрт парыбыз бар. Без аларны «Чулман парлары» дип йөртәбез. Узган ел коллективтагы бер яшь гаилә чыгыш ясарга ике айлык балалары белән килгән иде. Быелгы Пермь–Кулаткы юлы 19 сәгатькә сузылды. Ике яшь әни тагын күкрәк баласын алып килде. Берәүнең дә фестивальдән читтә каласы килми, «Түгәрәк уен» безнең өчен зур һәм бик мөһим чара ул! Пермьдәге репетицияләр дә шулай уза безнең, әтиәни биеп йөри, җитәкчебез бала карый. Күптән инде бер гаилә кебек яшибез, туган көннәрдә җыелышабыз. Пермьдә «Чәкчәк» татар яшьләре оешмасы эшләп килә. Бу оешмага йөрүче актив татар яшьләре милли традицияләрне саклап калу һәм татар телен популярлаштыру буенча төрле чаралар оештыра. Пермьдә яшәүче татар яшьләре көннәре, Сабантуйлар үткәрәбез. Тел гаиләдә сакланмаса, аны тышкы чаралар белән белән генә саклап калып булмый ул».

«Гүзәл Чулман» коллективының үзләре яшәгән төбәктәге татарларның фольклорын җыеп, өйрәнеп бүгенге көнгә кайтаруда зур тырышлык күрсәтүләре турында журналыбызда язган идек инде. Быел фестивальгә Чулман кызлары-егетләре Октябрь районы татарларының «Кәтикәт» дип аталган биюен алып килгәннәр иде. Ансамбльнең җитәкчесе Гөлүзә ханым Хәмзина сөйли:

– Пермь өлкәсе Октябрь районы татарлары үзләрен «ботык татарлары» дип атап йөртәләр. Бу якларга экспедициягә барып, әби-бабайлар белән аралашып, аларның бию хәрәкәтләрен бөртекләп видеога төшереп кайттык. Костюмнарын өйрәндек. Мондагы татарлар гомер буе марилар,

руслар белән аралашып яшәгән. Шуңа күрә, ботык татарларының киемнәрендәге бизәкләрдә дә күрше халыклар тәэсире сизеләнә. Биюнең хәрәкәтләре шактый катлаулы, яшьләргә бик тырышырга туры килде. Биюнең көе дә бик үзенчәлекле. Әбиләр безгә ничек күрсәтте, шулай итеп биергә өйрәндек. Гармунда уйнаганда «кәт-кәт-кәт» дигән тавыш ишетелеп тора, шул көйгә аяк тыпырдатып биедек, диләр. Биюнең исемен дә шуңа күрә «Кәтикәт» дип атаганнар. Төрле авылда шушы көйнең төрле вариацияләрен дә ишеттек.

«Түгәрәк уен» балалар өчен дә бер көтеп алган бәйрәмгә, җанлы аралашу мәйданына әйләнә бара. Беренче фестивальдә бердәнбер балалар фольклор коллективы – Түбән Камадан килгән «Нардуган» ансамбле катнашса, алга таба инде елдан-ел аларның саны артып, 2011 елда яшь сәнгаткярләр өчен аерым «Балалар фольклоры» номинациясе дә барлыкка килде. Быел инде, фестивальнең юбилеена, Россиянең төрле өлкәләреннән 12 балалар коллективы килгән иде. Кичке уеннарда да, кара-каршы такмак әйтешкәндә дә, «Түгәрәк уен»ның башка чараларында да балалар бик актив катнашып йөрде. Аларның фестивальдә үзләренең аерым тормышы, үзгә дөньялары гөрләде. Танышулар, аралашулар... Фестивальдә инде берничә ел катнашып килгән балалар бер-берсен белеп, интернет аша аралашып торучы дусларга әверелгән. Биредә алар сагынышып очрашып, рәхәтләнеп аралашалар, төрле тарафларга сибелгән халкыбызның гореф-гадәтләре белән танышып, үзләре өчен яңа дөнья ачып кайтып китәләр.

Гөлфирә Шәмсетдинова җитәкчелегендәге «Биш дус» төркеме (алар әле бер ел элек кенә оешкан) себер татарлары биюен алып килгәннәр иде. Айдар Ниязов, Ларис Тимергалиев, Руслан Нагыйпов, Айдар Сырычев, Илдар Шәмсетдинов – бу малайлар барысы да Тубыл шәһәренең 15нче татар мәктәбендә укый. Татар теле керә, татар әдәбияты укыйбыз, диләр. Мәктәпләрендә себер татарлары тарихына багышланган музей бар икән. Малайлар барысы да татар биюләренә гашыйк. Монда килеп күп дуслар тапканнар.

Фестиваль ачылышында, Кичке уеннарда, гомумән, кайда гына чыгыш ясасалар да, Түмәннән килгән «Шытыр-шатыр» балалар фольклор ансамбле тамашачы өчен чын мәгънәсендә затлы бүләк булды. Борынгы уен коралларыбыз – думбыра, кубыз, курай, дәф, кылкубыз авазлары кемне генә битараф калдырсын ди! Әлеге уен коралларының һәрберсенә ансамбль җитәкчесе Гаяз Габдуллинның кул җылысы сеңгән. «Шытыр-шатыр» себер татарлары көйләренә нигезләнгән композицияне башкарганда каяс (каен тузыннан ясалган савыт) өстендә биеп торган җайдаклы агач атны һәм кыр кәҗәсен генә күрсәгез иде сез! Элек балаларны менә шулай җептән тартып хәрәкәтләндерә торган уенчыклар белән юатканнар.

– Замана шундый бит, балалар татарча авырлык белән сөйләшә. Җырлар өйрәнергә керешкәнче, башта татар авазларының дөрес әйтелешен өйрәнергә туры килә, – ди Гаяз Габдуллин. – Мәктәптә татар теле дәресләре аз, интернетка күп вакыт бирелә. Татар җырлары, уен кораллары аша булса

да балалар күңеленә милли җәүһәрләрне салып калдыра алсак иде, дип тырышабыз. Һәр төбәк татарлары үзләренә генә хас костюмнарында үзләренең фольклор байлыгын күрсәттеләр, җитәкләшеп Кичке уеннарга чыктылар. Балалар да моны күреп, тоеп, күңелләренә салып үзләре белән алып китә бит, менә шунысы аеруча шатландыра.

Чуаш республикасы Комсомол районы Урмай авылыннан килгән «Тамчы» балалар ансамбле (җитәкчесе Илдус Шәйдуллин) фестивальдә тәүге тапкыр катнашты. «Беренче класстан бирле «Тамчы»га йөрибез, бик күп чараларда, фестивальләрдә катнашабыз», – диләр малайлар-кызлар. Төркиядә уза торган «Роза гөлләре» дип исемләнгән фестивальгә барып, татар фольклорын күрсәтеп кайтканнар. Бу төркемдәге балалар үзара чытырдатып татарча сөйләшүләре белән дә аерылып тордылар.

Ижау шәһәреннән килгән «Асылъяр» фольклор төркеме исә (җитәкчесе Лариса Гайнетдинова) «Түгәрәк уен»чыларга яхшы таныш. Кабатланмас чыгышлары белән берничә ел дәвамында тамашачы мәхәббәтен яулап килде алар. Быел исә, «Балага исем кушу» этнографик күренеше белән сәхнәгә чыгып, фестивальнең иң зур бүләге Гран-прига ук лаек булдылар. Аларның чыгышын жюри әгъзасы, Казан мәдәният һәм сәнгать академиясе профессоры Алсу Рәшит кызы Еникеева да югары бәяләде.

– Фольклорны сәхнәгә чыгаргач, кайчак ул музей экспонаты кебек күренә. Китапча сүзләр, ясалма сценарийлар белән эшләгәндә шулай килеп чыга ул. Шуны аңларга кирәк, фольклор бит ул үткән заман күренеше генә түгел, ә үткәннең бүгенге көндә дә дәвамлы булып яңарып торуы, үсештә булуы. «Асылъяр»лар йоланы курчак уенына әйләндереп, бүгенге көндә балалар дөньясында фольклорның ничек яшәгәнен бик оста итеп гәүдәләндерделәр. Балалар үзләренең исемнәрен дә алмаштырмаганнар, уен вакытында заманча исемнәрнең яңгырап китүе бик табигый яңгырады. Гомумән, балалар чыгышларындагы фольклор композицияләре миңа бик ошады. Иске Кулаткы балалар бакчасыннан килеп, быел беренче тапкыр безнең фестивальдә чыгыш ясаган «Гөлчәчәк» балалар төркеме дә бик шатландырды. Киләчәктә дә, ниндидер дөрес формалар табып, балалар фольклорын үстерергә иде.

...Иске Кулаткы туфрагында туган «Түгәрәк уен» дистә ел эчендә гади фестиваль кысаларыннан чыгып, татарны дөньяга танытучы тулы бер фольклор хәрәкәтенә әверелде. Әмма иң элек фестиваль татарны үз-үзенә танытты! Казан, себер, әстерхан, урал, пермь (кый) татарлары, мишәрләр, керәшеннәр, нагайбәкләр, типтәрләр... без төрле этник төркемнәрдән торган бүленмәс, зур бер халык!

Ә киләсе елда без Татарстан туфрагында җыелырбыз...

Илсөяр ИКСАНОВА,
Гөлсинә ХӘМИДУЛЛИНА,
Раилә ХӘЯЛИЕВА

Раилә Хәялиева, Расыйх Фәсхетдинов фотолары.

Сабан туе

Бу елгы Сабан туе башка елларга караганда ныграк нигез өстенә бина кылынганлыктан, узган елларга караганда хәйли[1] гүзәл рәвештә башланды. Сабан туен ясарга иганә итүче кешеләр бу ел биргән акчаларының юкка гына исраф булмаячагын белгәнлекләреннән, чын күңелдән һәм узган елларга караганда артыграк итеп бирделәр.

Сабан туеның идарәсе елдан-ел төрле кулларга күчеп йөргәнлектән, соңгы елларда игътибары беткән, күңел ачарлык манзаралар күрү мөмкин булмаганлыктан, игътибарлырак шәһәр кешеләрендә Сабан туен зиярәт итү[2] арзулары[3] сүнгән иде. Бу елгы Сабан туеның беренче көне хәйли гүзәл үтте. Тамашага килгән халык гаять күп иде.

Ун-унике елдан бирле бу кадәр тамашачы җыелганы юк иде, диләр. Һәм юк та иде. Өченче көн пароход вә көймәләр илә Сабан туена баручыларның һич исәбе вә хисабы булмаган шикелле, коры җирдән атлар илә һәм җәяүләп баручылар да гаять күп иде.

Тамашага тәхминән 5 меңнән зиядәрәк халык җыелган иде. Халык никадәр күп булып, мәйдандагы көрәшләрне күрү һәвәсе илә халыкның бер-берсене издихамга[4] төшереп, тәгъҗиз итү[5] вә кысулары күп булса да, Сабан туе идарәсенең иҗтиһады һәм стражникларның тырышулары саясендә ахырга кадәр көрәш мәйданнары тәртипле барды. Көрәшчеләр өчен мәйдан тарлык кылмады.

Әгәр көннәр дә җылы һәм җилсез булып, халык тузанга батмаса, Сабан туе дәхи дә күңеллерәк үтәчәк иде. Көн матур булса, бәлки тамашачылар дәхи дә күбрәк килгән булырлар иде. Мәйданның гаять тузанлыгы бераз тамашачыларның кәефен җибәрде. Сабан туе мөдирләре бу эшне игътибарга алып, мәйданлык урынына иртәдән су сиптереп, тузанын бастырсалар, яхшы булыр иде.

Мәйданда Бәрәзә авылының Хафизулла исемле егет мәйдан башланганнан ахырга кадәр 52 кешене җыгып батырга калды. Үзенең хәбәренә күрә, мәзкүр егетнең атасы да заманында беренче көрәшчеләрдән булган вә үз гомерендә һичкемгә җыктырмаган, имеш.

Ат мөсабәкаларына[6] 11 кешенең атлары иштирак итеп, Сәлахетдин Фәйзуллинның аты беренче килде.

Йолдыз. – 1910. – 30 май.

Сабан туе

Сабан туеның икенче көнендә, шимбә көн салкын, аның өстенә тузанлы булдыгыннан, көн бик ямьсез иде. Шул сәбәптән, тамашачылар бик аз иде. Мәйдан ярты сәгать кадәр генә дәвам итте. Ул көндә дә Бәрәзә Хафизулла батырга калса да, ләкин аңа каршы хәйли куәтле Рәкыйб чыкты. Җәки авылының Гыйсмәтулла исемле егет беренче көрәшләрендә Хафизулланы янбаш аркылы әйләндереп яхшук матур итеп екты.

Аннан соңгы мәбарәзәләрендә[7] Хафизулла, Рәкыйбның ни рәвешчә көрәшүеннән агяһ[8] булдыгыннан, ихтият илә[9] йөреп күп бирешмәде. Ат мөсабәкаларында әүвәлге көндә беренче килгән Салахетдин Фәйзуллин аты бөйләпме, яхуд башка бер сәбәп иләме, мәйданга бөтенләй килмәдегеннән, Кенәр авылы кешесенең аты беренче мөкяфәтне[10] алды.

Сабан туеның өченче көне якшәмбегә тәсадеф[11] иттегеннән, тамашачыларның яртысы руслардан гыйбарәт иде. Халык беренче көндәге шикелле гаять күп улдыгыннан, мәйданда гаять тыгызлык иде. Көрәшләр дә күбрәк руслар илә мөселманнар арасында булганлыктан, көрәшкә бик әһәмият биреп, көрәшчеләрнең һәрбер хәрәкәтләренә дикъкать итү һәвәсе һәр ике тарафта бик куәтле булдыгыннан, халыкның бер-берсен кысуы беренче көндәгеннән күп артык иде. Шул сәбәптән, ахырга таба мәйдан бик тар иде. Хафизулла бу көндә дә көрәштә беренчелек дәрәҗәсен алды. Ләкин бу көн аңа каршы

Сәрдә авылының Габдулла исемле көрәшче хәйли зур куәтләр күрсәтте. Габдулланың куәте Хафизуллага нисбәтән артык күренсә дә, үзенең осталыгы аркасында, Хафизулла беренче булып калды.

Ат мөсабәкасында да Салахетдин Фәйзуллин аты беренче килде. Ни сәбәпкә мөбнидер, бу көндә Сабан туе идарәсе үзенең програмында күрсәтелгән велосипед һәм көймә узышларын икенче көнгә тәэхир кылды[12]. Көн бик гүзәл, җылы һәм җилсез иде. Су өсте бик һәйбәт булдыгыннан, тамашачыларның бик күбесе Сабан туена көймәләр илә бардылар.

Йолдыз. – 1910. – 1 июнь.

Сабан туе

Сабан туеның дүртенче көне улан дүшәнбе башка көннәргә караганда да парлак сурәттә узды. Халык күп булса да, һичбер төрле тәртипсезлекләр булмады. Әүвәлге көннәрдә халыкның мәйданны кысуыннан гаҗиз булган Сабан туе мөдирләре, иртәдән башлап мәйданның әтрафын агач койма илә ихата кылып, эчке тарафка халык утырырга берничә кат урындыклар тездереп, ишектән дә халыкны бераз интихаб илә[13], аз булса да Сабан туена иганә кылган яхуд кылуы ихтимал булган кешеләрне генә керттеләр. Башка кешеләр койманың тышкы ягыннан торып тамаша кылдылар.

Мәйдан да бик күңелле узып, көрәшләр дә бик тәртипле булды. Мәйданда көрәш ике җирдән булып, бер җирендә милли татар көрәшләре, икенче урында француз көрәшләре дәвам итте. Француз көрәшләрендә Бередихин беренче, Пятницкий икенче, Петров өченче мөкяфәтне алдылар. Пятницкий Ибраһимовны 11 дәкыйкада[14], Дравертный 6 дәкыйкада, Петров Кузьминны 4 дәкыйкада, Ивановны 6 дәкыйкада, Курбатов Марнаутовны 7 дәкыйкада, Бередихин Пятницкийны бер дәкыйкада екты.

Милли көрәшләрдә беренчелекне бу көндә Бәрәзәнең Хафизулла алачак иде, ләкин ахырдан Тихонов нам гаять агыр гәүдәле көрәшчене күтәреп аткан вакытта Тихоновның агырлыгына тәхмил итә алмаенча, аста калып, мәйдан таралды.

Көрәшләрдән башка бу көн балалар һәм зур кешеләрнең җәяүле йөгерешләре илә велосипед һәм ат мөсабәкалары да булды.

Велосипедчылар мәйданлыктан шәһәргә таба китеп, Кабан күлен тәмам әйләнеп, 14 ярым чакрым кадәр мөсафәне катгъ итеп мәйданлыкка килделәр. Мәзкүр мөсафәне А.Г.Кухтин 32 дәкыйкада катгъ итеп беренче мөкяфәтне, Д.Гордеев 33 дәкыйкада катгъ итеп икенче, А.Ю.Дидерхсон 35 дәкыйкада катгъ итеп өченче, Ибраһим Зәйнулла улы 35 ярым дәкыйкада катгъ итеп дүртенче вә Бикчурин 38 дәкыйкада катгъ итеп бишенче мөкяфәтне алдылар. 12 велосипедчыдан бишесе мәйданга килеп җитә алмадылар.

Ат мөсабәкаларында бу көндә Салахетдин Фәйзуллин аты беренче килде. Бу көнге Сабан туе мәҗлесләренә Казандагы мәэмүрләрдән[16] һәм могтәбәр кешеләрдән миһманнар дәгъвәт ителеп, бераз зыяфәт тә хәзерләнмеш иде. Фәхри миһманнардан бу көндә Казанда булганнары һәрберсе килеп, Сабан туеннан бик мәмнүн булып таралдылар.

Хәзергә кадәр онытылып торган икән, туганыннан бирле Сабан туе мәҗлесләренең каһарманы булып йөргән «Сабантуе Гәрәй»гә бу ел башыннан аягына кадәр зәңгәр киемнәр кидерелгән иде. Өстендә зәңгәр постаудан кием, башында зәңгәр фәс иде. Буның хәлфәлекләре дә тамашачыларның хыялый хушына китәдер. Фәхри миһманнар арасындагы зорфадан берсе бу көнге мәҗлестә буңа «Сабантуе пашасы» исемен бирде.

Сабан туеның актык көне җомга көндә велосипед һәм көймә мөсабәкалары вә француз көрәшләре булачактыр.

Йолдыз. – 1910. – 3 июнь.

Басмага Казан (Идел буе) федераль университетының Н. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсенең сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлеге баш библиографы Рәйсә Гамир кызы ШӘРӘФИЕВА әзерләде.

Редакциядән. 1910 елгы Казан Сабан туеннан югарыдагы хәбәрләр «килеп ирешкәннән» соң, көрәшче батыр – Бәрәзә Хафизулласы белән кызыксына башладык. Нәтиҗәдә редакциябезгә әлеге батыр турында бер-бер артлы ике язма килеп керде. Аларны да укучыларыбызга тәкъдим итәбез.

[1]хәйли – шактый, байтак
[2]зиярәт итү – күрү, шунда булу
[3]арзу – теләк
[4]издихам – тыгызлык, күп халык җыены
[5]тәгъҗиз итү – аптырату
[6]мөсабәка – ярышу, узышу
[7]мәбарәзә – кара-каршы сугышу
[8]агяһ – белүче, хәбәрдар
[9]ихтият илә – саклык белән
[10]мөкяфәт – бүләк, приз
[11]тәсадеф – туры килү
[12]тәэхир кылды – кичектерде, соңга калдырды
[13]интихаб илә – сайлап
[14]дәкыйка – минут
[15]катгъ итеп – узып
[16]мәэмүр – чиновник

Бәрәзә Хафиз

«Көрәшче Хафиз җыенга әзерләнә башлаган». Әлеге хәбәр яшен тизлеге белән авылга тарала. Димәк, бер айдан Мәйдан.

Сугыштан соңгы иң хәерче вакытлар. «Юк»-тан башка бер әйбер дә юк. Шулай да Хафиз абый аерым хасияткә куела: ашау-эчү яхшыртыла (ит, май, йомырка эшкә җигелә); тәнне тыгызлатырга, беләкләргә көч җыярга, билне «бирмәслек итеп» ныгытырга кирәк. Ат хәтле гәүдәне сәгатьләр буе көрәштереп батыр калдыру өчен ай-һай ничә сарык түшкәсе кирәк булгандыр! Бу хакта халык арасында чыны-ялганы күп булган: «Бер утырып ашаганда бер бәтине...» һәм башкалар, һәм башкалар – сөйләргә дигәндә безнең Бәрәзәләргә бир инде син, телләренә бер керсәң...

1952-53нче еллар тирәсе. Мин Әтнә районы Олы Бәрәзә мәктәбенең 4нчеме-5нчеме сыйныфында укыйм. Әни ниндидер йомыш белән «Бай күпере» янындагы таш кибеткә төшереп җибәрде. Чатта күрәм: бер бабай әкрен генә атлап Кара Йосыфларга кереп бара. Килеп җиткәч карасам, ишегалдында кап-кара йөзле, гаять зур гәүдәле, озынрак сырма кигән берәү басып тора. Як-ягына карангалап та ала. Таныдым. Хафиз абый икән. Бастырыктай ике кулы җиргә кадәр асылынып төшкән, муенга утыртылып куелган имән бүкәне сыманрак баш түбән иелгән. Кыска аяклары белән ата каз сыманрак бер урында таптанып тора бу.

Мин кибеттән әйләнеп менгәндә күрәм: ул, ишегалдыннан чыгып, урам буйлап атлар-атламас кына түбән төшеп бара. Өйләре шул якта иде.

Бүген бу ике кадрны мин болай аңлыйм: «хәлсез арыслан». Тирә-якны дер селкетеп торган көрәшче. Үзе генә белгән сәләт белән көрәшеп тапкан кызыл малның сукыр бер тиенгә хаҗәте калмаган. Элек эшләпәсен салып исәнләшкән авыл халкының мескенле-мыскыллы карашы... Чүп-чарның сиңа сәлам бирмичә борылып үтеп китүе... Кайда ул элеккеге ашаулар, дастархан тулы нигъмәт?! Ә эчендә берни белән дә алыштыргысыз горурлык!

Дөньясын бушка үткәрүче мескеннәргә ул югарыдан карый. Үлгәч аларны беркем белмәячәк. Ә менә көрәшче Хафиз исеме һәм аның даны калачак. Калачак и баста! Чөнки, 654 йортлы авылда ул берәү генә. Ходай аны аерым яраткан, үгездәй көч-куәт, дәрт-дәрман иңдергән. Төкерә ул үзенең ачлы-туклы йөрүенә. «Бер ашавың – мең яшәвең!» – дигәннәр Бәрәзәдә. Авылда аны кунакка чират торып чакыралар. Муллаларга да эләкми андый хөрмәт!

Аягын көчкә өстерәсә дә, атлый ул әле. Горур атлый! Аның белән «Көрәшче Хафиз» дигән даны да янәшә бара. Үзе китсә дә, ул югалмаячак.

Шулайрак уйлап түбән төшеп бара «карт арыслан». Аның кояшы офыкка кереп бара. «Килгәннәр китәргә тиеш» дигән Гомәр Хәйям. Тик кем ничек китә бит...

Озак еллар Биектау район шифаханәсе баш табибы булган Дәминов Нәүфәл Шакир улының әтисе ягыннан Биктимер бабасы белән Хафиз абыйлар нәселе туган-тумача булган. Сабан туе алдыннан көрәшче Хафиз Битаман егете белән Биктимер бабайларның зур сараенда өрлек аркылы гер ыргытып көч җыйган. Нәүфәлнең әнисе Мәйлүха апай (ул минем әнинең бертуган апасы) Хафиз бабасының бик гыйбрәтле бер сүзен хәтерли: «Берәүне аркасына салу көрәшченең ярты гомерен ала!»

Мәйлүха апа сөйләвенчә, Олы Бәрәзә авылы 1925 елны ике башыннан да кинәт яна башлый. Халык ике якка йөгереп гаҗиз була. Түбән очтагы Хафиз йорты көлгә әйләнә. Бу хәлне ишетеп, Казан байлары әллә кырык, әллә алтмыш обоз текстиль төяп җибәрә. Шул мал бәрабәренә тиз арада көрәшченең бөтен каралты-куралы яңа өе салына.

Ышансаң – ышан, ышанмасаң – юк, дигәндәй, Казан байлары Хафизны хәтта Америкага алып барганнар, имеш. Аның белән көрәшергә кулына тимер шынҗыр тоткан негрны чыгарганнар. Оренбур, Өфе, Сарытау, Әстерхан, Казаннарда җиңгән Бәрәзә Хафиз бу негрны да аркасы белән җиргә шапылдатып куйган.

Казаннарда атналар буе көрәшеп батыр кала алган, циркларда профессионаллар белән тартышкан, Рәсәй буйлап җиңелүне белмичә, Татарстанның беренче чемпионы булган җиңелмәс Хафизны Олы Бәрәзәдә үзен әйләндереп ыргытучы булган бит! Тик монысы икенче кыйсса инде...

Илгиз КАДЫЙРОВ,
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре

Чабаталы батыр

Егерменче гасыр башларында татар дөньясына «Казаннан утыз-кырык чакрымдагы авылларның берсе Бәрәзәдә уналты яшьлек Хафиз атлы егет бик яхшы көрәшә башлаган» дигән хәбәр тарала.

Арча, Әтнә яклары элек-электән көчле, батыр кешеләре белән дан тоткан. Бәрәзә авылы да шул якта. Сабан туйлары җитә башласа, шул якның көрәшергә яраткан таза-таза егетләре Бәрәзәгә җыелалар да, көчләрен тикшерү өчен, Хафизуллалар сараендагы өрлек аша ике потлы герләрне атышып уйныйлар. Шулай итеп, көрәштә бик тә кирәк булган «ыргым» алымын да үзләштерәләр. Көннәр җылыта башлауга һәм кыр эшләре тәмамлануга, яшь батыр, чабышка барасы ат кебек, үзенә тынычлык таба алмый башлый. Ә яшел чирәм өстенә чыгуга, халыкның бөтен игътибары Хафизда. Ул килми торып көрәшне башлау юк.

1912 елда Бәрәзә егете, Казанга барып, атна буе дәвам иткән Сабан туенда күп кенә батырларны бүләксез калдырып, соңгы – ахыргы хәлиткеч очрашуга кадәр җиңелү ачысын татымый. Шул чакта аңа Казандагы атаклы байларның берсе игътибар итә дә егетне үзенә хезмәткә чакыра. Хезмәт дигәне әлләни авырдан булмый тагын – Сабан туйларына бер ай кала Хафизны авылыннан барып алып, яхшы тәрбиягә куялар. Хафизны көрәшкә әзерләргә дип, тагын ике-өч көрәшчене тоталар. Бәрәзә егете Сабан туйларында шул байның данын күтәрү өчен чыгыш ясарга тиеш була.

Бер елны Казан Сабан туена Петербургтагы көрәш батыры килә. Түгәрәк эчендә утырган Хафизны күрсәтеп: «Әнә, безнең иң зур батыр шул була», – диләр аңа. «Чабаталы батыр», – дип көлә теге, Хафизның озын җиңле киндер күлмәгенә, аягындагы чабатасына карап.

Көрәшә башлыйлар. Ярты сәгатьләп йөрсәләр дә, 140 килолы пәһлеван үзеннән 40 килога җиңелрәк Хафизны ега алмый. Бераз ял итеп, яңадан көрәшә башлауга, Хафиз тегене бөтен көченә күтәреп ала да селтәп тә сала. Әлеге алыш нәтиҗәсендә аның ике теше селкенә торган булып кала.

Бай Бәрәзә егетен башка якларга да алып йөри. Ә Сабан туйлары тәмамлангач, авылга Ырынбур, Өфе, Сарытау якларыннан бүләкләр төялгән йөкләр кайта.

Бер елны боларны Хаҗитархан (Әстерхан) Сабан туена чакыралар. Анда Кавказ, Урта Азия якларыннан килгән батырлар җыела. Бик каты көрәшәләр. Бай баштарак Хафизны көрәшкә чыгармый, башкаларның бил алышуларын күзәтеп, чамалап утыра. Ул арда мәйданда «Казан батыры килмәгәнмени?» дигән сүз китә. Бай шуннан соң Хафизга әкрен генә уртага чыгарга куша.

Чыга Хафиз. Берсен сала, икенчесен... Тәгәрәтеп кенә тора чыккан берсен. Бай шуннан соң гына уртага йөгереп керә дә: «Менә ул Казан батыры!» – дип, Хафизның кулын өскә күтәрә. Соңыннан Хафизга: «Әгәр берәрсе екса, каян килгәнебезне дә әйтмичә, шыпырт кына кайтып китә идек», – ди. Ул заманнарда көрәшнең дәрәҗәсе бик югары булган, мәйдан тоткан пәһлеваннарга «фәлән байның батыры» дип, зур хөрмәт белән караганнар.

Хафиз батырның көрәштәге уңышлары революциядән соңгы кумәкләшү, социализм төзү елларында да дәвам итә. Бервакыт аны хәтта Казан циркында профессионаллар арасында оештырылган көрәшләргә дә чакыралар. Тик андагы алдан сөйләшенгән-килешенгән, та-

Әтнәдә 2007 елдан бирле Хафиз батыр истәлегенә яшүсмерләр арасында көрәш бәйгесе үткәрелә.

машачы күңелен күрү өчен генә оештырылган бәйгеләрне үз итә алмый ул, гаиләсе белән аеры-саеры торуны да ошатмыйча, авылына кайтып китә.

Хафиз Бәрәзә турындагы истәлекләр ул якларда бүген дә телдә әле:

– Ул киң күңелле, бик тыныч кеше иде...

– Йөкле аты батса, аңа сукмас, арбаны үзе тартып чыгарыр иде...

– Ике чакрымдагы Атамыш авылы тегермәненә унар потлы бодай капчыгын күтәреп китәр иде дә онга әйләндереп кайтыр иде...

– Кадакны, чүкеч белән түгел, ике потлы гер ташы белән кагар иде...

Берчакны ул базарда бер олау утын алмакчы булган. Ләкин сатучы тегеннән артыграк каермакчы була икән. Сатулашып, килешә алмагач, Хафиз утын сатучыга: «Бер күтәрәм утының бар, шуңа да күпме сорыйсың!» – дигән. Сатучының ачуы чыккан. «Әгәр шушы утынны чанасы белән күтәреп китә алсаң, утын синеке!» – дигән ул. Хафиз шунда атны тугарган да утынны чанасы белән күтәреп китә башлаган. Моны күреп исе киткән сатучы, атын җигеп, утынны Хафизларга бушка илтеп биргән, имеш.

Хафиз батырның «Кемне дә булса егу өчен миңа аны җирдән кәгазь калынлыгы гына күтәрү дә җитә» дигән сүзләрен көрәшчеләр әле дә булса сокланып искә төшерәләр. Аның 1946 елда, инде шактый олы яшьтә чагында да, Дөбъяз районындагы Казаклар авылында батыр калуын күрүчеләр әле дә бар.

Бәрәзә батыры Сабан туйларында гына танылып калмый, спорт тарихына да кереп кала: 1940 елда Казанда ТАССР оешуга 20 ел тулу хөрмәтенә татарча көрәш буенча беренче мәртәбә республика беренчелеге оештырылгач, бу бәйгегә, Арча районы данын якларга дип, 53 яшьлек Хафиз абый Сәхибуллинны да алып киләләр. Һәм ул, авыр үлчәмдәге барлык көндәшләрен дә егып, Чирмешәннән Шаһвәли Исламов, Куйбышев (хәзер – Спас) районыннан Камил Бәдретдинов белән бергә, Татарстанның беренче чемпионы булып тарихка кереп кала.

Бу хәлләрнең шаһиты булган Гаяз абзый Низамиев сөйли:

– Хафиз абый келәтле зур йортын да Сабан туйларыннан көрәшеп алып кайткан бүләкләренә салып керде. Аның гаиләсе авылда 1950-еллар башына кадәр яшәде. Аннары (әтисе Хафизның үлеменнән соң) йөк машинасында эшләүче олы улы Әбрар Казан читендәге Каравай бистәсенә барып урнашты да, Бәрәзәдәге йортны сүтеп, шунда алып киттеләр...

Узган гасырның 20нче елларында шул ук Казан артындагы Дөбъяз дигән районның Олы Битаман авылыннан Шәйдулла атлы тагын бер көрәшче үсеп чыга. 1923 елның июнь аенда, унтугыз яшендә, Казанга барып, биш көн дәвам иткән Сабан туе көрәшендә мәйдан тота.

1928 елның июль аенда Казанда Автономияле республикалар һәм өлкәләр спартакиадасы оештырыла. Җиңүчеләр август башында Мәскәүгә барып, Бөтенсоюз спартакиадасында катнашу хокукы яулый.

Мәскәүдәге спартакиадада, төрле яклардан килгән милли көрәш вәкилләренең бер төрле кагыйдәләргә тиз генә ияләнә алмаулары аркасында милли көрәш буенча рәсми ярыш уздырылмый, күрсәтмә чыгышлар белән генә чикләнергә булалар. 24 яшьлек Шәйдулла Хәйруллинның ул чакта авылга тана алып кайтканлыгын хәтерләүчеләр әле дә бар.

1929-30 елларда язмыш Казан артындагы ике зур батырны – Шәйдулла белән Хафизны очраштыра. Шәйдулланың Бәрәзә авылы аша үтеп барышы була ул. Ә Бәрәзәдә Җыенга әзерләнеп яталар. Егетнең атаклы Хафиз батыр белән көрәшеп карыйсы килә.

Хафиз әллә бәялә п бетерми егетне, әллә кәефсезрәк чагы була – ул Шәйдулланың егып салганын сизми дә кала... Үзенең дәрәҗәсен белә торган көчле, горур Хафиз тарткалашып маташмый. Бары туганнары гына, мондый гарьлеккә түзә алмыйча, бүләген алып юлга кузгалган егетне куа китәләр. Алат янында куып җитеп, кирәген бирмәкче булалар. Егетнең низагка керергә исәбендә дә юк: «Әйдә, тагын көрәшәбез...» – дип кенә тора.

2006 елда 96 яшьлек Фатыйма әби сөйләгәннәргә караганда, алдагы елның Сабан туена Хафиз батыр үзе Битаманга килә һәм анда да Шәйдулла тарафыннан салына, имеш.

Моның өчен Хафизның туганнары Шәйдулланы «акылга утыртмакчы» булалар. Һәм Мәскәүдәге зур тормышны күреп кайткан Шәйдулла, эшкә ялланып, гаиләсе белән Владимир өлкәсенә китеп бара, биш-алты елдан Мәскәүгә күченә. Татарның танылган, таланты әле ачылып та бетмәгән бу батыры 1942 елда яу кырында башын сала.

Хафиз батырга исә 1954 елда авырып Казан сырхауханәсенә киткән җиреннән кире Бәрәзәгә әйләнеп кайтырга насыйп булмый. Ул Казанның Бишбалта зиратында җирләнә.

Илдус ИЛДАРХАНОВ,
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре

Тырлау аланында бәйрәм

Аллы-гөлле чәчәк-такыя кигән кызлар, киптерелгән дару үләннәренең хуш исе, авыздан сулар китереп кайнар табада чыжылдаган тәбикмәкләр, бер минутка да тынып тормаган җыр-бию... Мамадыш районы Җөри авылының Тырлау аланы быел унтугызынчы кат 60 меңләп халыкны Питрау бәйрәменә җыйды.

Питрау көннәре җөрилеләр өчен икеләтә бәйрәм булды быел. Авыл халкы күптән инде яңа Мәдәният йорты турында хыялланa иде, ниһаять, ул хыял чынга ашты. Питрау бәйрәме көнне аны ачу тантанасында республикабыз Премьер-министры Алексей Песошин, якташыбыз, «Ак Барс Холдинг» компаниясе генераль директоры Иван Егоров, районыбыз башлыгы Анатолий Иванов һәм башка кунаклар катнашты. Кунаклар шунда ук урнашкан китапханә белән танышып чыкканнан соң, иркен тамаша залында балалар һәм фольклор ансамбльләре әзерләгән концерт карадылар.

Бәйрәм башланганчы, Тырлау аланына төшә торган гадәтем бар: бу елны нинди үзгәрешләр көтә икән? Быел да иртәрәк аяк киендем. Ел да фольклор коллективлары өчен сыену урыны булган берничә кечкенә өй янәшәсендә әле чи агач исе дә җилләп бетмәгән дистәгә якын яңа бина калкып чыккан. Арада Питрау музее; керәшен хуҗа-

лыкларында файдаланылган эш кораллары, йорт кирәк-яраклары урнаштырылган бина; мунча һәм башкалар Тырлау аланындагы композицияне тагын да баетып җибәргәннәр. Ылыя авылына кадәр сузлыган сәүдә рәтләрендә, төрле аттракционнарда, тематик мәйданчыкларда халык мәш килеп Питрауга әзерләнә.

Тырлау аланына керә торган капка янында мәртәбәле кунакларны ипи-тоз, керәшен пирмәңкәсе һәм... җылы яңгыр белән каршы алдылар. Бәйрәмне котларга гына килеп киткән җәйге яңгыр озак тоткарланмады, кунаклар фольклор коллективлары, уен мәйданчыклары белән танышкан арада үтеп тә китте.

Питрауны тантаналы ачу театральләштерелгән пролог белән башланды. Республикабыз районнарыннан, Башкортостанның – Бакалы, Чиләбе өлкәсенең Нагайбәк районнарыннан килгән фольклор коллективлары да аңарга матур бизәк өстәделәр. Халыкны бәйрәм белән районыбыз башлыгы Анатолий Иванов, Татарстан Республикасы Премьер-министры Алексей Песошин, «Ак Барс Холдинг» компаниясе генераль директоры, Республика керәшеннәренең иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе Иван Егоров, Татарстан Халыклары дуслыгы Ассамблеясы Советы рәисе – Башкарма комитеты җитәкчесе Николай Владимиров, Мамадышның Изге Ксения Римляныни чиркәве настоятеле Владимир атакай, район мөхтәсибе Илһам хәзрәт Миннегалиев тәбрикләде. Премьер-министр Татарстан Республикасы Президенты, Дәүләт Советы һәм Министрлар Кабинеты исеменнән тәбрикләү сүзләрен ирештерде.

Рәсми өлеш тәмамлануга, халык үзе теләгән мәйданчыкларга юл тотты. Үзәк мәйдан янәшәсеннән агучы Ылыя суы өстендә капчык белән сугышучылар, авыш баганадан баручылар, балык тотучылар мәш килә иде. Үзәк мәйдан тирәсендә исә капчык киеп йөгерергә, гер күтәрергә, таяк тартышырга, чүлмәк ватарга, шашка-шахмат уйнарга, йомыркалы кашык кабып йөгерергә, кул көрәштерергә... кыскасы, өч дистәгә якын төрле уеннарда катнашырга теләүчеләрдән озын чиратлар хасил булды. Балалар мәйданчыгы турында әйткән дә юк инде! «Керәшен ишегалды», «Димче почмагы», «Керәшен чибәре», «Яшьләр дискотекасы» мәйданчыклары да шау итеп торды. Теләгән кеше халык уеннарында катнашты, теләгәне, тәкыя үрү, себерке бәйләү серләренә төшенде. Дару үләннәреннән ясалган кайнар чәйләрдән, төрле эчемлекләрдән, милли ашлардан авыз итү дисеңме... җаның ни тели, барысы да бар иде!

Быел Тырлау аланында тәүге мәртәбә пәйда булган Питрау музеена берничә мәртәбә кереп чыгарга туры килде. Кайчан керсәм дә, борын төртерлек тә урын юк: халык зур кызыксыну белән Питрау тарихы турында сөйләүче экспонатлар белән таныша. Аның эчтәлеген баетуда Мамадышның Туган якны өйрәнү музее хезмәткәрләренең хезмәтен бәяләми мөмкин түгел.

– Музейда күргәннәрдән акылымны җыя алмыйча торам. Мондагы экспонатлар Питрауның һәр елы турында шулкадәр тәфсилләп сөйли, – дип соклануын белдерде Саба районының Шекше авылы Мәдәният йорты директоры Ләйсән Хисмәтова.

«Чәчәк бәйрәме»ндә
Чәчәк кебек кызлар.
Куып тоталмасаң,
Йөрәккәең сызлар!

«Кыз куу»лар була
Елга бер кат кына.
Питраулар җитсә
Язмышыңны сына!..

Чиләбе өлкәсе Нагайбәк районының Париж авылыннан килгән Людмила Аранова исә:

– Минем Җәригә икенче тапкыр килүем. Безне юлга чыгып ук каршы алдылар, урнаштырдылар. Тырлау аланында да кадерхөрмәт күрсәтеп кенә тордылар, – дип, рәхмәт хисләрен җиткерде.

Питрауга бәйрәм итәр өчен генә түгел, кавышыр өчен килүчеләр дә бар. Андыйлар өчен «Димче почмагы» эшли. Халык ышануы буенча, мәхәббәт шалашына кергән пар киләчәктә, һичшиксез, бергә була икән. Быелгы Питрауда 18 яшьтән алып 60 яшькәчә булган алты дистәгә якын гүзәл заттан, шул чама ук ир-аттан гариза кабул ителгән. Махсус өстәлдәге ул язмаларны карап, телефон номерларын язып алучыларны үземә дә күрергә туры килде. Карта ачучы ханым янында да озын чират тезелгән иде.

Керәшеннәрдә, бакыр балдаклар белән алмашу, кәбен койдыру кебек, кавышуның үз йолалары да бар. Аңа кадәр, вәгъдә билгесе итеп, яшьләр көзге һәм кульяулык алмашканнар. Егет кызга – көзге, кызлар, җавап итеп, кулъяулык тапшырган. Хәзер, көзге бүләк итәргә ярамый, диләр. Ләкин заманында көзге бик кыйммәтле бүләк саналган, читкә китеп акча эшләп кайткан егетләр генә шундый бүләк ала алган. Бакыр балдаклар бирүнең дә үз сере бар: әлеге металл дәвалау, организмны чистарту көченә ия дип санала. Элек бу көнне болынга төшкән яшьләргә күрше авыллардан килгән егеткызлар белән дә танышу форсаты да чыккан.

2004 елда Питрау программасына килеп кергән «Керәшен чибәре» бәйгесе инде бәйрәмнең чын-чынлап йөзек кашына әверелде. Быел әлеге бәйгедә Татарстаннан – ун, Башкортостан һәм Чиләбе өлкәләреннән берәр сылу катнашты. Кызлар «Дефиле», «Визитка», «Рушник», «Керәшен йолаларын күрсәтү», «Үз төбәк җыруын башкару», «Викторина» номинацияләрендә көч сынаштылар. Жюри әгъзалары сылулар арасыннан иң чибәрен сайлаганда, тамашачылар «Бәрмәнчек» дәүләт керәшен фольклор ансамбле солисты Александр Игнатьев белән аның тутасы, күпсанлы халыкара конкурслар лауреаты Надежданың мини-концертын карарга өлгерделәр. Җиңүчене билгеләү җиңел булмагандыр: катнашучыларның һәркайсы тажга һәм махсус бүләккә лаек булырлык иде шул. Нәтиҗәдә, Питрауның «Керәшен чибәре» исеменә районыбызның Дүсмәт авылы кызы Алиса Исакова лаек булды. Аңа күчмә тажны узган елгы Питрау чибәре Екатерина Максимова тапшырды. Тукай районыннан Эльвина Мефодиева – икенче, Кукмара районыннан Юлия Марышева өченче урынга лаек дип табылдылар.

Татар милли көрәше һәр елны бирегә республикабызның иң көчле көрәшчеләрен җыя. Быел Ульяннан Сергей Павликның, Йошкар-Оладан Муса Галләмовның келәмгә чыгуы исә географиянең киңәя баруын күрсәтте. Алар бүгенге көндә үз авырлыкларында иң көчле спортчылардан саналалар.

Көрәш бәйгеләрендә яшүсмерләр сигез авырлык үлчәү категориясендә, ир-егетләр җиде үлчәүдә көч сынаштылар. Рөстәм Ханов үз яшьтәшләре арасында абсолют батыр исемен яулады. Ир-егетләр арасында барган бәйгеләр иртәнге сәгать өчкә чаклы җанатарларны киеренкелектә тотты. Гадәттә төп призлар автомобиль була торган иде, быел машина урынына акчалата бүләкләр җирәбәдә уйнатылды. Нәтиҗәдә иң югары бүләкләргә Азат Нурмөхәммәтов, Эльвир Ахунҗанов һәм Раил Нургалиев ия булды.

Ә бәйрәмнең иң дулкынландыргыч мәле Питрау учагын кабызу һәм төнге караңгылыкта Тырлау аланы өстен төрле төстәге утларга күмгән фейерверклар булды. Учак тирәли әйлән-бәйләнгә баскан халык уен белән мавыгып, таң атканны сизелми дә калды.

Николай ҖӨРИЛЕ

Автор фотолары.

Илсөяр ГАРИПОВА,
Гөлсинә ХӘМИДУЛЛИНА

Теләчедә бер көн

Теләченең үзәгендә үк урнашкан, тирә-ягындагы таш йортлар арасында сап-сары бүрәнәләре белән балкып торучы музей бинасы үткән-сүткәндә күңелне ымсындырып чакырып торса да, ничектер кереп танышып чыгарга гел җәй килми иде. Теләче районына махсус сәяхәтебезне районның Мәдәният бүлеге җитәкчесе Давыт Солтангәрәй улы Иксанов һәм Мәдәният йортының башкарма директоры Фирдәвес Мансур кызы Нәгыймова белән киңәшкәннән соң, нәкъ менә Туган якны өйрәнү музееннан башларга булдык. Биредә безне музейның директоры Фаягөл Миңнехан кызы Имамиева (фотода уңда) белән фонд сакчысы Эльмира Баттал кызы Хуҗина каршы алды. Беренче соравыбыз керә-керешкә телдән «өзелеп тә төште»:

– Теләчедән кул сузымында гына яткан Олы Нырсы, Карабаян, Кибәхуҗа (Олы, Югары, Кече) һәм башка авылларның тарихы Казан ханлыгы чорыннан ук мәгълүм. Ә Теләченең үзәгендәге аллеяда куелган һәйкәлташта бу торак-авылга нигез салыну елы дип 1560 ел күрсәтелгән.

– Әлеге дата Теләчегә урыс дворяны Василий Богданов килеп утырган елга нисбәтле куелган, – дип сөйләп китте Фаягөл ханым. – Казан ханлыгы урыс дәүләте тарафыннан яуланганнан соң, бирегә бик күп урыс алпавытлары, алар белән бергә, Муром, Арзамас, Түбән Новгород һәм башка өлкәләрдән күп санда урыс крестьяннары килеп утырган. Алар татар авылларында (бу тирәдә угро-финнар да күп яшәгән) һәм урыс чирүе килгәндә татарлар ташлап киткән авылларда урнашканнар. 1560 дигән дата бүген күпләр тарафыннан кире кагыла. Районның тарихын җентекләп өйрәнәсе бар әле. Шөкер, бу эш белән турыдан-туры шөгыльләнүче кеше бар – тарихчы Мәгъсүм ага Шәрәфиев ул. Бүгенге көндә Нырсы авылында казу эшләре алып бара. Безнең хыял – Теләче районының һәрбер авылы турында китап язу. Андый китап әлегә Нырсы авылы турында гына язылган. Без төбәкне өйрәнүче тарихчылар белән «Түгәрәк өстәл»ләр оештырып киләбез. Менә шунда бик күп мөһим мәсьәләләр күтәрелә, уңышлар, табышлар барлана, алга таба ясыйсы адымнарыбыз

тәгаенләнә. «Бергәлектә – көч», диләр бит, киләчәктә безне әллә никадәр кызыклы ачышлар көтәдер дип ышанабыз.

– Музейның тарихы белән дә таныштырып китсәгез иде.

– Без биредә икебез дә яңа кеше. Туган якны өйрәнү музееның оештырылуы, экспонатларны җыйнау турыдан-туры Әлфия Шәйхулла кызы Билалова дигән фидакарь зат белән бәйле. Ул үзе китапханәче булып эшләгән. Һәм РОНО бинасының кечкенә генә бүлмәсендә музей оештырган. Аннары музей музыка мәктәбендәге бүлмәгә күчерелә. Инде район җитәкчелегеннән музей өчен аерым бина сорап йөри торгач, менә шушы агач бинаны төзеп өлгертәләр. Экспонатлар саны арта. Аларның зур күпчелеге Әлфия ханым авылларга йөреп, үзе эзләп тапкан әйберләр.

Хатын-кызларның зиннәтле киемнәре, бизәнү әйберләре каршында туктап калабыз. Фаягөл ханым дәвам итә:

– Әлеге кыйммәтле ядкарьләр музеебызга Иске Җөри авылыннан килеп кергән. Җөри Казан ханлыгының мәшһүр шәһәрләренең берсе булган, ханлыктагы төп юлларның берсе «Җөри даругасы» дип аталган. Халыкта Җөри хан һәм аның кызы белән бәйле риваятьләр дә сакланган. Биредә яшәгән аксөяк катлам нәселләреннән килә бу затлы ядкарьләр. Затлы материалдан алтын чуклар куеп тегелгән күпшы күлмәкләр, нәфис кәҗүл читекләр... – болар барысы да бүгенге көн белән чагыштырганда бик борынгы истәлекләр булып торалар. Кемнәрдер аларны дәһшәтле елларда да саклап калган һәм менә, Ходай кушып, музейга тапшырырга карар иткән.

– Ә шулай да иң борынгы экспонатыгыз кайсы чорга карый?

– Иске Җөри авылы янында табылган хатын-кыз бизәнү әйберләре, үргән бау рәвешендә ясалган бизәк Болгар чорыныкы. Алар безгә әле ярты ел чамасы элек кенә килеп керде. Нырсы авылындагы казу эшләре вакытында табылган көмеш акча – гарәп дирһәме – XIV гасырга карый. Мамонт сөяге, орчык очлары да шунда ук табылган.

Элек Теләчедә данлыклы базар булган. Ул пәнҗешәмбе көнне эшләгән. Һәр авыл үзенә хас җитештерү тауарларын алып килгән. Музеебыздагы кәрҗин-чабаталар Комаровка авылы урысларыннан килеп кергән. Агач мичкәләр, кул тегермәннәре, бала арбалары Теләчедә агач белән эш итү һөнәрчелегенең алга киткән булуын күрсәтә. Аннары, чигүчеләр бик күп булган, чигү хәзер дә бик популярлашты. Бу һөнәр ияләре аеруча Мәтәскә, Шәтке авылларында күп очрый. Без, үз чиратыбызда, борынгы чигү үрнәкләрен торгызуга, аларны кире халыкка кайтаруга өлешебезне кертергә тырышабыз.

Музейда районның танылган шәхесләренә караган аерым почмаклар булдырылган. Шуларның берсе – татар халкының атаклы җырчысы Таһир Якупов почмагы. Анда җырчының түбәтәе, репродукторы, гармуны, самавыры, чынаяклары... Шифоньеры эчендә сәхнә костюмнары эленеп тора. Боларның барысын да музейга Таһир Якуповның исемен мәңгеләштерү өчен янып-көеп йөрүче Сания ханым китергән.

Пионерия почмагы, Бөек Ватан сугышына багышланган почмак, Әфганчылар почмагы, гомумән, музейның тулаем экспозициясе яңадан-яңа экспонатлар белән тулыландырыла бара. Музей хезмәткәрләре алга зур максатлар куеп, дәртләнеп эшли.

– Музейга өлкәннәрнең генә түгел, мәктәп балаларының да йөрүе күңелне күтәрә, – ди Фаягөл ханым. – Араларында аерым кызыксынып йөрүче балалар бар. Бигрәк тә җәйге лагерьлардан күпләп киләләр. Төбәк тарихын өйрәнүчеләр белән уздырылган республикакүләм семинардан тагын да канатланып кайттык. Тик теләгәнчә киң колач белән җәелеп эшләргә штат җитми, тагын бер хезмәткәр булса иде дип телибез. Яңа заман яңа таләпләр куя. Калышасыбыз килми, музеебызны республикадагы иң алдынгы музейлар рәтендә күрәсе, чын мәгънәсендә районыбызның тарихи-мәдәни үзәге итәсе килә.

Казаклар

Икенче тукталышыбыз – Казаклар авылы. Мәдәният йорты бакчасында безне китапханә мөдире Альбина Рәхмәтуллина белән бер төркем ханым каршы алды. 2008 елдан эшләп килүче «Ахирәтләр мәҗлесе» оешмасына йөрүче ханымнар булып чыкты алар.

Сүзебезне авылның атамасыннан ук башлап киттек.

– Авылыбызның борынгы тарихы, ни кызганыч, фәндә төгәл билгеле түгел. Архивларда да документлар сакланмаган, – дип сөйләп китте гомере буе мәктәптә тарих укыткан Гамбәрия Нури кызы Нигъмәтҗанова. – Авыл тарихы белән кызыксынып, истәлекләр язып барган мулла Рәхмәтулла бабайның язмалары арасында бер риваять сакланган. Әлеге риваятьтә, бу авылга Болгар дәүләтенең чикләрен сакларга килгән өч казах – Алагол, Байгол, Миңгол нигез салган, диелә. Алар монда гаиләләре белән килеп утырганнар. Авылга Теләчедән килгән якта әле бүген дә Алагол болыны, Байгол тавы, Миңгол тигезлеге дигән атамаларның саклануы, бу фикернең нигезсез түгеллеген раслый. Әмма кемнәр булган алар – казахмы, казакмы? Анысын фаразларга гына кала. Рус дәүләтендә гаскәрнең бер өлеше – иректә сугышчыларның «казак» дип аталуы мәгълүм. Болгар гаскәрендә дә уртада ханны саклый торган бер төркем – сакчы гаскәр булган. IX-X гасырларда Болгар дәүләтенең бик куәтләнгән чоры була, чикләре киңәя, шул вакытта бу тирәләрдә авыллар барлыкка килә. Олы Кибәхуҗа, Югары Кибәхуҗа авылларына беренче кешеләрнең килеп урнашуы да гаскәриләр белән бәйле, чик буйларын сакларга җибәрелгән кешеләр нигез салган, дип уйланыла.

Болар, әлбәттә, барысы да гоманлаулар гына. Казан ханлыгы җимерелгәннән соң бу якларда көчләп чукындыру сәясәтенең никадәр дәһшәтле булуын искә төшерсәк, Казаклар авылының килеп чыгышы бөтенләй башка эчтәлек алырга да мөмкин бит... Тик ни генә булмасын, Казаклар заман җилләренең бөтен сулышын үзе аша кичереп, бүген дә саф татар авылы булып яши.

Заманында ике мәхәлләле зур авыл булган Казаклар. Ике мәчет, ике мәдрәсә, ике зират. Әле колхозлашканнан соң, узган гасырның 30нчы елларында да, Тау өсте аерым, Тау асты аерым колхоз булган. Бүген инде Тау өстендә унлап кына хуҗалык калган, авылда барлыгы 50ләп хуҗалыкта 151 кеше яши икән. Бу тирәләрдәге беренче татар урта мәктәбе булып тирә-юньдә дан тоткан, бай тарихлы мәктәп тә (заманында 650дән артык бала укыган, читтән килеп укучылар – хәтта Арчадан кадәр килгәннәр – интернатта яшәгәннәр) сагынып сөйләргә генә калган. Соңгы – 1941 елгы чыгарылышның егетләре барысы да диярлек Бөек Ватан сугышында һәләк булганнар. Данлыклы мәктәп директоры Алексей Васильевич Кошкинны, ул сугышка киткәч директор булып калган хатыны Кәримова Зоя (чын исеме Мөһәҗүрә) Бари кызын да (күренекле галим Равил Үтәбай-Кәриминең әнисе) зур ихтирам белән искә алдылар.

Бу якларда гомер-гомердән тегүчеләр яшәгән. Тегү машиналарын чанага салып, кышларын башка авылларга да чыгып йөргән алар. Соңрак халыкның күбесе Теләчедәге Промкомбинатта һәм Олы Кибәхуҗадагы танылган тегү комбинатында эшләгәннәр. Комбинатта эшләгән кешеләрнең кулыннан бар да килгән: шәл дә бәйләгәннәр, матур-матур киезләр дә тукыганнар. Сарык йонынннан кофталар, нос-

Теләче Мәдәният йортының башкарма директоры Фирдәвес Нәгыймова (сулдан беренче) һәм Үзәкләштерелгән китапханәләр челтәре директоры Резеда Дәүлиева (уңнан беренче) «Ахирәтләр мәҗлесе» белән һәрчак тыгыз элемтәдә.

килар бәйләгәннәр. Сарыкны күп асраганнар ул чакта. Хәзер авылда сарык асраучылар бик аз икән, сыерлар да кимеп бара, 20гә тула микән, диделәр. Киметәләр малны.

Хуҗалыкларда мал кимесә дә, Казакларда бик зур ферма комплексы (сыер малы гына да меңләгән баш!) эшли икән бүген. Сыер савучыларның хезмәт хаклары да югары, хезмәт хакын вакытында түлиләр, икмәгенпечәнен дә биреп торалар, диделәр.

– Икмәк булса, җыр да була, дигәндәй, авылның мәдәни тормышы да сокландыра. Анысы инде турыдан-туры «Ахирәтләр мәҗлесе» оешмасы эшчәнлеге белән бәйле. Районда ел саен уздырыла башлаган халык иҗаты фестивальләрендә дә катнашып, бик матур итеп чыгыш ясап киләләр, – дип мактап китте Фирдәвес ханым. – Олы Кибәхуҗа авылында Мәдәният йорты ачылганда Татарстан Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнехановны да бик матур итеп каршы алдылар алар.

Ханымнар җанланып хатирәләргә бирелеп алдылар: «Фойеда орчык эрләп, җырлап тордык... Рөстәм Нургалиевич: «Чын җонмы соң бу? – дип тотып-тотып карады сарык җоннарын. – Безнең әни дә шулай орчык эрләп утыра иде», дип, әнисен дә искә төшерде...»

– Авыл һәм район күләмендә үткән барлык чараларда катнашып килүләре өстенә, китапханә каршында оештырылган «Балачак» берләшмәсенә йөрүчеләр белән киңкырлы тәрбия эшчәнлеге дә алып баралар әле алар, – дип сөйләп китте оешманың җитәкчесе Альбина Рәхмәтуллина. – Чөнки «Ахирәтләр мәҗлесе»нә йөрүчеләр барысы да зур тормыш тәҗрибәсе туплаган, тирән мәгълүматлы кешеләр: үзе «аяклы тарих» Гамбәрия апа Нигъмәтҗанова, гомер буена авыл җирлегендә эшләгән Нәсимә апа Рәхмәтуллина, китапханәче Алсу апа Гобәйдуллиналар – болар барысы да авылыбызның асыл традицияләрен саклаучылар. Яшь буынга гореф-гадәтләребезне тапшырып калдыру максатында күптөрле чаралар үткәрәбез: «Карга боткасы», «Орчык бәйрәме», «Яулык бәйрәме»... «Йомырка җыю», «Бирнә җыю», «Карга боткасы», «Каз өмәсе» кебек йола бәйрәмнәр авылыбызда бүген дә саклана әле. «Бәйрәм чәе»безне «Татарстан яңа гасыр» каналы да төшереп алган иде безнең.

– Балалар өчен бигрәк тә күңеллесе – «Йомырка җыю». 1 Майда күп итеп йомырка буйыйбыз. Балалар бик күп була, шәһәрдән дә махсус кайталар бу бәйрәмгә. Иң элек ул, билгеле, сукага төшкәндә башкарыла торган ритуал йола булган инде, игеннәр яхшы үңсын дип, буразнага йомырка салып калдыра торган булганнар, – дип аңлатма биреп китте Гамбәрия апа. – Соңыннан, тарих үзгәргәч, безнең совет бәйрәмнәре белән бергә кушылган. 1 Май – Хезмәт ияләренең бердәмлеге көне – бик зур бәйрәм иде бит инде. Йоланың шул бәйрәмгә яраклаштырылып сакланып калуы бик яхшы. Элек Сабантуйлар да язгы кыр эшләре тәмамлангач үткәрелгән бит. Хәзер инде өстән билгеләнеп, бөтен авылларда бер көнне үтә. Авылда яшәүче кешесе дә күп түгел, шуңа элеккеге кебек зур булмый Сабантуйлар. Элек бит бөтен күрше-тирә авыллар, атлар җигеп, бер-берсенә кунакка йөрешәләр иде. Безнең өч авылга бер Сабантуй була хәзер.

Соңгы елларда яңарыш алган «Чишмә бәйрәме» Казакларда да үтә икән. «Балалар белән бергәләп «Әҗәкәй чишмәсе»нә барып, башта чишмә тирәсен җыештырабыз, чәчәкләр утыртабыз, аннан төрле ярышлар үткәрәбез, самавыр куеп чәйләр эчәбез», – дип сөйләделәр. Гамбәрия апа чишмәнең исеменә нисбәтле риваятьне дә искә төшереп үтте.

– Кайнанамның апасы Гайшә әби сөйләгән иде миңа ул риваятьне. Бик борынгы заманнарда булган хәл бу. Кызлар элек-электән әлеге чишмәдән су китергән, егетләр шунда ат эчерә торган булганнар. Әҗәкәй исемле кыз чишмә янында бер егетне күреп, гашыйк булган. Әмма бу икәүнең бергә булуына әтиәниләре ризалык бирмәгән, алар кавыша алмаганнар. Әҗәкәй, йөрәк хисләренә түзә алмыйча, гел шушы чишмә янына килеп елый торган булган. Шуннан бу чишмәгә Әҗәкәй исемен биргәннәр.

...Ачык йөзле, киң күңелле, өстәвенә шулкадәр тирән мәгълүматлы ханымнар белән саубуллашып, Олы Кибәхуҗа тарафына кузгалдык.

Олы Кибәхуҗа

«Монда кадәр килеп, Олы Кибәхуҗадагы Наратлык чишмәсенә кагылмый үтсәгез килешмәс, – диде безгә якын-тирә авыллардагы тарихи урыннарны биш бармагы кебек белүче Гамбәрия апа. Үзе, шул арада, барачак авыл тарихына кагылышлы бик гыйбрәтле хәлләрне сөйли дә башлады. Гамбәрия апа Олы Кибәхуҗа авылына кагылышлы мәгъ-

луматларның байтагын шушы авыл тумасы, фәлсәфә фәннәре докторы, профессор Яхъя Абдулла улы Абдуллинның (1920–2006) хезмәтеннән алган. Шушы урында без дә галимнең хезмәтеннән бер өзек китерүне мәслихәт күрәбез.

«Авылыбызның нигезе бик борынгы. Халык арасында яшәгән риваятьләргә караганда, ул моннан 800 ел элек барлыкка килгән. Риваятьләргә караганда, авылга Коббәхуҗа исемле болгарлы нигез салган. Коббәхуҗа гаскәри дәрәҗә булырга тиеш – коббә (сугыш киеме) йөртүче. Коббәхуҗа бу якларга үзенең энесе Кадеркол белән Болгар дәүләтенең ул вакыттагы чигенә чик сакларга килә. Коббәхуҗа утырган җирдә акрынлап зур авыл барлыкка килә. Мазар елганың Максага төшкән җирендә авылның каберлеге була. Бу – зур гына мәйданны биләгән мөселман каберлеге, авыл халкы аны «иске зиярат» дип йөри. Анда хәзергә кадәр ике борынгы кабер ташы сакланган. Аларның берсе XIV йөздә, икенчесе XVI йөздә куелган. Авыл үзе Мазар елга буйлап сузылган зур һәм бай сала булган.

Язылганнарга караганда, яу сугышы килгәч (Иван IV Казанны алгач, төбәктәге авылларны буйсындыру өчен җибәрелгән урыс отряды), авылдан дошманга каршы 72 кияү чыга. Бу бәрелеш авылның югары башында булган булыр. Шул бәрелеш булган урында, хәзерге авылдан Яңа Салага бара торган юл Мазар елганы кисеп чыккан урында җир сукалаганда 12 чакмалы мылтык тапканнары да сөйләнелә. Шушы бәрелештән соң авыл халкы өчен авыр көннәр башлана. Төрле юллар белән авыл халкын чукындыру сәясәте үткәрелә. Халык моңа каршы көрәшә – авылны чолгап алган урманнарга яшеренә. Басым көчле була, акрынлап халыкның бер өлеше буйсынырга мәҗбүр була, тыштан гына булса да, христианлыкны кабул итә. Авыл үзе дә Макса елгасы буйлап бераз төшеп хәзерге урынына күчеп утыра. Ләкин халык тыштан христианлыкка күчсә дә, асылда үз диненә – исламга тугрылыгын саклый, яшеренеп кенә балаларына дин сабагы укыта. Көрәш озак елларга сузыла. XIX гасырның урталарында керәшен татарлары арасында инде ачыктан-ачык исалмга кайту өчен көрәш җәелдерелә. Бу көрәштә Олы Кибәхуҗа алгы сафта торган булса кирәк. Архивларда миссионерларның Олы Кибәхуҗа авылының мөселман пропагандасы үзәге булганлыгын күрсәткән донесениеләре саклана. 1864 елны авыл халкының күпчелек өлеше рәсми рәвештә мөселманлыкка күчә һәм моның өчен патша палачларының ачы җәзасын татый. Бу озакка сузылган көрәш 1905-1906 елларда авылда мәчет салу белән тәмамлана» (Яхъя Абдуллин, «Үткәннәр һәм уйлар», 2005 ел).

(Язылганнарга түбәндәге мәгълүматны өстибез: «...В 1867 году ... четыре крестьянина и еще 12 жителей Кибя-Козей были высланы в Сибирь. Кибякозинцы так и остались мусульманами...» («Туган ягым – Теләче», 2003)).

Хәзерге Әтнә районындагы Мәңгәр авылы бае акчасына салынган мәчетнең язмышы башка бик күп мәчетләрнеке белән уртак. 1940 елда манарасы киселә. Ә менә аен Хәлимә апа белән Нурислам абый яшереп алып кайтып, ярты гасыр өй чормаларында саклап торалар. Үзгәреш җилләре исә башлагач, өлкәннәр мәчетне торгызу артыннан йөри башлый. 1990 елда, Рамазан аенда мәчеткә яңадан манара куела. Һәм чормадагы ай да үз урынын ала...

Олы Кибәхуҗа авылына каршы тау битендә наратлык шаулап утырган. Бу наратлык изгеләр зираты дип телгә кереп калган. «Наратлык чишмәсе» авылның изге урыннарының берсе санала. Чишмә янында рәт-рәт тезелеп киткән озынча чокырлар шул зират эзләреме – җавап таба алмадык. Бәлки Изгеләр зираты нәкъ менә көчләп чукындыру вакыйгалары белән бәйледер... «Сорашып та йөрмәгез, бүген авыл халкы ул тарихны искә алырга да теләми», – диделәр безгә. Юк, бу тарих онытылырга тиеш түгел. Ул, гыйбрәт булып, алдагы гасырларга да күчә барырга тиеш. Гасырлар буена мил-

ли һәм дини изүгә каршы көрәшеп, коточкыч фаҗигалар кичереп тә сынмаган, ахыр чиктә барыбер җиңеп чыккан бабаларның исемнәре барланып, тарих битләренә җуелмаслык итеп уелырга лаек.

«Фазыл чишмәсе»

Узган ел «Иске Казан Түгәрәк уены» республика фольклор фестивалендә Теләче районының Югары Мәтәскә авылыннан килгән «Фазыл чишмәсе» фольклор коллективы беренче урын яулаган иде. Бу коллектив шулай ук «Төп йорт» республика гаилә ансамбльләре фестивалендәге этнографик күренеше белән күңелгә кереп калды.

Мәчет каршындагы тәбәнәк кенә иске клубта эшләп ята икән ансамбль. Иске мәктәп бинасы дип аңлаттылар. Киләсе елга салынырга тиешле яңа клуб бинасы аякка басканны көтеп, күңелләрен бер дә төшермичә, гөр килеп яшәп яталар болар.

«Ансамбльгә ни өчен мондый исем бирдегез?» – дигән соравыбызга каршы «Атаклы җыр тууга сәбәпче булган чишмә безнең авылда ага бит...» дигән җавап алгач, уңайсызрак булып китте, менә бит, шушы көнгә кадәр белми йөргәнбез...

– 2013 елда район фольклор фестиваленә әзерләнгәндә сайлап алдык бу исемне. Авылыбызның югары очында бик тәмле сулы чишмә ага, – дип сөйләп китте Люция Гарипова (Сәрия ханымның бертуганы). – Элегрәк ул чишмә янында Фазыл исемле кеше яшәгән. Аның дүрт улы булган. Фазыл ага, әнә шул уллары белән, чишмәне гел карап, тазартып торган. Фазыл аганың дүрт улы да сугыш кырында ятып калган, үзе дә инде күптән вафат, ә чишмә һаман да челтерәп агып ята. Халык бүгенге көндә дә бик яратып эчә аның суын.

– Әниләр сөйли иде моны, – дип дәвам итә Сәрия ханым. – Безнең авылдан бишалты чакрым ераклыкта Янбулат авылы бар. Сугыш елларында анда атаклы музыкант Рокыя Ибраһимова кайтып йөргән. Ул безнең Югары Мәтәскәгә, Зират урамындагы Әхәт атлы кешеләргә кунакка килә торган булган. Кичке уеннар әнә шул Фазыл чишмәсе янында узган безнең. Рокыя Ибраһимова да яшьләр белән Кичке уенга чыккан. Шунда буе-сыны килешле, чибәр йөзле бер егет (Зиннәт исемле укытучы егет булган ул, Бөек Ватан сугышыннан әйләнеп кайтмаган) моңарчы ишетелмәгән бик матур яңа көй уйнаган. Рокыя бу көйне отып алган да, Казанга кайткач, Сибгат Хәкимгә: «Югары Мәтәскәдә искиткеч көй оттым, әйдә, син сүзләр яз әле, матур бер җыр тусын. Без аңа «Фазыл чишмәсе» дип исем куярбыз», – дип әйткән. Сибгат Хәким 1947 елда әлеге көйгә сүзләр язган.

Безнең «Фазыл чишмәсе»ндә 20 кеше. Шулкадәр дус-тату яшибез. Бер бәйрәм үтүгә, икенчесенә репетицияләр башлана. Ике гармунчыбыз бар – бу үзе зур бәхет (күпме коллективлар музыкантсыз интегә бит!). Шуларның берсе Мәҗит Каюмов ансамбльгә хатыны Рузилә белән йөри. Рузилә авылның фельдшеры, Мәҗит төп һөнәре буенча эретеп ябыштыручы. Икесе дә шулкадәр игелекле кешеләр. (Алма агачыннан ерак тәгәрәми: сөйләшә торгач, аларның улы бүгенге яшь музыкантлар ара-

Яшьлек болынында.

сында танылып килүче егет, «Татар моңы» һәм башка конкурсларда катнашкан Илфар Каюмов булуы ачыкланды — ред.). Бөтен авыл сәнгатькә гашыйк кешеләр безнең,

Сөләйман Мөхәммәтшин 2017 елда Казанда узган «Түгәрәк уен»да Төмәндә яшәүче якташы – музыкант Әбүзәр Миңнебаев белән.

аларны санап бетерә торган да түгел: Рәис Муфазалов, Гөлзара һәм Илдар Гыймадиевлар, Әлфия, Нәкыя, Люция Гариповалар, Рузилә Исламгәрәева, Алмаз Кашафетдинов һәм башкалар... – барысына да рәхмәтләрем чиксез минем! Сәхнә бизәүне, декорацияләр әзерләүне ир-атлардан башка күз алдыма да китерә алмыйм. Кирәк икән – читәнен үреп куялар, агачын китереп бастыралар, мичен коралар – алтын куллы егетләр бездә! Беркем дә «вакытым юк» дип зарланмый. Район күләмендә уза торган мәдәни чараларның үзәгендә кайныйбыз. Теләче районы буенча үткәрелгән фольклор фестивалендә өч ел рәттән урын алып кайттык. Узган ел «Иске Казан Түгәрәк уены»нда җиңү безгә башкалабызда, Кремль территориясендә узган Бөтенроссия «Түгәрәк уен» фестивалендә катнашу хокукы бирде. Анда барып, Россиянең төрле өлкәләреннән килгән милләттәшләребезне күреп, аларның сөйләшләрен тыңлап, чыгышларына сокланып кайттык. Бу чарада катнашуыбыз безнең өчен бик зур дәрәҗә булды.

Ансамбльнең икенче гармунчысы Сөләйман Мөхәммәтшин белеме буенча мал табибы, бүгенге көндә сарыкчылык буенча фермерлык хуҗалыгы бар. Колхоз таркалганнан соң эш урыны югалуга карамастан, авыл халкына бүгенге көнгә кадәр бушлай ветеринария хезмәте күрсәтеп килә. «Тәүлекнең кайсы вакыты булса да йөгереп килеп җитә, кирәкле медикаментлары да һәрчак кул астында», – диләр. Шул ук вакытта клуб эшчәнлегендә катнашырга да җай таба. Гармунда үзе уйнап, моңлы тавышы белән авыл көен җырлап күрсәтте Сөләйман әфәнде.

– Гармунда уйнау әти ягыннан да, әни ягыннан да килә. Әти дә, аның ике энесе дә гармунчы иде. Мин 2нче класста уйный башладым. Башта мунчада уйнадым, анда бит яңгырап чыга. Язылышкан яшь парларны авыл Советыннан кыңгыраулы атта гармун белән алып кайталар иде элек. Безнең үзәк Олы Мәтәскә авылында. Гармунчы итеп мине чакыра башладылар. Авыл көен уйный идем. Үзем бик ояла идем инде. Авылыбызда Мәликхан абый белән Вәсилә апа өйләнешкәндә, бармас өчен печәнлеккә менеп качтым. Әни ялына: «Улым, төш инде, Мәликхан абыең 25 яшенә җитеп бер генә өйләнә бит инде, ат көтеп тора», – ди.

Гармуннан гомер буе аерылмадым. Тулай торакларда, туйларда бик күп уйналды. 1976 елда армиягә киттем. Монголиягә эләктем. Ул чакта «дедовщина» бик көчле иде. Әлеге дә баягы гармун коткарды. Ротада хромка бар иде. Флёра Сөләйманова

башкаруында «Әниемә» җырының чыккан чагы бу. «Дед»лар, татар малайлары, мине төнлә чакырып китерәләр дә: «Әй, земляк, теге «Әниемә» дигән җырны уйна әле!» – диләр. Төн буе уйнап чыга идем.

Бу гармунга 70 яшьләп бар. Миңа моны әниемнең энесе биреп калдырды. 15 гармуным бар. Балалардан кечкенә кызым бераз уйнаштыра, башкалары тартылмады.

Гармун белән Олы Мәтәскә авылында Сабан туенда круг әйләнеп чыгабыз без. Анда мине әбиләр көтеп тора. Мин аларны гармунга биетәм. «Күн авылы көе»н, «Карачтау авылы көе»н уйныйм. Яшь барган саен, күңел гармуннар арасыннан тальянга тартыла. Гармун йөрәккә ял бирә бит ул.

Менә шундый фидакарьләрдән тора икән «Фазыл чишмәсе». Коллектив гел эзләнүдә: өлкәннәрдән энәсеннән җебенә кадәр сорашып, әллә никадәр этнографик материал тупланган, алар нигезендә фольклор-этнографик күренешләр әзерләнгән. Сәрия Гарипова үзе биюче булгангадыр (заманында Казанда, Камал театрында, цирк бинасында узган смотр-конкурсларда җиңеп кайткан чаклары булган аның), «Фазыл чишмәсе» ансамбле репертуарында биюле күренешләр шулкадәр күп. Халык арасында аерым биючеләрнең торган саен кими баруын аңлап, алардагы бию хәрәкәтләрен видеога төшереп калырга тырышалар.

Җирле топонимиканы, йола-гадәтләрне, халык авыз иҗаты үрнәкләрен үз эченә алган бу күренешләр («Мунчала өмәсе», «Көлтә бәйләү» һ.б.), уйлап карасаң, үзләре аерым бер фәнни хезмәткә торырлык бит!

...Саубуллашыр алдыннан Люция Гарипова авыл тарихының гыйбрәтле бер сәхифәсен сөйләп алды.

– Безнең авылның халыктагы икенче исеме – Яңа ил.

XIX гасырның урталары була бу. Безнең туган йортта ул вакыт әнинең әбисе Хәдичә белән ире Әхмәт яши. Алар хәлле кешеләр булганнар, «Әхмәт байлар» дип йөрткәннәр. Көннәрнең берендә Хәдичә әбиебез келәттә он иләп ята икән, капкадан актан киенгән бер хәерче карт килеп кергән. Ул әбидән сүс сораган. Әби, «сүс бирә алмыйм, менә он бирәм» дип, моңа күпмедер он салып биргән. Карт: «Син озакламый җиңелчә җәрәхәт алырсың, ә менә авылыгызга зур афәт килер, әмма сезгә кагылмас», – дип чыгып киткән. Шул ук көнне әби ташка абынып егылып терсәген чыгарган. Өч көннән авылда коточкыч янгын чыккан. Ут, өч өй аша сикереп (берсе безнең өй), бөтен авылны камап алган. Авыл икенче урынга күченгән. Әмма ул урын тынычсыз булган, гарип балалар туа башлаган... Шуннан соң халык янә бирегә әйләнеп кайткан. «Яңа ил» дип шул вакытта йөртә башлаганнар (күрше авыллар әле дә шулай диләр.) Күрәсең, Ходай безгә шушы туфракта яшәргә язгандыр...

Субаш

Субаш авылында без атаклы «Нардуган» керәшен халык фольклор ансамбле белән очраштык. Һәм, рәхәтләнеп-кинәнеп, ансамбльнең җитәкчесе, гомере буе мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укыткан Зоя Ивановна Павлованы тыңладык.

– Катнаш урманнар, артык биек булмаган Урта, Мәрәки, Бакыр базы, Пашка таулары кочагына сыенып утырган безнең Субаш. Табигатебез искиткеч. Авылны икегә бүлеп, бормаланып-бормаланып, мул сулы инеш ага. Әлеге инешкә Гөргери, Чөмәрәй, иң борынгы Изгеләр чишмәләре килеп кушылып, аның суын үтә күренмәле итә. Балалар җәй буе кызылканат, ташбаш, җумба кебек балыкларны тотып мәш киләләр. Инешебез нинди коры еллар килгәндә дә агуын дәвам итә. Ә яз көне, ярларына сыеша алмыйча, иңкүлеккә җәелә.

«Нардуган» ансамбленең тоткалары.
Уңнан беренче – Зоя Павлова.

Субаш авылы уңдырышлы кара туфраклы җирләр, ямь-яшел болыннар уртасында балкып утыра. Биредә игенчелек, терлекчелек белән эшләп көн күрүче, баскан җирендә ут чыгарып ял да итә белүче, җыр-га-моңга бай халык яши. Районыбызда керәшен авыллары күп түгел, Субаш шулар арасында халыкның берникадәр тыгызлыгы, дөньяга аек карашы, көр күңелле, бай мәдәни тормыш белән яшәүче кешеләре белән бераз аерылып тора дисәм, һич тә ялгыш булмас.

Авылыбыз үзенең балта осталары, ташчылары белән лаеклы горурлана; нарат агачыннан, кирпечтән зәвык белән салынган йортлар елдан-ел күбрәк калка; ә чигүчелек һөнәрен бүгенгә кадәр дәвам итүче түти-җиңгиләребез көнкүрешебезгә эстетик ямь өстиләр; аларның бу матур һөнәрен оныклары дәвам итә.

Мәсәлән, лаеклы ялда да тик утыруны белмичә тәре аллары, тәрәзә пәрдәләре, сөлгеләр, алъяпкычлар, кашагалар, кульъяулыклар чигүче Анна Подъячева, Мария Новикова, Аксинья Касьяноваларның кулларыннан гөлләр тама. Чигелгән әйберләр бүген дә кулланылышта. Сабантуйларында керәшен өе аллы-гөлле болынны хәтерләтә; конкурс-фестивальләрдә дә урынлы куллана бу чәчәк бәйләмнәре.

Гасырдан-гасырга, буыннан-буынга, әбибабайдан әти-әнигә, ата-анадан балаларга үзләренең борынгы бәйрәмнәрен, гореф-гадәтләрен, йолаларын югалтмыйча тапшырып килгән халык кына озын гомерле була ала. Моның өчен, әлбәттә, туган телеңне саф килеш саклау һәм белү зарур.

Тарихыбызны онытмауда, гореф-гадәт, йолаларыбызны саклауда, аларны үсеп килүче яшь буынга тапшыруда авылыбызның мәдәният хезмәткәрләре һәм авылда яшәп иҗат итүче «Нардуган» керәшен халык фольклор ансамбле әгъзаларенең роле бик зур.

«Нардуган» ансамбе 1987 елда оеша. Менә утыз елдан артык инде үз кыйбласына тугъры калып, халкына армый-талмый хезмәт итә. Теләче, күрше районнар һәм республика халкы аларның һәр чыгышын көтеп ала, алкышлап озата. Теләче, Казан Сабантуйларының, Питрау, Казанский бәйрәмнәренең этник бизәге безнең ансамбль.

Без 2013 елдан лаеклы рәвештә «Халык» исемен йөртәбез. 2001 елдан республикада үткәрелгән бик күп фестиваль-конкурслар лауреатлары, 2012 елда ТНВның «Аулак өй» кунаклары булу бәхетен дә татыдык, 2017 елда Йошкар-Ола шәһәрендә үткән «Хәзинә» конкурс-фестиваленең Гран-при иядәре.

Тройсын, Питрау, Казанский кебек милли бәйрәмнәребез ел саен мәркәзебез Казан шәһәреннән, төрле районнардан җыелган фольклор ансамбльләре катнашында, гореф-гадәт, йолаларга нигезләнеп үткәрелә. Ә Раштуа, Олы көн (Пасха), Покрауны авылыбызның мәдәният хезмәткәре – клуб мөдире Татьяна Романова һәм китапханәче Лидия Ильиничналар җитәкчелегендә авыл халкы бергәләп клубта үткәрә. «Нардуган»лылар шушы бәйрәмнәргә хас йолаларның композициясен тамашачылар хозурына җиткерә. Аллага шөкер, башланган эшебезне дәвам итүче «Сүрәкә» (урта) һәм «Тәңкәләр» (кече) төркемнәре эшләп килә. Алла боерса, буыннар чылбыры өзелмәс, дигән өмет белән иҗат итәбез.

Авылыбыз уртасында 2010 елда нигез салынган Изге Троица чиркәве балкып утыра. Әлеге иман йортында изге дини бәйрәмнәр хөрмәтенә келәүләр укыла.

Кач ману (крещение) – көнкүрешебездән диңгезгә төшеп югалган зәбәрҗәт кебек иде. Менә берничә ел инде әлеге йола авылыбызның ихтирамга лаек егете Игорь Андреевич Дмитриев җитәкчелегендә кабат яңарды. Ир-егетләребез, бердәм булып, әлеге эшкә алындылар, территорияне әзерләделәр. Кач манып аруландырылган суда чумынып ел буена саулык алу, авырулардан котылу өчен ел саен бик күп ышанучылар килә. Коенып чыккан һәркемнең, сөенечтән, күз төпләрендә шатлык күз яшьләре җемелди.

Әйе, һәр уңышның нигезендә оешканлык, тырышлык, дуслык ята. Алдагы көннәрдә дә чәчәк атучы Казаныбыз – башкалабыздан якты нур алып, бергә-бергә бердәм булып, бәйрәмнәребезгә йөрешеп, гореф-гадәт, йолаларыбызны саклап, дус һәм тату яшәсәк иде!

(Язманың дәвамы 56нчы биттә)



Әләшә. Үткәнме, бүгенгеме, киләчәкме?

Казан арты Әтнә төбәгендә, бормаланып аккан Ашыт елгасы буенда бу як кешеләре өчен генә түгел, гомумән, татар халкы өчен үтә дә әһәмиятле бер урын бар. Халык телендә Кала тавы дип аталган, күпсанлы легенда-риваятьләргә сәбәпче булган әлеге биеклек археологлар тарафыннан кальга буларак тәгаенләнсә, халык исә, Казан шәһәренең борынгы урыны нәкъ менә биредә булуына ышанып яши. Шушы ноктада лирик чигенешләрне калдырып торып, тарихи фактларга күз салыйк әле.

Кала тавы археология фәнендә Әйшияз шәһәрчеге исеме белән билгеле. Әлеге җирлектә истәлекле-тарихи өч урын бар.

Беренчесе – Күәм авылыннан 500 м көньяк-көнбатышта урнашкан Әйшияз шәһәрчеге зираты. Халык телендә ул Хан зираты дип йөртелә. 1956 елда бу зираттагы ике каберне археолог Н.Ф.Калинин казып карый. Һәм әлеге каберлек XVI гасырга караган мөселман зираты дигән нәтиҗәгә киленә. Хан зиратыннан көнбатыштарак Әйшияз шәһәрчеге урыны. Тышкы ур (вал), чокыр, керү урыннары бүген дә әйбәт беленеп тора. 1956 елгы казу эшләре вакытында биредә безнең эраның I меңъеллыгы уртасына хас керамик әйберләр дә табылган. Әйшияз шәһәрчегеннән 400 м чамасы көнбатыштарак, урман эчендә Изгеләр зираты һәм Изгеләр чишмәсе урнашкан. Ашытның уң як биек ярында үскән урман эченнән салынган 159 басмалы тимер баскыч буйлап аска төшсәң, Изгеләр чишмәсенә килеп чыгасың. Кала тавын өйрәнгән күренекле дин белгече, тарихчы-галим Шиһабетдин Мәрҗани Кала тавы Ислам мәмләкәтенең чиге булып, чирмешләрдән сакланыр өчен кальга буларак хезмәт иткәндер дигән фикерне әйтә (Шиһабетдин Мәрҗани, Мөстафәдел-әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар, Казан, 1989, 160-161 битләр). Тарихчы С.М. Шпилевский «Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии» (Казань, 1877) дигән китабында да Кала тавы турында язып калдырган. Ул Әйшияз шәһәрчеге урларын кирпеч ишелүдән барлыкка килгән дип фаразлый. Димәк, кайчандыр ур өстендә кирпеч стена булган дип уйларга нигез бар. Мари тарихчылары исә Әйшияз шәһәрчеге мари җирләренең көньяк чигендә XVI гасырда төзелгән кальга булмадымы икән дип язалар (Очерки истории Марийской АССР, Йошкар-Ола, 1965).

Татарстан АССР тарихының I томында (Казан, 1959, 12 бит) бирелгән археологик картада бронза гасыр культурасы истәлекләре табылган урын буларак Әйшияз шәһәрчеге дә күрсәтелгән. Татарстанда бронза гасыры безнең эрага кадәр II меңъеллыкка туры килә. Кала тавының никадәр борынгы икәнен шуннан да чамалап була.

Халык телендә йөргән риваятьләр исә башкачарак: элек Ашыт елгасы мул сулы булган. Елга буйлап саллар агызганнар, көймәләр йөзгән. Бөек халыкның бөек тарихы шаһиты Ашыт елгасы ярында (Ашыт сүзе борынгы төркиләрнең нәсел башы саналган Ашин (бүре) ыругы атамасыннан килеп чыгуы гына да бик күп нәрсә турында сөйли!) бабаларыбыз кала төзергә ниятлиләр. Әмма елганы яхшылап өйрәнгәннән соң, аксакаллар биредә зур шәһәр салырга ярамавы, Ашытка тиздән саегу куркынычы янавы хакында кисәтәләр. Калатауда хан кирмәнен саклар өчен күпмедер кешеләрен калдырып, Казансу буена барып урнашалар. Кирмәндә калган кешеләр дә вакыт-

лар узу белән Әйшияз һәм Куәм авылларына кучәнә. Әнә шулай хыялдагы кала, тау исеменә әверелеп, бүгенгегә бары кайтаваз булып кына килеп җитә.

Инде «Әләшә» бәйрәменең үзе хакында да сүз башларга вакыттыр. Бөтен Казан арты халкының бәгырендә сулкылдаган «Әләшә» бәйрәме нәкъ шушы урында – Кала тавында ел саен җәй башында – сыерчык бала очырган атнаның җомгасында уздырыла. Нинди бәйрәм соң ул «Әләшә»? Ул кайчан барлыкка килгән? Бүгенге көнгә кадәр нигә аны төбәк халкы күз карасы кебек саклый?

«Әләшә» – Казан арты татарларының мәҗүси заманнардан бирле үткәрә торган бәйрәме, әнә шуңа да халкыбыз өчен бик газиздер ул. Мәҗүси заманнарда табигатькә табыну, ут аша сикереп, чистарыну йолаларын үз эченә алган бәйрәм тормышыбызга Ислам дине килеп кергәч тә югалмаган, эчтәлеген, формасын үзгәртсә дә, кадерен җуймаган бәйрәм булып кала килгән. Ачлык елларында, сугыш чорында да, дин тыелган җаһил дәвердә дә юкка чыкмаган, безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Бүген исә «Әләшә» бәйрәме – язгы кыр эшләреннән соң җыелып, ил-көнгә иминлек, басу-кырларга уңыш-бәрәкәт, шифалы яңгырлар сорап Аллаһы Тәгаләгә ялвару, вәгазьләнү, әрвахлар рухына дога кылу җыены. Бәйрәм көне Рамазан аена туры килмәгән елларда Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен корбан чалынып, казан асыла, табын корыла. Соңгы елларда «Әләшә»гә якын-тирә Куәм, Әйшияз, Каенсар, Көек авылларыннан гына түгел, ерак араларны якын итеп, бөтен Казан артыннан, Татар иленнән, хәтта чит төбәкләрдән дә халык җыела.

«Әләшә» исеме үзе кайдан килеп чыккан соң? Адлер Тимергалинның «Миллият сүзлеге»ндә әләшә/әләсә тарихи-лексик берәмлек буларак түбәндәгечә аңлатылган: «Әләшә/Әләсә Казан татарларында язын ут ягу һәм шуның аркылы сикерү йоласы, башта пакьләнү ритуалы булып, соңыннан яшьләр уенына әйләнгән». Галимә Фирдәвес Гарипова, әлеге аңлатмага нигезләнеп, үз фикерен әйтә: «Ут аша сикереп чыкканда, «Алач!» дип кычкырганнар. Бу аваз – татар, кыргыз, казак һ.б. халыкларда пароль сүз – оран. Ә себер татарларына «алас» әйтелеше хас. Мондый йола Урта Азиядә аеруча күп таралган була. Казан һәм себер татарларына ул шуннан килгән дип уйлыйлар. Р. Әхмәтьянов «алас» сүзенең этимологиясен гарәпчә «халас» – «азат, йөксез, гөнаһтан хали» сүзе белән бәйли. 1969 елда басылып чыккан «Татар теленең диалектологик сүзлеге»нә мөрәҗәгать итик: «Әләшә – Казан артының этнә сөйләшендә «яшьләр уены» (гулянье, игры молодежи). Ашыт җыенында Кала тауга әләшәгә чыгалар ыйы җәшләр (ТТДС, 69: 543)». Димәк, «Әләшә» бәйрәме төрки бабаларыбызның җәй башында уздыра торган төп йолалары – җыеннарга барып тоташа. Замана шаукымы белән данлыклы Ашыт җыены тарих тузанында күмелеп калганда, «Әләшә», бакый дәверләрне бүгенгегә бәйләп, Казан артының килер буынына үз нурын сирпергә омтыла. Саклыйсы иде аны!

Дөресен әйтим, соңгы елларда «Әләшә» турында төрле фикерләр ишетелә. Араларында шактый катгый яңгырап, әлеге йола-бәйрәмне җан җылысы белән саклап яшәгән төбәк халкын рәнҗетерлекләре дә бар. Кайбер дин әһелләре, «Әләшә» – мәҗүсиләрдән калган җыен, Ислам динендә андый бәйрәм юк, аны үткәрү дөрес түгел» дигән сискәндергеч өндәмәләр белән күңелгә шактый шом салырга да өлгерде.

Масштаблы фикер йөртеп тә, үз халкының чын улы булып калган Шиһабетдин Мәрҗани: «Өч әйбер диндә юк, әмма динне саклый. Болар – милли тел, милли кием һәм милли гореф», – дигән. Исламны кабул иткәнгә кадәр халкыбыз үткән, безнең аң үсешебезгә шактый тәэсир калдырган мәҗүсилек чорыбызны беркая да куя алмаган кебек, рухыбызны бөтен итүче йолагадәтләребездән дә бер селтәнүдә баш тарта алмыйбыз ләбаса! Һәм әле баш тарту кирәкме икән?! (Уйлый китсәң, татарны татар иткән Сабан туебызның тамырлары да тарихның мәҗүси катламнарыннан җан тарткан түгелме соң?) «Әләшә» бәйрәменең асылына игътибар иткәндә, Ислам диненең бер генә канунына да каршый килми лә ул! Мөселман кардәшләрнең үзара очрашып аралашуы, вәгазь тыңлау, Коръән уку, дога кылу, каберләрне зиярәт итү – Ислам динендә, киресенчә хуплана гына, шулай бит? «Ярамый!» дигән катгый фәтва дин юлында күңел тәрәзләрен әле яңа ачарга җөрьәт иткәннәрнең гайрәтен чигермәсме? «Әләшә» кебек меңъеллык йолалардан түгел, ә дорфалыктан, каты бәгырьлектән күбрәк куркырга кирәктер, мөгаен.

Уйламыйча кычкырырга, сенсация ясарга яраткан кайбер беркатлыларның «Әләшә»не Кече Хаҗ белән чагыштырулары, хан зиратында үтенеч кәгазьләре калдырып, Кала тау изгеләренең үз теләкләрен чынбарлыкка әверелдерәчәгенә ышанулары – монысы инде дистә еллар динсезлек томаны эчендә адашып йөреп, әле яңа гына калебе актырган өммәтебезнең дини яктан белеме сай булуы, милләт мәгърифәте сагында торган мәдрәсә системабызның тамырына балта чабылуның аяныч нәтиҗәсе дип аңларга кирәктер. Тора-бара Ислам диненең нечкәлекләрен бишектән үк белеп үскән, милләт мәнфәгатьләрен дин кануннары белән үзара яраштырып яши алган буын килер, ул чагында инде фикер каршылыклары да, ялгыш-хаталар да булмас дип ышанасы килә.

* * *

Алда телгә алынган Әүлия каберлегендә эленмә тактага түбәндәге сүзләр язылган: «Бүгенгәчә исеме төгәл сакланмаган ханның дин әһеле Ирәмәли балалары: Сөләйман хаҗи, мулла Таҗетдин, кызлары Гайшәбикә һәм Хәнифәбикә абыстайлар һәм 5 сабый кыз бала шушы урында дәфенләнәләр. (якынча 960-985 еллар)». Фикерле белгән һәркем әлеге язуны укыганда гаҗәпләнеп куядыр. Идел буе Болгарында рәсми төстә ислам динен кабул итү 922 елга туры килә. Ә бирердә 960 елларга караган кабердә хаҗи күмелгән! Ул чорларда хаҗ кылу, хаҗ сәфәренең айлар түгел, елларга сузылуын да искә алсаң, бу җирләргә Ислам диненең Болгар дәүләтенә караганда да иртәрәк килүен, биредә мөселманнар яшәвен аңлап ничек шаккатмаска кирәк! «Әләшә»не халык бәгыреннән йолкып алырга теләгән затларга әлеге кире каккысыз фактлар гыйбрәт булсын иде.

Һәр елны сыерчык бала очырган җәй иртәсендә Кала тавының олпат эргәләре азан тавышына изрәп китәр, борынгы йолаларына тугры Казан арты, Әтнә төбәге халкы «Әләшә»гә җыелыр – мең еллар буена үзгәрмәс хакыйкать, дәверләр киндеренә сеңгән илаһи күренеш бу! Башкача мөмкин түгел!

Гөлүсә БАТТАЛОВА,
Әтнә, Күәм.



Раилә САБИРОВА

Кичке уенга чыгабызмы, ә?..

– Габдрәй абзаң белән Кичке уенда таныштык без, наныем. Ул гармунда өздереп уйный, мин чүәк табаныннан утлар чыкканчы биергә ярата идем. Кичке уен беткәч, Габдрәй мине түбән очка кадәр озата кайта. И-ии, аның мине озата кайтканын бөтен авыл белә иде инде, шул тиклем гармун уйнамаса!..

...Күрше әбинең гомерлек яры белән су буенда Кичке уенда танышу тарихын әллә ничә кат тыңлаганым булды. Әллә яшьлеген сагынудан, әллә хәтере бераз кителгәнгә бик еш искә ала иде ул бу тарихны. Сөйләсен! Мәхәббәт аңкып торган сагынулы моңсулану ич ул! Кичке уен романтикасы!

Әби-бабайлар сөйләгәнен ишетсәм дә, әдәби әсәрләрдә очратсам да, Кичке уен дигәннәре һәрчак бик мавыктыргыч тоела иде миңа. Анда инде, әнә, бездәгечә егетләр клуб ишеге төбендә таптанып басып тормагандыр! Их, безнең авыл дискотекаларын да Кичке уенга әйләндерсәң иде ул, дип хыялланган чаклар да булды минем... Жылы-рәхәт җәйге кич. «Чут-чут» итеп кайдадыр сандугач сайраганы ишетелә. Ә су буендагы иңкүлек чырык-чырык кызлар көлүенә, җыр-моң тавышына күмелгән. Монда бию, парлы уеннар, мәзәк сүзләр, гармун тавышы, уен-көлке! Монда гомерлеккә вәгъдәләшү, тәүге кабат күз карашлары белән аңлашу, танышу, кулъяулык алмашу... Монда әби-бабайларның бәхетле яшьлеге, оныкларга сөйләрлек татлы ядкаре!..

Соңгы елларда Кайбыч районында Кичке уеннар үткәрелә башланды. Нәкъ йоласына туры китереп, кояш батып, көн кичкә авышкач, көтү кереп, кичке эшләр тәмамлангач башлана ул күңелле уеннар.

Соравыл, Кошман, Бортас, Кече Мәме, Чути, Борындык, Мөрәле һәм башка авылларда да халык Кичке уеннарга чыга. Кая «Зәлидә» әйләнәләр, кая парлы бию. Кичке уенда беркем дә тыныч кына басып башкаларны тамаша кылып тормый! Төрле авылларда Кичке уеннар гөрләгәннән соң, ямьле бер кичтә бар халык Олы Кайбычның Сабантуй мәйданына җыела.

Район үзәгендәге Кичке уен Кайбычта яшәүче татар, рус, чуашларның кулга-кул тотынышып Түгәрәк уен уйнаулары белән башлана. Чигүле түбәтәйләр, канатлы алъяпкычлар, итек-читекләр, кызыл каймалы, җете бизәкле күлмәкләр, артка чөеп бәйләнгән яулыклар, ялтыр бизәкле биек калфаклар гөр килә мәйданда.

– Төрле халык җырлары, биюләр, милли уеннар белән үрелеп баручы Кичке уен – районда яшәүче төрле милләт халкын берләштерүче мәдәни күпер ул. Ә мәдәния-



тебезне үстерер өчен милли йолаларыбызны белү, өйрәнү, саклап кала белү кирәк, – дип әлеге бәйрәмнең никадәр мөһим икәнлегенә басым ясый Кайбыч муниципаль районы башлыгы Альберт Рәхмәтуллин.

Мәйдан тирәсендәге халык шау-гөр килеп «Пар табыш», «Әсир алыш», «Күпер», «Чума үрдәк, чума каз» уеннарына чыга. Олысы да, кечесе дә, җитәкчесе дә... берсе дә читтә калмый. Бөтен кеше бии, күңел ача. Халык уеннары тәмамланган арада, Кайбычта яшәүче төрле милләт фольклор коллективлары чыгыш ясый, яшьлек җырларын яңарта. Җырлар нинди телдә генә яңгыраса да, гармун тавышы тынмый ул кичтә! Сыздыра гына егетләр! Ул да түгел, мәйданга кыңгыраулар чыңлатып, чиккән сөлгеләр, түшле яулыклар белән бизәлгән тарантаслы, чыр-чу килгән бала-чага төялгән арбалы атлар килеп керә. Соңгы елларда Кичке уенга ат бизәп килүчеләр Яшел Үзән районы Татар Танае авылыннан Рәис Тазов, Олы Кайбыч авылыннан Рузалит Сөнгатуллин һәм Иншәр Гыйсмәтуллиннар булды. Кайбыч егетләре гомер-гомергә атларга гашыйк булуы белән аерылып тора инде ул . Кичке уенга атлар белән килү дә бу җирлекнең зур үзенчәлеге булып тора!

Кайбычтагы Кичке уен – гореф-гадәтләребезне яңарту, аларны башкаларга да җиткерү, бигрәк тә яшь буынга күрсәтү максатыннан оештырыла. Әнә, балалар мәйданчыгы шат авазлардан гөрләп тора, олырак балалар инде зурлар белән бергәләп төрле халык уеннарына да катнашып күңел ача. Ммм... мәйдан тирәли тәмле ис таралган! Кайда коймак, кайда пылау һәм уха пешә, самавыр кайный... Төрле тәмтомнар белән тулы өстәлләр янына килеп һәркем теләгәнчә сыйлана ала. Көн инде эңгер-меңгер булып, тәмам кичкә авышкач, мәйдандагы халык күмәкләшеп «Зәлидә» әйләнергә керешә. Кичке уен караңгы төшкәнче дәвам итә, Кайбыч өстендә ул көнне бик озак гармун тавышы ишетелеп тора әле.

...Кичке уеннарны йөреп кайтканда мин янәдән Габдрәеен сагынган күрше әбиен искә төшердем. Соңгы елларда Кайбычта буйдак егетләр саны артып киткән диләр. Их, менә бу Кичке уеннар буйдаклар саны кимүгә, бик матур татар гаиләләре артуга да сәбәпче булса иде!

* * *

Кайбыч районы, Иске Тәрбит авылыннан Галя апа Медова искә төшерә:

– Безнең якта, Кичке уеннарга чыкканчы, кайбер уңган кызлар Ивановога барып эшләп, басмалар (тукыма) алып кайтканнар. Басмалардан Кичке уенга чыгарга дип бер иш күлмәкләр, яулыклар теккәннәр. Яулыкларның читен һәр кыз үзенчә чигә торган булган. Кичке уенга чыккан кызларның кулларында һәрчак кулъяулык булган. Уен вакытында берәр егет берәр кызның кулъяулыгын алса — бу мәхәббәт белгертү дип саналган. Мин яшь чакта Кичке уеннар Питрауга чаклы гына уйнала иде. Безнең Иске Тәрбитнеке генә булган Кичке уен җырлары да хәтердә әле. Без аларны урам әйләнеп җырлап йөри идек.

Башмагымның дагасы,
Шак-шак басып барасы.
Болай торып булмыйсы,
Уен әйтә башлыйсы.
Шылтыр-шылтыр беләзек,
Кул иләмен китерә.
Буйга җиткән кыз чыккач,
Уен иләмен китерә.

* * *

Өч багана булыйкмы, ди,
Киртәләнеп уйныйкмы?
Бар кыз бергә җыелыйкмы,
Таң атканча уйныйкмы?
Алмагачы барында
Таянмыйбыз талларга.
Үзебез кызлар барында
Җалынмыйбыз ятларга.
Ике басу карышы,
Бөгелә микән арышы?
Теге якның кызлары
Киләме икән кар(ы)шы?
Тал төбендә тыныч су
Тастымаллар юарга.
Бар кыз бергә җыелыштык
Уйнап-көлеп җырларга.
Су өстендә багана,
Башына дулкын кагыла.
Ай-һай, шушы уен өчен
Татлы йокы кала ла.
Идел буе сары алма,
Сары алма ашамаек.
Шушы уенны башлагач,
Бетермичә ташламаек!

* * *

Әй уш кына, уш кына,
Урыннары буш кына.
Быел киткән кызларның
Урыннары буш кына.
Быел Гөбнә бик тулы,
Казлар ничек йөзәдер.
Быел киткән кызларныкы
Җаны ничек түзәдер?

* * *

Челтәр күпер булмаса,
Күпердән дә китмибез.
Уйнамагач та көлмәгәч
Кыз булып та йөрмибез.
Җитен элдем читәнгә,
Җилфер-җилфер итәргә.
Әйдәгез, кызлар, кериик,
Вакыт җитте керергә.
Җир җиләге җыя-җыя
Савытларым тулды инде.
Әйдәгез, кызлар, таралышыйк,
Кайтыр вакыт булды инде.
Кырда карга кычкыра,
Җирдә елан сызгыра.
Әйдәгез, кызлар, керәбез,
Таң әтәче кычкыра.

Питрау җиткәч, Кичке уенны кыр күперен чыгып уйный идек. Шул рәвешле, имеш, уенны икенче елга озатып җибәрәбез.
И уза ла, уза ла,
Кулда көмеш туза ла.
Тузса тузсын көмешебез,
Уеныбыз уза ла!
Тал өстендә ак яулык.
Ал дисәң дә, алыш юк.
Моннан уен узгачтын
Чык дисәң дә, чыгыш юк.
Чуар кукку туклыйдыр,
Сука өстендә туктыйдыр.
Ай-һай безнең уеныбыз
Питрау җиткәч туктыйдыр.
Бу җырлар буыннан-буынга күчеп килгән. Питраугa чыккач, әле хәзер дә рәхәтләнеп җырлыйбыз аларны.

Төш юраулар

Намаз укыганыңны күрсәң, кеше арасында олуг булырсың.

Төштә ай, кояш, йолдызлар күрсәң, тормышта абруй белән яшәрсең.

Тау башында утырганыңны күрсәң, дәрәҗәң артыр, зур урыннарга утырырсың.

Алтын акчалар күрсәң, кулыңа хәләл мал керер, вак акча күрсәң, гайбәт ишетерсең, мәшәкатең артыр.

Ишегалдыңа каз йә торна килеп керүен күрү – малаеңның өйләнүенә, аларның очып чыгып китүен күрсәң – кызыңның кияүгә чыгуына.

Әйләнә-тирәңдә казлар йә тавыклар күрү – үтәлмәгән нәзергә.

Төшеңдә күп итеп балык күрү – байлыкка, балыкның кулдан төшеп суга китүе – малдан аерылуга.

Пешмәгән арык ит – авыруга, майлы ит – бәрәкәткә.

Илбашлыкларын күрү – шатлыкка, сөенечкә.

Киң юлдан йә киң урамнан бару – тормышыңның яхшыруына.

Салават күпере күрү – шатлыкка, яшен күрү – борчуга.

Бүрәнә күрү – юлга, киселгән бүрәнә – кыска сәфәргә, агач кису – юлга чыгарга хәбәр килүгә.

Терене үле күрү – күргән кешенең озын гомерле булуына, үлене тере дип күрү – шатлыкка.

Әрвахны ялангач күрсәң, аның исемен атап, сәдака бирергә кирәк йә аның рухына атап дога кылырга кирәк.

Төштә аю күрү – дошманың барлыгына ишарә. Аюны үтергәнеңне күрсәң, дошманыңны җиңеп чыгасың.

Төштә болыт күрү – хәвеф-хәтәргә. Бу көнне «Аятел-көрси» укып, сәдака бирергә кирәк.

Төштә җиләк-җимеш күрү – авыруга.

Яхшы тун кию – шатлыкка.

Азрак кына кар, боз күрү – тиз үтә торган кайгы, күңелсез мәшәкать.

Чыганак: Юсупов Ф.Ю. Сафакул татарлары: тарих, тел, халык иҗаты, Казан, 2006, 426 б.

Әйлән-бәйлән

Июль ае башында Әлки муниципаль районы «Яшь имәннәр» балалар савыктыру лагерендә II Республикакүләм «Әйлән-бәйлән» Татарстан халыклары милли традицион уеннары фестивале үтте. Бу чара Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы каршындагы Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге һәм Әлки районы башкарма комитеты тарафыннан оештырылган иде.

Фестиваль балалар фольклор коллективларына ярдәм итү, халык уеннарын саклап калу өчен шартлар тудыру; балаларда һәм яшүсмерләрдә туган телгә, мәдәнияткә, гореф-гадәтләргә карата мәхәббәт тәрбияләү; җөмһүриятебездә яшәүче халыкларга хөрмәт уяту максатларын күздә тота.

Быел фестивальдә Казан шәһәреннән һәм Татарстан Республикасының 10 районыннан: Әгерҗе, Әлки, Алексеевск, Балык Бистәсе, Саба, Сарман, Теләче, Тукай, Чистай, Яшел Үзәннән 13 балалар фольклор коллективы катнашты. Ә фестивалебезнең махсус кунагы быел да Төмән өлкәсеннән килгән «Вак бәлеш» балалар фольклор төркеме булды. Алар татар, рус, чуваш, мари халык традицион уеннарын күрсәттеләр.

Имән агачлары ышыгында, чәчәкләргә күмелеп утырган лагерь – үзе бер әкияти дөнья. Капка төбеннән үк кунакларны әкият геройлары каршы алды. Регистрация узып, урманда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре белән танышканнан соң, коллективларның капитаннары кулларын буяуга манып, таблода дуслык чәчәге ясадылар. Аннан инде балалар өчен «Яшь имәнлектә уеннар» дип аталган мавыктыргыч квест башланып китте. Коллективлар бер сәгать дәвамында әкият геройлары әзерләгән биремнәрне үтәп, серле сандык янына килеп җиттеләр. Ә монда аларны оештыручылар тарафыннан әзерләнгән бүләкләр көтә иде.

Фестивальне рәсми төстә Әлки муниципаль районы башлыгы Александр Фёдорович Никошин, Татарстанда кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Сәрия Харис кызы Сабурская, Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәгенең бүлек мөдире Нәфисә Азват кызы Сагбиева ачып җибәрде. Кунаклар балалар уеннарына да катнашып киттеләр.

Фестиваль ачылышыннан соң Сабантуй мәйданында үткәрелгән җирәбәдә һәр команданың капитаны туган телендә сөрән салды. Җирәбә ярдәмендә коллективларның чыгышы билгеле бер эзлеклелеккә корылды.

Соңыннан командалар өчен «Уен мозаикасы» бәйгесе үткәрелде. Һәр катнашучы командa үзенең исемен атап, девизын әйтте, әзерләп килгән традицион уенның кагыйдәләрен аңлатып бирде, уенга башка команда уенчыларын җәлеп итү осталыгын күрсәтте. Бу эшләрне башкарып чыгу өчен командаларга 15-20 минут вакыт бирелде. Уеннар тәмамлангач, жюри әгъзалары нәтиҗә ясады. Беренче көн уен нәтиҗәсе буенча Казан шәһәреннән «Энҗе бөртекләре» коллективы (җитәкче – Галиева Гөлназ) җиңүче дип табылды. Фестивальнең беренче көне учак янында кич утыру, легендалар сөйләү, җырлар, кичке уеннар белән тәмамланды.

Икенче көнне иртәнге аштан соң Сабантуй мәйданында «Бергә уйныйбыз» бәйгесендә командалар традицион милли уеннар: хәрәкәтле, драматик яки түгәрәк уен тәкъдим иттеләр. Балалар уенның кагыйдәләрен үзләштереп, тәҗрибә алмашу буенча мастер-класслар үттеләр. Шул арада жюри әгъзалары бәйгедә күрсәтелгән уеннар өчен коллективларга урыннар билгеләде.

Беренче урынга Төмән өлкәсеннән «Вак бәлеш» (җитәкче – Ислам Сафин), Тукай районыннан «Скоморошина» (җитәкче – Марина Бачуркина), Әлки районыннан «Веселушки» (җитәкче – Фирдания Хабибуллина) коллективлары лаек дип табылды. Фестивальгә килгән барлык балаларга да бер үк төрле истәлекле һәм файдалы бүләкләр тапшырылды.

Дуслык әйлән-бәйләне белән тәмамланган фестивальдән балалар икенче елга да очрашу өмете белән таралыштылар.

Гөлфирә ХИСАМЕТДИНОВА,
Республика тарадицион мәдәниятне үстерү үзәге белгече

Раилә ХӘЯЛИЕВА

Сүзләре хикмәтле, куллары сихәтле

Комлыкта – нарат, өскә таба имән урманы җәелеп киткән. Кайчандыр бу урманнар чукынырга теләмәгән Тәрбит авыллары качаклары белән тулы булган, бастырырга килгән казак гаскәрләреннән качып авылларыннан кузгалган үксез ятимнәрне сыендырган. Петр I заманында кораблар төзү өчен дә имәннәрне Олы Тәрбит урманнарыннан кискәннәр, диләр...

Бүген менә урыны белән шомлы, урыны белән якты аланнары булган Тәрбит урманында тыныч кына җәйге яңгырларга чыланып хуш исле чабыр, ак тажлы ромашкалар, сары мәтрүшкәләр һәм тагы бик күп шифалы үләннәр түшәлеп үсә, шыпырт кына җәнлек-җанвары йөреп тора. Урман һаман табигатьнең үз сулышыннан яралган садә җаннар өчен барып көч алыр, сыенып урын булып кала әле. Еш кына бу урман сукмагында чуар яулыгын ияк турыннан чияләп бәйләгән, бала итәкле яшел күлмәге өстеннән ике кесәле ситсы алъяпкычын кигән, очына кечкенә төенчек бәйләнгән чикләвек таягын иңсәсенә салган керәшен карчыгы – Лиза апа Кошкинаны очратырга була. Урманда ул, акрын гына керәшен җырларын сузып, үзе генә белгән сукмаклардан йөрергә, көч-дәва һәм шифалы үләннәр җыеп кайтырга ярата. Урман шомлы диләр, тик Лиза апа өчен түгел!

– Мин яшь чакта урман караучы Солтан абый бар иде. Үзенә кая да булса барырга кирәк булганда, ул урманны һәрвакыт миңа ышанып калдырды. Урманда бернинди куркыныч юк, рәхәтләнеп акрын гына җырлап йөрим. Иртә яздан ылыс бөреләрен җыям, аннан юкә чәчәген, ромашка, чабыр үләне, меңъяфрак... Үги ана үләнен өйгә алып кайтырга ярамый, гаиләне боза. Җир җиләге күп була безнең якта. Җиләк җыеп как та ясыйм, кайнатма да. Мунча чыккач чәй эчәргә тәмле була ул...

Сөйли дә сөйли Лиза апа. Тыңлыйсың-тыңлыйсың да, аңа яшәешнең мең төрле сере, тылсымы билгеледер кебек тоела башлый. Табигать кануннарына буйсынып, үз көенә талгын гына болын-кырларның шифалы сулышын тоеп яши белгәнгәме икән, бигрәк рәхәт аның янында. Тыңлаган саен тәнгә сихәт, җанга тынычлык иңә сыман.

Инде, әйдәгез, Лиза апа белән бергәләп, урман юлыннан акрын гына, авыл ягына борылыйк.

Бүгенге көндә Кайбыч районын икегә бүлеп агучы Гөбнә елгасы буена урнашкан Олы Тәрбит авылында 500 дән артык кеше яши. Бу яклар гомер-гомергә иген иккән һәм терлекчелек белән көн күргән. Олы Тәрбит авылында туып-үскән Лиза апа Кошкина да үзенең хезмәт юлын терлекчелек тармагыннан башлаган. Хезмәт юлы гына түгел, кулларының сихәте дә мал-туарны дәвалаганда ачылган аның.

– Шуңа гаҗәпләнәм, хәзер зур-зур йортларда яшәсәләр дә, кешеләр тавышланып бетәләр, бер-берсе белән тату яши белмиләр. Мин авылыбызның «Мачы» кушаматлы гаиләсенә килен булып төштем. Дөресрәге, урладылар мине, – дип сүзне бик ерактан башлады Лиза апа. – Биш ел ике килен, биш бала, кайнана, өч ир-ат бер йортта яшәдек. Иремнең энесе – солдатка китмәгән малай – безнең баш очында йоклый иде, кемдер мич башында, кемдер сәкедә. Шулай да гаиләдә бер тавыш та чыкмады, дус-тату булдык! Килендәшемнең балалары минеке тирә туды. Аның күкрәгенә сөт төшми иде, шуңа үземнекеләрне дә, килендәшемнең кечкенә балаларын да мин имезә идем. Аннары иремнең энесе солдатка китте, ә без өч бала белән иске генә бер йортка күчендек. Мич ягып өй җылытабыз, ашарга пешерәбез. Балалар мин күрмәгәндә күмер белән уйный, бөтен өй эче кап-кара була торган иде. Бервакыт, ферма мөдире булып эшләүче абыем йөгереп кергән: «Фермада ике үгез сугышты, берсе егылды», – ди. Бик курыккан үзе, колхоз малы өчен баш белән җавап бирә торган заманнар бит. Чыгып чаптым мин дә абый артыннан. Барсак, үгез һаман ята, тормаган. Мин тиз генә зур күзле

инә сорап алдым да, үгез янына кереп, ертылган урынын тиз генә ямадым да койма аркылы кире сикердем. Бер сәгатьтән үгез торып йөри башлаган. Бу хәлне белгәч, и орышты кайнанам, и орышты. Өй тулы олан, алар турында уйламыйча нишләп куркыныч янаган урында йөрисең, ди. Балаларны бик ярата иде кайнанам, безгә дә аларны гел кайгыртып торырга кушты, балалар үсмичә мине эшкә дә чыгармады. Инде икенче юлы абыем тагы килгән, кинәт сикереп торып әнисе янына йөгергән тай аягын каймыктырган. Баса да алмый, җаныкаем. Абыйдан камфара мае сорап алдым да, шул майны сылап тай аягын озаклап удым. Бераздан торып чапты тай. Бу хәлдән соң, абый миңа, кулың белә синең дип, бу эшне ташламаска кушты. Шулай акрын гына мал табиблары дәвалый алмаган терлекләрне миңа тапшыра башладылар. Аягы чыкканмы, бозаулый алмыймы, барысына да мине чакырталар иде. Бозау асларына кереп, аркам белән терлекне күтәреп, чыккан сөякләрен җайлаган чаклар да булды. Аннан үземнең балаларның кул-аякларын утырта башладым. Балалар шук бит, тик кенә тормыйлар. Күрше хатыннары да балаларын алып керә иде. Аннары күршедәге Чүти авылыннан да килә башладылар. Кулларыма сихәт каян килгән соң, дип үзем дә еш кына уйланам. Яшь чакта, кан китеп, бик озак аңсыз ятканмын мин. Аю каны эчертеп дәвалаганнар. Табиблар терелəсемә ышанмаганнар да. Мин терелеп кайткач, авыл халкы аһ иткән. Менә шул хәлләрдән соң, им-томчылык сәләте ачылган бугай инде миндә.

Кызганыч, миңа бу дәва эшенә фатыйхасын биргән абыемны бик яшьли үтерделәр шул. Игезәк улларымның берсе сигез яшендә үлеп китте. Егерме ел бергә яшәгәч, ирем дә вафат булды. Күп җәфа күрергә, хәсрәтне шактый татырга туры килде безнең башларга.

Балалары үсә төшкәч, колхозга эшкә чыга Лиза апа. Бушаганда бер улына көтү көтәргә дә булыша. Әле бит йорт-җирне дә карап торырга, балаларны да тәрбияләргә кирәк. Авылда мондый мәшәкать хатын-кыз җилкәсенә салынган, беркая да китеп булмый. Колхозның да эше күп, берсе беткәнче, икенче эш көтеп тора. Түз генә! Сабыр кеше шул ул Лиза апа. Тыныч кына тормыш алып бара, им-томчылык эшен дә туктатмый.

– Элек басуда бик күп итеп чөгендер эшкәртергә бирәләр иде бит. Минем дә басудагы эшне кеше белән бергә бетерәсем килә. Эшкә генә тотынам, ярдәмең кирәк, дип алып китәләр. Ярдәм сорап килгән кешене кире дә борып җибәрә алмыйм. Әле техника да юк заман бит. Җәяү барып авырган кешене карыйм, аннан кире басуга кайтып эшемне дәвам итәм. Иптәш хатыннар, башта үз эшеңне бетер, аннары кеше эшен карарсың, дип әрлиләр иде. Мин алай булдыра алмыйм шул, кеше гозерен аяк астына салып булмый, – ди Лиза апа.

Ел әйләнәсе Лиза апалар өендә кеше өзелми. Капка төбендә машина эзе беткәне юк. Ул берәүне дә кире бормый, һәркемгә тыныч кына ярдәм күрсәтә, сихәтле куллары белән буыннарны сыйпый, авырткан урынга җан өрә. «88 яшьтә генә ич әле мин. Пенсиягә чыгармыйлар, тегендә киткәч ял итәрсең, диләрдер», – дип кеткелди үзе.

Кечкенә балалар егылмыйча, койма, рәшәткә башына менмичә тормый. Үзебезнең дә кечкенә кызларыбызны Лиза апа янына берничә тапкыр алып барганыбыз булды. Табибтан курыккан балалар белән дә уртак телне тиз таба ул. Тезләрен майлап уа-уа да, борылган, каймыккан сөякләр шылт итеп кенә үз урынына кайтып куя. Балалар сизми дә кала.

– Авырткан җирне ничек беләсез? – дип кызыксынам.

Килен кайнана туфрагыннан ярала, диләр.
Лиза апаның килене Надяның да
кулларыннан гөлләр тама.
Надяның кулдан чигелгән бирнәләре.

– Кулым белән капшап сизәм. Буыннарның ничек дөрес урнашырга тиешлеген шулай тоеп беләм. Төрле авырулар белән киләләр. Кем кулын тайдырып, кем күзеннән чүп алдырырга. Әнием дә күзгә кергән чүпне теле белән бик оста ала торган иде. Балаларга кургаш белән куркулык та салам. Менә ун ел балага уза алмаган бер хатын килде. Сихәтләп, сылап җибәрдем, файдасы тигән. Күптән түгел малаен күрсәтергә килеп китте. Миңа килеп эчен утырттырганнан соң балага узган хатыннар күп. Аларның бала тапкан дигән хәбәрен ишеткәч бик сөенәм мин. Минем «балалар» Мәскәүдә дә, Казанда да, Чуашта да, үзебезнең районда да күп үсә, шөкер. Бу заманның икенче бәласе: халык баш авыртудан бик җәфалана. Мунчага керер алдыннан, 2-3 сәгатькә баш түбәсенә май (каз, тавыкның эч мае) сылап торуның файдасы зур. Чигәләргә камфара мае сөртеп уарга да була, дип киңәшләрен бирә Лиза апа.

– Дәвалау күп көч, энергия сорый. Үзегез ничек хәл аласыз?

– Көчем китсә, ятып торам. Үлән чәйләре эчәм. Үләннәрнең файдасы бик күп. Файдалы үләннәрне язын урман-болыннардан җыеп кайтырга тырышыгыз. Табигать үзе табиб ул, һәр авыруга дәвасын бирә. Үзем җыеп киптергән үләннәрне минем янга дәва эзләп килгән кешеләргә дә биреп җибәрәм.

15 онык, 20 оныкчык, әле күптән түгел генә бишенче буын онык туган. Бик бай дәү әни ул Лиза апа. Оныгы Сергейның тормыш иптәше – Надежда килен сөйли: «Нәселдә яңа бәби тугач, бөтен туган-тумача, дәү әни-дәү әтиләр бер йортка җыела безнең. Лиза дәү әнине барыбыз да Мачы әби дип йөртәбез. Ул бу бәби бәйрәменә зур савытта ботка пешереп килә. Ботканы һәркем авыз итеп чыгарга тиеш. Хәтта кечкенә бәбигә дә боткага манып алынган кашык очын ялаталар. Аннан Мачы әби баланы чишендереп, буыннарын тикшереп чыга. Бала елак булса, берәр нәрсәдән куркып калмадымы икән дип, куркулык коя».

Лиза апа чиркәүгә йөрүчеләргә йөри. Коры да тота (бу як керәшеннәре уразаны шулай дип атый). Ире үлгәннән соң, ялгызы гына җиде бала үстергән: ике малай, биш кыз. Бер кызы белән бер улы авылда яшиләр икән. Башкалары төрлесе-төрле якларга таралганнар. Төп йортта калган улы Алексей һәм килене Светлана белән гомер итә, оныкларына булышып яши.

Августта җыела торган дару үсемлекләре

Абага – тамыры җыела

Аир (аир болотный) – тамыры

Алтынбаш (золототысячник малый) – үләне

Балан – җимеше, кайрысы

Бака яфрагы (подорожник большой) – яфрагы

Гөлбадран – чәчәге

Дүләнә (боярышник) – чәчәге, җимеше

Зәңгәр мәтрүшкә – чәчәге

Кандала үләне (донник) – үләне

Колмак (хмель обыкновенный) – күркәсе

Кычыткан - яфраклары

Күк җиләк – җимешләре

Песи үләне (валериана) – тамыры

Шома кәпшә (дягиль) – тамыры

Сазанак (багульник болотный) – үләне

Тырнак гөл (календула, ноготки) – чәчәге

Әрекмән – тамыры

Кура җиләге – җимеше

Меңъяфрак (тысячелистник) – үләне

Миләш – җимеше

Нарат – ылысы, бөресе

Наратбаш (хвощ полевой) – үләне

Ромашка – чәчәк кәрзиннәре

Тузганак – үләне, тамыры

Турак уты (толокнянка) – яфрагы

Петрушка – үләне, тамыры

Чалма чәчәк (пион уклоняющийся) – тамыры

Әрем – үләне

Үги ана яфрагы – чәчәге, яфрагы

Үлмәс гөл (бессмертник песчаный) – чәчәге

Үлән, чәчәк өлешләрен җыю өчен 2–12 август; тамырларын җыю өчен 16–26 август көннәре кулай булыр.

«ИНТЕРТАТ.РУ» сайтыннан алынды.

Искедә казынсаң, яңаны белерсең

Мин Биектау районының Чуваш иле авылы китапханәсендә эшлим. Авылымның үткәне белән кызыксынам. Махсус архивта утырмасам да, китапларда очраткан мәгълүматларны, өлкәннәр хәтерендә сакланган кызыклы истәлекләрне, фактларны теркәп барам. Алар арасында кулъязмалар да бар. Бу материалларны киләчәктә нишләтермен – белмим, әмма үзем туплап бара торган истәлекләрнең күз карасы кебек сакланырга тиешле кадерле ядкарьләр икәнлеген аңлап яшим.

Безнең Чуваш иле авылы Алат юлы өстендә урнашкан. Авылның атамасы Казан ханлыгы дәвере документларында Чуваши (Чуваш Караул) рәвешендә искә алына.

Татарстан зиратларындагы кабер ташы язмаларын җентекләп өйрәнгән эпиграфист Һ. Йосыпов бу авыл зиратында XVI йөзгә мөнәсәбәтле кабер ташы язмалары таба. Казан өязенең 1602–1603 елларга караган теркәү кенәгәләрендә Чюваш (чыганактагы язылышы шулай) авылында йомышлы татарлар һәм ясаклы татарлар яшәве күрсәтелә.

Авылыбызның элеккеге мулласы Вәли ага Шәймарданов Чуваш Иле авылы оешу турында түбәндәге риваятьне сөйләп калдырган: «Иван Грозный, Казанны алгач, татарларны куган. Бу авылга шул заманнарда килеп утырган ханның өч улы булган: Каратмән хан, Айбаш хан, Җуаш хан. Болар өчесе өч авылны нигезләгән. Бирегә Җуаш хан килгән, исемен бозып яза торгач, Җуаш иле «Чуаш Иле»нә әйләнеп киткән. Авыл икегә бүленгән: суның бер ягында – казаклар, икенче ягында ясаклылар яшәгән. Бу яктагылар лашман эше эшләгәннәр, имән ташыганнар. Монда «Ар кайнаткан» дигән җир бар, анда арлар (удмуртлар) килеп имән яндырганнар һәм күмерен сатканнар».

Авылыбызның атамасының килеп чыгышын галимә Фирдәвес Гарипова «Чуваш иле» дигән язмасында Идел буе Болгар дәүләте белән бәйләп аңлата: «Борынгы Болгар дәүләтендәге кабилә-кавемнәрнең бер өлешен чуваш дип атаганнар булса кирәк. Марилар аларны «суас», татарлар «чуваш» дип йөрткәннәр» («Очерки истории Высокогорского района РТ, Казань, 1999).

Чуваш иле заманында төбәгебездәге күрекле авылларның берсе булып саналган. Урталай инеш белән бүленгән зур авылның элек ике мәчете булган. Аның берсенең бинасы әле дә исән (китаплардагы «ул мәчет сүтелгән» дигән мәгълүмат дөрес түгел! «1867 елда иминиятләштерелгән» дигән калай беркетмәдәге язу әле дә укырлык). Дөрес, ул бүгенге көндә ташландык хәлдә.

Безнең авылда элек-электән күн аяк киеме җитештерү белән шөгыльләнгәннәр. Олылар, Чуваш илендә сандал осталары күп иде, дип сөйлиләр иде. Авыл уртасында аяк киемнәре тегү буенча алты кешедән торган артель эшләгән. Чүәк-читекне күбрәк революциягә кадәр теккәннәр, аннан соң башлыча өйдә киелә торган башмакка (домашний), сандалга күчкәннәр. Бер бабай «конфискациядән курыкканга» дип аңлатты.

Гарипов Мөхәммәтҗан (Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле баш балетмейстеры Гарипова Раилә Мөхәммәтҗан кызының әтисе булырга тиеш) авылда теккән читекләрен Казанга, Мичәк Садыйгына (Кәвешче Кәрим) илтеп тапшыра торган булган (Гарипова Марзия истәлекләре).

Мотыйгуллин Кәрим үзе сандал тексә, сеңелесе Марзия чүәк эшләгән. Бу 1960-еллар булырга тиеш. Алар заказга да теккәннәр, тауарларын базарга да алып чык-

Казанның Фатих Кәрим урамындагы Кәвешче йорты

каннар. Казанга күчеп киткәч тә бу кәсепләрен дәвам иткәннәр.

Читек, сандалны тагын Гобәйдуллин Гали дә теккән, Галиев Сөнгатьне исә сандалчы буларак хәтерлиләр.

Соңгы буын аяк киеме тегүчеләр: Галиев Вәли, Ганиев Габделхак, Зарипов Әхмәтҗан, Сафиуллин Габдрахман, Гайнуллин Гыйният, Гайнуллин Гани. Алар инде берсе дә исән түгел. Хәллерәк чакларында теккән әйберләрен (сандал, домашний) Казанга илтеп сатканнар, олыгайгач өйдә теккәннәр, заказ биргән кешеләр тауарны боларның өйләренә килеп ала торган булганнар.

Әле мин мәктәптә укыган елларда да авылда ике-өч бабай өйдә кия торган башмак тегү белән шөгыльләнә, аларны күрше авыллардан да килеп алалар иде.1985 елда күрше авылда укыганда, укытучыларга заказ белән Зарипов Әхмәтҗан абый теккән домашнийларны берничә тапкыр илтеп бирдем. Кызганычка, борынгыдан килгән бу һөнәрне бүгенге көндә дәвам итүче калмады.

Башкалабыз Казанда, Иске Татар бистәсендә 2013 елда реставрацияләнгән, «Кәвешче йорты» дигән эленмә такта урнаштырылган тарихи йортның хуҗасы булган кеше – Садыйк Кәримов та Чуваш иле кешесе. Ул заманында Казан халкы арасында «кәвешче Кәрим» буларак дан алган атаклы аяк киеме тегү остасы булган. Садыйк Кәримовны, Казанга күчеп киткәнче, «Мичәк Садыйгы» дип йөрткәннәр. Авылда хәзер дә, ташландык хәлдә булса да, Мичәк кизләве бар. Әлеге кизләүне Садыйк Кәримов казыткан диләр.

Чуваш иле татарның күренекле шәхесе, мәшһүр педагог Галимҗан бине Мөхәммәтҗан бине Баруди (1857–1921) исеме белән дә бәйле әле. Галимҗанның атасы, Казан сәүдәгәре Мөхәммәтҗан Галиев егет вакытында аяк киемнәре җитештерүче осталары белән танылган Чуваш илендә сәүдә агенты булып хезмәт куя. Ул Кече Кәвәл кызы Фәхернисага өйләнә (Галимҗан Баруди кайбер чыганакларда Чуваш илендә туган дип, икенче берләрендә исә Кече Кәвәлдә туган дип күрсәтелә). 1960 елда яшь гаилә Казанга күченә. Мөхәммәтҗан авыл халкы тормышында-көнкүрешендә игелекле эз калдыра, чөнки халыкның шактый өлеше алга таба да озак еллар буена шушы һөнәр белән көн күрә. Мөхәммәтҗан Галиев Казан губернасында шәрекъ аяк киемнәре белән сату итүче буларак танылган атаклы сәүдәгәр Мостафа Фәйзуллин белән хезмәттәшлек итә һәм аның вафатыннан соң, үзе зур ширкәтнең хуҗасы булып китә.

Сүз уңаеннан шуны да әйтик, Иске Татар бистәсенең үзәгендә торгызылган «Татар утары» да Чуваш иле авылы кешесе, мануфактура һәм баш киемнәре белән сату итүче икенче гильдия сәүдәгәр Хәмит Сабитов (1818–1900) йорты булган.

1935-59 елларда авылыбызда МТС гөрләп эшләгән, тирә-як авыллардан трактор курсларына укырга килгәннәр, ике медпункт, балалар бакчасы, почта, мәктәп, китапханә, клуб, яшелчә бакчасы, умарталык – барысы да булган.

Хәзер 135 ләп кеше яшәгән авылның клубы, китапханәсе, медпункты гына бар. Юл асфальтланган, Казанга якын, шунлыктан дача йортлары төзиләр; авылның үз кешесенә эш кенә юк.

...Күршебездәге Маҗар авылы тагын да кызганычрак хәлдә. Табигатьнең искиткеч матур урынында урнашкан бу авылда бүген нибары ике кеше яши, дачалар бар. Юл юк. Аның белән әле, һич ялгансыз, бер ай элек кенә кызыксына башладым, ләкин соңгарак калынды, хәтерләүчеләр калмады диярлек. Кайбер фотосурәтләр таптым. Маҗар да Чуваш иле белән бер чордарак оешкан булырга тиеш. Заманында ул да зур булган, хәтта аерым колхоз булып яшәгән.

Шактый еллардан бирле, иске фоторәсемнәр җыям. Авылдашларымнан сорап алып, күчермәләр ясатам. Алар күп калмаган инде, искене ташларга яратабыз бит. Шул фотоларның берничәсен «Түгәрәк уен»га да тәкъдим итәм

Сәвия, ГАЛИЕВА
Чуваш иле авылы китапханәчесе

Иске мәчетебез бүгенге көндә дә үзендә яңгыраган азан авазын сагынып утыра...

Көтү көткәндә.1957 ел.

Маҗар авылы хатыннары колхоз эшендә.

Бу фотолар Татарстанның Биектау районы Чуваш иле авылында яшәүче Сабитова Наилә, Әхмәдуллин Гафиятулла, Надыйрова Ләләләрнең гаилә альбомнарыннан алынды.

Чуваш иленең яшелчә бакчасында.

Фин сугышына киткәндә.1939 ел.

Чуваш иле мәктәбе укучылары.1955 ел.

Гали РӘХИМ

Борынгы төрекләрдә дөньяга караш һәм халык әдәбияты

Борынгы төрекләрнең әхлакка карашлары да үзләренең икътисади халәтләренә мөнасиб булып, аларда, һәрбер күчмә халыкларда булган шикелле, кунакчыллык, гайрәт һәм сугышчанлык, һәрбер патриархат тормышында булган шикелле, атага буйсыну, зинага зур гөнаһ итеп карау, хосусый милекне изге нәрсә итеп тану, шуның аркасында урлаган өчен зур җәзалар тәгаен кылу, атасы үлгәч – үги анасын, агасы яисә энесе үлгәч – җиңгә яки киленне никах итү шикелле гадәтләр хөкем сөрә иде*.

Шулай итеп, борынгы төрекләрдә чын мәгънәсе белән бер төрле катгый идеология табарга мөмкин түгел. Булган идеологияләре дә аларның күчмә тормыш, патриархи иҗтимагый дәрәҗә, шаман дине китереп чыгарган фикер һәм тойгылардан гыйбарәт. Бу идеологияне үз күзе белән күрәсе килгән кешегә бары бер юл гына бар, ул да булса халык теленнән алынып язылган «Коркыт», «Сәед Баттал», «Сары Салтык газый» шикелле дастаннар һәм борынгыдан бирле авыздан-авызга әйтелеп йөртелә торган табышмак, мәкаль, җыр һәм дастаннар шикелле халык әсәрләрен укып, алардагы ислам тәэсирен алып ташлап, чын төрек гонсырын (элементын) гына калдырып караудыр. Димәк, иң борынгы төрекләрнең идеологияләрен күрсәтүче көзге – халык әдәбиятыдыр.

Мәгълүм ки, борынгы төрекләр өчен тип шәкелендә булган тормыш күчмәлек иде. Мондый дәрәҗәи мәдәниядә (мәдәни дәрәҗәдә) торган халыкларда без, гомумән, халык әдәбиятының бай булуын күрәбез. Борынгы бәдәви гарәпләрдә халык әдәбиятының байлыгы мәгълүм мәсьәләләрдәндер. Болай да, басма әдәбият таралмас борын, халык әдәбияты һәммә гыйрык (җирле) халыкларда да бик тәрәккъый иткән (алга киткән) була. Бөхәр шикелле икътисад галимнәре[1] халык җырларының һәм музыкасының хезмәт белән бергә, коллектив рәвештә эшләгәндә килеп чыккан булучылыгын исбат иттеләр. Күчмә халыкларда, шул җөмләдән төрек халыкларында да, бик борынгы заманнардан бирле җыр һәм музыканың шактый таралган булуы, табигый, аларның икътисади хәятләре белән бергә бәйланган.

Борынгы күчмә төрек халыкларын шул ук тормыш һәм кәсеп сугышчан булырга мәҗбүр итте: аларга хайваннарны, мал-туарны ерткычлардан сакларга, күчеп, яхшы кырлар эзләп, «кыр гизеп» йөргәндә ят кабилә һәм халыклар белән очрашырга, күп вакытта яңа утлавыкларны корал куәте белән сугышып алырга, шул ук Кытай, Иран шикелле мәдәни (һәм заманасының империалист) илләрнең һөҗүменнән «йорт»ны, «олыс»ны, «ил»не сакларга кирәк була иде. Мал-туар үләт белән кырылган чакларда, ачлыктан гаҗиз булып, борынгы төрекләр күрше илләргә, бай кабиләләргә һөҗүм итеп, талап азык табарга мәҗбүр булып тордылар. Шулай ук аксөяк ыруг һәм кабиләләр карасөяк ыругларын үзләренә буйсындырып тору өчен, борынгы «Спарта»дагы хөкем сөрүче сыйныфлар шикелле, һәрвакытта коралланып торырга, карасөякләргә дә, кысылуның чиге килеп җитә башлагач, баш ыругларга каршы найза, айбалта, кылыч һәм ук-җәяләрен кулларыннан төшермәскә тиеш булды. Шуның өчен бо-

рынгы төрекләр иҗтимагый төзелешләрендә унга бүлү әсасы (нигезе) белән, гаскәрилек рәвешендә эшләделәр. Менә шушы сугышчанлыкны саклау өчен аларга рухны күтәрә торган музыка һәм җырлар кирәк иде; шуның өчен борынгы төрекләр һәм монголларда сугыш алдыннан кубыз уйнап[2], гаскәрне кыздырып тору гадәте бар иде; сугышлардан кайткач та ил шагыйрьләре, «узан»нар[3], «акын»нар үлән әйтеп, борынгы батырларны мактап, хәзерге егетләрне җилкендерәләр иде. Урысларның иске мәнбәгъләреннән (чыганакларыннан) «Слово о полку Игореве»[4] безгә борынгы куман-половецлардагы шундый гадәтне тасвир итә. Шулай ук түбәндә сөйләнәчәк борынгы сәлҗук төрекләренең халык дастаннары мәҗмугасы (җыентыгы) «Китабе Коркыт»та[5] халык җырчысы «узан»ның «илдән илгә, бәйдән бәйгә» йөреп, борынгы сугышларны сөйләп, баһадирларның канын кыздырганын бәян кыла.

Икенче яктан, борынгы төрек халыкларында халык әдәбиятының тәрәккъкый итүенә сәбәп күчмә халыкның шул эш белән шөгыльләнергә вакыты булуыннандыр. Сугыштан тыныч чакларда күчмә төреккә артык эш юк. Аның бөтен йорт һәм көнкүреш эшләрен хатыннары башкаралар, игенченеке төсле көн саен булып, күп хезмәт сорый торган шөгыльләр аларда юк. Шуның өчен академик Радлов[6] борынгы төрекләрдән мәдәни дәрәҗәдә артык алга китмәгән күчмә кыргызлар хакында сөйләгәндә: «Матур сөйләү сәнгатен өйрәнергә кыргызның вакыты бар. Ул көн-төн сөйли, йокы белән ашау гына аның сөйләвенә манигъ була (тыя) торган шөгыльләр һәм дәр вакыйг (чынлыкта) кыргызлар фәсахәт (матур теллелек) һәм матур сөйләү белән аерылалар», — ди**.

Халык әдәбиятының киңлеге, байлыгы ягыннан күчмәле төрекләр никадәр утрак халыклардан алда торсалар, халык әдәбияты әсәрләрен иҗат һәм хәтердә саклау җәһәтеннән дә алар шулай ук югары торалар. Күчмәле төрекләрнең кәсепче (профессионал) җырчылары шулкадәр күп әйбер күңелдән беләләр ки, мәдәни халыкларга аларның хәтер кувәләренең (куәтләренең) көчлелегенә гаҗәпләнергә туры килә. Алар ифрат озын дастаннарны, бихисап җырларны, әкият һәм легендаларны күңелдән белә торган булалар. Профессионал җырчылар — алар, күбесенчә, шагыйрьләр дә. Телдән-телгә йөргән әдәбиятны тудыручылар, үзгәртүчеләр һәм саклаучылар да шулар. Ләкин алар халык әдәбиятында бик гам (гомуми) булган шаблоннар (калыплар) буенча гына иҗат итеп, шагыйрьнең шәхсияте (индивидуальность) әсәрләрендә аермачык күзгә ташланмаганга, гомум авыз әдәбиятындагы гадәт буенча, аерым шагыйрьләрнең намнәре (исемнәре) хәтердә сакланмый, аларның әсәрләре дә гомум халык әдәбияты массасына кушылып, халык малы булып китә. Шулай итеп халык әдәбияты әсәрләре мәйданга килә.

Дала шагыйрьләре бик көчле рәвештә импровизация кувәсенә дә малик (ия) булалар. Ягъни алар тоткарсыз, фикерләренә килү белән, теләгән нәрсәләре хакында шигырь тезеп әйтә алалар. Язу сәнгатенең керүе аркасында мәдәни-утрак халыклар арасында инде бу кувә югалган; чөнки алар һәрбер фикерләрен сөйләү аркылы түгел, бәлки, кәгазьгә язу аркылы изһар итәргә (ачып салырга) өйрәнгәннәр. Артык бер әйбер булып калганга, импровизация ташланган, онытылган. Мәдәни тормышта бик сирәк шагыйрьләрдә генә ул заһир (билгеле) була. Әмма дала шагыйрьләре өчен бу бик гади нәрсә. Алар берничә сәгать тоташтан авызларыннан яңадан-яңа мәүзугларга (темаларга) шигырьләр коеп тора алалар. Халык әдәбиятында күп мәүзугларга әзер калыплар, әзер гыйбарә һәм җөмләләр, хәтта бөтен-бөтен мисраглар (шигырь юллары) булганга, кәсепче җырчы өчен бу артык читен эш түгел. Аның бөтен осталыгы шул әзер кисәкләрне шома итеп ялгап җибәрүдән генә гыйбарәт[7]. Мәсәлән, бер-бер җыен яки туйда шагыйрь-җырчы шунда хәзер булган кунакларны һәм йорт хуҗасын тәүсыйф итеп (сыйфатлап), мактап, исемнәрен атап җырлый, хуҗаның дошманнарын сәлеб (юк) итә, алардан көлә; мәҗлескә яңа бер кеше килеп керү белән ул, шигыренең агышын бозмастан, мәүзугны яңа килүчегә күчерә. Тыңлаучылар даирәсе байлардан гыйбарәт икән — ул байларны, байлыкны, юмартлыкны мактап җырлый, ярлылардан гыйбарәт икән — байларны яманларга, аларның начар сыйфатларын тезәргә тотына; чөнки халык өстендә туена торган халык җырчысына шулай тыңлаучыларына ярарга тырышмый ярамый. Аннан соң оста импровизаторлар бәгъзы мәҗлесләрдә үзара әдәби ярышлар ясыйлар; ягъни алар шигырь әйтешеп, сүз көрәштереп бер-берсен илзам итәргә (бәхәстә җиңеп чыгарга), җавантан, дәвам итүдән гаҗиз итәргә тырышалар[8]. Хәзерге дала казакъларында да бу бар гадәт; бәгъзән (кайчак) ике «әйткеч» бер-берсен җаваптан калдыра алмыйча төннәр буенча шигырь әйтешеп чыгалар икән[9]. Менә

бу гадәтләр күчмәле төрек халыкларында борынгы заманнарда да, шөбһәсез, булгандыр, бәлки, тагын да куәтлерәк хөкем сөргәндер.

Җыеннарда картлар, осталар җыелып курай уйнау, җырлау, самак әйтү[10] шикелле борынгы күчмәлектән калган гадәтләр безнең башкортларда да әле хәзергә кадәр сакланган. Күптән утраклыкка күчүләренә карамый, профессионал дастанчылар Анатолий төрекләрендә дә очрый. Болар хәзер авылдан-авылга йөреп, кайчан калаларга да килеп, каһвәханәләрдә халык җыеп, «Сәед Баттал»[11] шикелле ярым халык әсәре булган дастаннарны яки «Хуҗа Насретдин» латыйфәләре (мәзәкләре) күк халык иҗаты булган анекдотларны сөйлиләр. Төркиядә хәзер боларны «мәддах» («мактаучы») дип атыйлар[12]. Бу мәддахлар, шиксез, шул борынгы «Китабе Коркыт»та сөйләнгән илдән-илгә гизүче «узан»нарның варисларыдыр.

Борынгы төрекләрнең халык әдәбияты үз вакытында язылып алынма[га]нга күрә, бары мәнбәгъләрдә генә булган бәгъзы кинаяләр аркылы, борынгы авыз әдәбиятының нинди булуы хакында катгый бер фикергә килергә мөмкин түгел. Чөнки заманнарның агышы белән бертуктаусыз үзгәреп тору халык әдәбияты дигән нәрсәнең төп хассасыннандыр (үзенчәлегеннәндер). Шулай да мәсьәләне ачарга бөтенләй үк имкян (мөмкинлек) юк дип әйтеп булмый. Ул да булса, хәзерге түбәнрәк мәдәни дәрәҗәдә торган, читләр һәм дин тәэсирләренә азрак бирелгән төрек кабиләләренең халык әдәбиятын өйрәнеп, шуннан заманнар буенча өсте катланып килгән катлауларны алып ташлау соңында, шул әсәрләр борынгы заман әсәрләре (яки шуларга бик якын) дип танудыр. Вакыйган (чыннан да) без бу халык әсәрләрен борынгы заманныкы дип таный алабыз. Күчмә төрек халыклары, бөтен күчмә халыклар шикелле, шактый консерватор табигатьлеләр; аларның бу әсәрләре ата-баба әсәрләре булу йөзеннән изге әсәр ителеп танылганга, аларны җырчылар күңелләрендә саклыйлар (нәкъ безнең татар әбиләре куркылык[13], чалпу[14] шикелле шаманизм калдыгы гадәтләрендә әйтелә торган сүзләрне саклаган төсле). Әгәр без моның өстенә «Коркыт», «Сәед Баттал», «Күр углы»[15], «Хуҗа Насретдин» шикелле, хәзер язылып алынган булса да, электә халык телендә йөргән дастан, кыйсса һәм хикәяләрне дә арттырсак, төрекләрдә борынгы халык әдәбиятының нидән гыйбарәт булуы хакында бер фикер ясый алабыз; ләкин ничек тә, аларның нинди әсәрләр булганлыгын тәгаенләп әйтеп булмый.

Шактый иске заманнарда язылып алынып сакланган халык әдәбияты әсәрләреннән иң мөһиме һәм хәзердә халык хәтереннән югалганы мәшһүр «Китабе Коркыт»тыр. Бу әсәр нәсер белән язылган, ләкин төзелеш, мәүзуг һәм өслүбе (стиле) белән ул чын бер каһарман дастаны. Бу китап борынгы төрек әсәрләре арасында бөтенләй аерым урын тота торган аерым энҗеләрдәндер. Аның саф халык иҗаты булган (беркадәр орхон язуларының өслүбен хәтерләтә торган) теле шулкадәр шигъри, матур һәм фәсыйхбәлигъ (матур-төзек) ки, хәзерге көндә төрек әдипләре үз өслүбләрен шул юл белән алып барсалар, зур муаффәкыять (уңыш) казанырлар иде. Үзенең әдәби кыйммәте белән бергә, теленең дә ифрат борынгы (архаик) булуы аркасында, бу әсәр рус-европа галимнәрен бик кызыксындыра. Аңа зур әһәмият бирелеп, аның хакында шактый әдәбият та мәйданга килгән. Бу китап хәзергә бер-ике генә кульъязмада табылган. Анадулда табылып, борынгы җөнүб (көньяк) төрекчәсендә язылган булса да, госманлылар үзләре бу әсәр хакында бернәрсә дә белмиләр; алар өчен ул тәмам югалган***.

Бу әсәрне башта, госманлы һәм сәлҗук төрекләренең бабалары – угыз төрекләре арасында мәйданга килгән булырга кирәк, дип чамалыйлар.

Мәгълүм ки, угызлар хәзерге төрекмәннәрнең дә бабалары; шулардан ук госманлы халкы килеп чыккан. Китапның мөндәриҗәсе (эчтәлеге) шулай: мөкаддимә (кереш сүз), монда мәкальләр, афоризмнар, кыскача характеристикалар; 12 данә аерым хикәя. Тел һәм өслүбе бер булу, һәрбер хикәядә алда сөйләнгән кешеләрне, баһадир һәм каһарманнарны, вакыйгаларны әйтеп китү, тәкрар кылулар (кабатлаулар) – бу әсәрнең, бер иттифакый (очраклы) мәҗмуга гына булмыйча, Илиада һәм Одиссея шикелле бербөтен поэма (дастан) булуын күрсәтәләр.

Хикәяләрдәге вакыйгалар күбрәк Әрмәнстан тауларында вакыйг булалар (барлыкка киләләр). Каһарманнарның дошманнары Гөрҗи, Кара диңгез буендагы абхаз халкы һәм трабзун румнары. Монда тасвир кылына торган каһарманнардан мәркәзи шәхес – угызларның баш ханы Баяндәр хан[16]. Ул үзе сугышларда иштирак кылмый (катнашмый). Чын сугышчы каһарман исә аның кияве Казан бәй.

Коркыт баба**** булса, ул бер баһадир түгел, бәлки, илнең аксакалы – патриарх. Ул бөтен төрек халкының хикмәтен үзенә җыйган бер кеше. Аның кем икәне мәгълүм түгел. Әсәрнең үзендә аның Мөхәммәд [пәйгамбәр] заманында булып, хак мөселман булганлыгы сөйләнә[17]. Ләкин аның тарихи шәхесме, әллә уйдырма, хыялдан туган бер кешеме икәне һаман да хәл кылынмаган. Шулай да борынгы гарәп мөәррихләре бер вакытта, XII гасырда угыз халкының башында Коркыт исемле кеше булганлыгын сөйлиләр, төрекмәннәрдә, кыргызларда һәм Кавказ таулары артындагы халыкларның телендә дә Коркыт, Хорхуд ата исемле каһарманнар сөйләнә. Бер рум мәнбәгы угызларга якын булган печәнәкләрдә дә шундый бер Коркуд исемле башлык булганын сөйли. Әлхасыйль (кыскасы) бу исем борынгыдан килгән, угыз төрекләре арасында мәшһүр булган бер кешенең яисә чынлыкта булмаган, хыялый бер шәхеснең исемедер*****.

(Ахыры бар)

* Бу хакта тәфсилле мәгълүмат Гурляндның «Степное законодательство» дигән әсәреннән табарга мөмкин. – автор искәрмәсе. (Яков Ионович Гурлянд турында сүз бара. – А.Г.)
** Образцы народной литературы тюркских племен. – Ч. V, стр. 4. Шул ук әсәрдә һәртөрле төрек халыкларының халык әдәбиятларыннан нәмунәләр (үрнәкләр) табарга мөмкин.
*** Бу әсәр хакындагы әдәбият:
1. Переводы отдельных рассказов В. В. Бартольда в Зап. Вост. Отд. Им. Арх. О-ва: VIII, 303-219; XI, 175-194; XII, 37-594;
2. Статьи: в Зап. Вост. Отд. 1) Бартольд, «Коркуд», IX, 272-274; 2) Его же, «Еще известье о Коркуде», XIX, 173-178; 3) Туманский, По поводу «Китабе Коркуд», IX, 269-272; 4) А. Диваев, О могиле свять. Хорхут-ата, X, 193-195; 5) Ditz? Den Wurdigenvon Asien, II, 399.
****Куркоду фигыленнән боерык сыйгасе (сүз формасы – А.Г.), татарча әйткәндә, куркыт-баба булырга тиеш.
***** К. Иностранцев, Коркуд в истории и легенде, стр. 40 (Зап. Вост. Отд. Том 20).

[1]Эрнест Богарт (1870-1958) – Америка икътисадчысы, Иллинойс университеты профессоры.
[2]Бу төрки терминның берничә мәгънәсе бар. Иң борынгысы – эпик хикәятләр сөйләгәндә «чиртеп уйный торган кыллы корал». Шуның белән беррәтгән, М.В. Есинова язганча, төрле мәдәниятләр контекстларында бу терминның «үз-үзен тарихи тотышы» гаять үзенчәлекле. Кайсыдыр төбәкләрдә ул смычоклы (сызгычлы) коралны аңлата, кайберләрендә варган (чирткеч идиофон) мәгънәсендә кулланыла. (Кара: Есипова М.В. История и география распространения древнетюркского термина «кобуз» (музыкальный инструмент)»// Научный Татарстан. – 2013. – № 3. – С. 26).
[3]Борынгы төркиләрдә «озан» сүзе халык җырчысы яки хикәят сөйләүчене билгеләү өчен кулланылган. В. Бартольд искә алган XVII гасыр фарсы-төрек сүзлеген төзүче Шу'ри сүзләренчә, «төрек телендә озаннар дип тамбурда (гитарада) уйнаган Угыз-намә укыган кешеләрне атыйлар». (Кара: Бартольд В. Турецкий эпос и Кавказ// Книга моего деда Коркута. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1962. – С. 114). В.М. Жирмунский язганча, «тамбур» дип домбраны аңларга кирәк...» (Жирмунский В.М. Огузский героический эпос и «Книга Коркута»// Книга моего деда Коркута. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1962. – С. 149).
[4]XII гасыр ахырындагы борынгы рус әдәбияты ядкаре, аның тарихи нигезе 1185 елда Новгород-Северск кнезе Игорьнең кыпчаклар белән сугышуыннан гыйбарәт.
[5]Угыз кабиләләренең язма эпос истәлеге. Бу кабиләләр соңрак төрекмән, әзәрбайҗан һәм төрек халыклары составына керә. Эпосның гомуми эчтәлеге угызларның яулап алынган кавказ җирләрендә хакимлек итү өчен «кяферләр» белән сугышуыннан гыйбарәт. 1922 елда В. Бартольд тарафыннан рус теленә тәрҗемә ителгән (1962 елда басылган).
[6]Василий Радлов (1837-1918) – көнчыгышны өйрәнүче галим, тюрколог, археолог, тәрҗемәче.
[7]Казан татарлары фольклоры турындагы лекцияләрдә: «Шуның өчен шагыйрь-импровизаторларга әзер сюжетлардан, гыйбарәләрдән, җөмләләрдән, эпитетлардан һәм үрнәкләрдән берәр нинди яңа әсәр төзү читен түгел, темалары яңа булса да, эчтәлекләре һәм формалары иске диярлек булып кала», – дип укыйбыз (Мирасханә: ф. 18, тасвир. 1, сакл. берәм. 34. – Б. 113 арты).
[8]«Казан татарлары фольклоры» дигән лекцияләр курсының унынчы лекциясендә Г. Рәхим моның турында болай дип әйтә: «Бу ярышларда ике шагыйрь-импровизатор, берсе икенчесен сүзсез калдырганчы, бер-берсенә карата тапкыр әйтемнәр атышалар (Мирасханә: ф. 18, тасвир. 1, сакл. берәм. 34. – Б. 111-112 арты).
[9]Бу очракта сүз айтыс – ике акынның импровизацион ярышы – турында бара.
[10]Самак – яшьләрне үгетләүче туй җыры.
[11]Сәед Баттал – дин өчен көрәшүче легендар шәхес, урта гасыр госманлы-төрек әдәбияты («Кысса-и Сәед-Баттал газый») герое. Бу әдәби әсәр татарлар арасында кульязма рәвешендә киң тарала, ә XIX гасырдан алып басма әсәр буларак («Сәетбаттал китабы», «Мәнакыйбе Сәетбаттал газый», «Сирәте Сәетбаттал газый») билгеле була.
[12]Мәддах – әкиятләрен каһвәханәләрдә сөйләүче, күчеп йөри торган әкиятче.
[13]«Куркулык кою» йоласы күздә тотыла. Моның турында тулырак мәгълүматны бу җыентыкка кергән «Фольклор һәм халык әдәбиятын җыю өчен кулланма»ның искәрмәләрендә табарга була.
[14] «Чалпу салдыру (салу)» йоласы күздә тотыла. Моның турында тулырак мәгълүматны «Фольклор һәм халык әдәбиятын җыю өчен кулланма»ның искәрмәсендә табарга була.
[15]Күр углы («Гүр-углы») – XVII гасырда барлыкка килеп, Урта Азиядә таралган эпос. Төрекчәдән «сукырның улы» дип тәрҗемә ителә. «Гүр-углы» «кабердән туган угыл» дигәнне аңлата. Аның әнисе, көнчыгыш версиясе буенча, авырлы килеш күмелгән була, әмма баласы туа һәм исән кала, шуның өчен аны Гүр-углы дип атаганнар.
[16]В.М. Жирмунский язганча: «Баюндур-ханның исеме, угызларның эпик башлыгы буларак, төрекмәннәрнең идарә итүче Ак бәрән династиясен барлыкка китергән Баюндур кабиләсенең Якын Көнчыгыш кабиләләре арасында (XIV гасыр уртасы – XV гасыр уртасы) өстенлек иткән чорында гына тарала. Угызлар эпосының борынгы традицияләрендә Баюндур-хан җирлеге юк...» (Кара.: Жирмунский В.М. Огузский героический эпос и «Книга Коркута»//Книга моего деда Коркута. – М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1962. – С. 143-144).
[17]«Коркут китабы»ның кереш сүзендә автор Коркутның тууын Мөхәммәт пәйгамбәр вакытлары белән бәйли: «Аллаһ илчесенә, аңа сәлам булсын, якын вакытта Бәят кабиләсеннән Коркут-Ата исемле кеше чыкты». (Кара.: Книга моего деда Коркута. – М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1962. – С. II)

Чыганак: Гали Рәхим. Сайланма әсәрләр. – Казан: «Ихлас» нәшрияты, 2018, 180-192 битләр.



Мәҗит РАФИКОВ

Йомышчы Әбүбәкер, яки «ни булса, ни була...»

(Хикәя)

I

Бу җир дигән нәрсә бигрәк кадерле шул. Җир өчен адәм баласыниләр эшләмәгән дә ниләр күрмәгән! Күптән булган хәл бу. Ул вакытларда Суша суы буендагы Күгәрчен авылы елганың сул ярында гына утырган әле, уң як ярга канатын ташлап өлгермәгән.

Кызу печән өсте икән.

Күк аяз, көннәр коры тора, тик шунысы аяныч: алтын вакыт заяга үтә! Олы мәчет артындагы җыен өе тирәләре «гү-гү» килеп тора. Җир идәнле, кабык түбәле, ертык карындык тәрәзәле бу «парламент бинасы»на чабаталы агайларның тавышлары гына түгел, үзләре дә сыймаганнар – барысы бергә өерелеп кире ишегалдына чыкканнар.

Җыены да гади җыен түгел: биш авылның картлары, атларга төялеп, Күгәрченгә килгәннәр. Алты авыл җыены бу. Могтәбәр картлар өй саен иганә дәфтәрләренә тамгалар куйдыра-куйдыра җыйган акчаларын ак тастымалга төреп алып килгәннәр.

Йомышчы «хадук»ның сәфәре ерак буласы – пайтәхетнең үзенә үк...

Кама буе болыннарында үлән дигәнең тездән түгел, билдән болай җиткән. Агайлар, шул үләннәрнең төмен дә татып өлгермәгән чалгыларын ташлап, җыенга ашыкканнар. Җыен өе ишегалдында – шау-шу, колагың тонар. Чебиләгән тәпиле малай-шалай кайсысы кояштан бер күзен кыскан, кайсысы авызын ачып ияген кыйшайткан, читтән генә карап тора.

II

Кама буе Кызыл тау аслары – элек-электән әлеге алты авылның чабынлыклары булган алар.

Карчыга борын алпавыт Стрекалов – ачкүз! – үз авылы халкын хәер-чегә калдыруы, кызларын мәсхәрәләве җитмәгән, инде кеше болыннарын тартып алмакчы! Алты авылның чабынлыкларында көтү-көтү үгез-бозау симертеп Казанга озатып кына ятасы... Быелтыр булды былтыр, пистолетын шартлатып, югарыгы баштан бозауларын җибәртеп, күпме халыкны печәнсез калдырды. (Үзенең һәрбер бозавын закон саклый!) Ә быел Мәликә күле башына ук чыгып юлны баскан. Үткәрми! Өяздән атлы стражниклар чакырткан, чөгендер борынлы становой пристав майлы мыекларын сыйпый, каш астыннан бүредәй карый...

Ул карчыга борын өяздә дә, губернада да бөтен җир-болын язуларын күптән актарып карап чыккан инде, кешеләрен майлый-майлый... Губернаның Казенный палатасын да үз ягына аударды инде, ахрысы... Берәү рәхәт кенә көтү-көтү мал сатып, акча сугып ятсын да, монда синең кышкы челләдә яшь бозавыңа бәйләп эләр үлән яфрагың булмасынмы? Авыллар атсыз-сыерсыз калсынмы?! Йә, кайсы закунга сыя бу?!

III

Бер карасаң, бу җыен – бәхетле җыен әле. Үзенең Әбүбәкере бар. Әбүбәкер Солдат, әрсез балта сабы, русчага шомарып кайткан, сулдан уңга каләм йөртә белә. Үзе таза, гайрәтле: ак патшага егерме биш ел хезмәт итеп кайткач, сабан туенда Үгез Сәләхне әйләндереп салды, үзе тапкыр, зирәк. Бүтәннәр керә алмас җиргә ул керер, бүтәннәр булдыра алмасны ул булдырыр. Бертуган энесе Мөхәммәтҗан ахун да Әбүбәкергә «Шәкерт абый» дип зурлап кына эндәшә. Әбүбәкер Солдат булмаса, кем бу татар җәмәгатенең сүзен санат хәтле санатка үткәзерлек итеп язар да, кем аны шундый югары урынга җиткезергә алынып иде?..

Кибеп-корышып беткән Габделлатыйф карт шау-шуны тыймакчы. Сүзне аны каләмгә элеп теркәп ялгарга да кирәк бит. Әбүбәкергә

кыендыр. Кырык кеше кырык яктан колагына горголдап торсын әле...

– Гатау кода, тавышың дөнья каплый. Әкренрәк сөйлә әле... Хамматхан кияү, син дә...

Картны ишетмиләр. Шау-шу үзлегеннән басыла тешә.

Әбүбәкер имән түмәргә утырган, шыгырдавык өстәлгә ике беләген салган, каурый каләмен түш төймәсенә бәйләп алган тар авызлы шешәсенә манып-манып яза.

«Хөкемфәрма Сенат комиссиясенә.

18... сәнә, без Казан губерниясе Лаеш өязе Урахча волосте Күгәрчен, Түбән Тегермәнлек, Югары Тегермәнлек, Ямаш, Балтач, Күки авыллары дәүләт крестьяннары шушы пригавурны бер сүздән төзедек ки, Городок алпавыты Стрекалов безнең Кама буе Керәүшә суы тамагындагы чабынлык болыннарыбызны тартып алды. Печән чаба алмыйбыз, атларыбыз вә башка терлекләребез бетеп бара. Генеральный межеваниегә кадәр авылларыбызда халык азрак иде, болыныбызны вакытлыча файдалануга өлешләп сатып тора идек, инде хәзер алпавыт Стрекалов безгә акча түләү түгел, әлеге болыннарга үзебезне җибәрми, тиешле кәгазегез юк, ди. Әмма бу болыннар элек-электән безнеке. Ата-бабалардан буыннан-буынга мирас булып кала килгән үз болыннарыбыз. Без 18... елны да, дәхи аннан соң да губерна Казенный палатасына гозеребез белән мөрәҗәгать иткән идек, беренче тапкыр карар дөрес чыкмады, икенчесенә инде өч ел җавап юк.

Шушы пригавур белән Хөкемфәрма Сенат комиссиясенә мөрәҗәгать итсен дип, Әбүбәкер Биккенә утлы Зәетовны ышанычлы вәкил вә йомышчыбыз итеп сайладык. Каләм тотучыларыбыз кул куя, тота белмәгәннәребез тамгаларын сала...»

Герблы бер сумлык зәңгәрсу кәгазьгә ике-өч кенә исем уңнан сулга сырлап куелгач, өч багана булып бер-бер артлы култамгалар тезелде: менә тәпәче читкә авышкан чабагач шикеллесе, менә өч япьле сәнәк кебеге, башына саескан кунган багана сыманы...

Эшлияче Шәйминең Казанда үз йомышы да бар икән, җирән атын Мөхәммәтҗан ахунның җиңел тарантасына корып алды да Әбүбәкер Солдатны ерак сәфәргә озата китте.

IV

Әбүбәкер, йомры баш, Сенат канцеляриясенә беренче кат ишек ачып кергәнче, җиде көн буена олы йомышына кечкенә булса да теләктәшләр эзләде, эш йөртү юлларын өйрәнде. Йөзе ачык, кулы юмарт иде. Үзе кебек «хадук»лардан кайсы бүлмәләргә кереп, ничек йомыш йомышлауларын сорашты.

Канцеляриягә керер көнне сакалын китәреп, мыегын бөтереп җибәрде, шинель итәге белән искергән итекләрен ышкып ялтыратты, солдат фуражкасын башына кырынрак салып киде. Канцеляриягә (аны «присутственное место» дип тә атыйлар икән) җиңел адым, кыю караш белән, май ярган пычактай шома керде керүен дә... чыгуын шома гына чыга алмады... абынды, төрмәгә үк эләкте...

Сенат кадәр сенатның елкылдап торган палаталарында да күзгә күренмәс биек бусагалар бар икән, «уңдым» дигәндә акча салмасаң, йөзтүбән капландыра икән...

Һаман шул наданлык! Үзең императорский указларны укыштырган акыллы баш бул, авыл сине күз өстендә каш кебек күрсен, үзең, Алла колы, сенатның саф дөрес карарын сәмруг кошлы кәгазьгә күчертеп сиңа тоттырасы обер-секретарьның ак кулына «алтын йөгертә» белмә, имеш!..

Сенатның тәфтиш комиссиясе күреп тора: болыннар алты авылныкы. Бу хактагы язулар хәзер «табылмаса» да, алар барыбер булган, бар, мәсьәлә көн кебек ачык. Тәвәккәл алпавыт хәйлә ятьмәсен киң ташлаган: мөхтәрәм губерна хөкемдарларыннан да үз карарын яздырып мөһер суктырып ала белгән... Әмма... бунт кубачак бит... Ярамый!..

Сенат комиссиясенең итләч шома битле, калын гәүдәле обер-секретаре карар язуын алты авылның ышанычлы вәкиленә тапшырыр алдыннан, ике күзен тондырып, аңа озак кына, таш бәгырьле юлбасардай карап утырды, йомышчы «хадук» күзен читкә алмады, туры карады, әмма елмаеп, йомшап китеп, кесәсеннән янчык та чыгарып атмады. Әллә инде бу вәкил кеше турылыкның да кыеклап йөрүен белми иде...

Обер-секретарь озын ак каурыен ялтырап торган җиз савытка манып, карар кәгазенең буш бер юлына ике-өч кенә сүз өстәп куйды да аягүрә басып карарны йөгертеп укып чыкты. Укуын дөрес укый хәерсез: болыннар алты авылныкы...

Моңарчы русча язу танымаган булып маташкан Әбүбәкер Солдат ка-рарны алгач та, ябырылып укый башлый бит! Ни күзе белән күрсен: буш юлга алты авыл урынына алпавыт Стрекалов исеме язып куелган...

Җан ачуы куба Әбүбәкернең, үзен тыя алмыйча, китереп сала берне ак битле обер-секретарьның яңагына.

– Пыччаму нипрабильно писал? Машшинник!..

V

Ике газраилдәй ике Җантимер горур дәгъвачыны саңгырау диварлы бер соры йортка алып килеп, тимер ишектән кертеп җибәрәләр, тышкы якта зур йозак шалтыр-шолтыр килеп бикләнә.

Калын ла икән Әби патша салдырган хәбесханәнең стеналары, салкын да икән таш идәннәре, биек лә икән рәшәткәле тәрәзәсе...

Ришвәтче хөкемдар! Шатланып калгандыр әле. Каты суктың, янәсе, ярар, аның каравы үкенечең ачырак булыр, болын кирәк булса, горур башыңны иеп кире килерсең әле...

Әбүбәкер кайгыда. Ай, надан халык, кара сарык... Юллык сума җыеп бирә белгәннәр, императорский сенатка ришвәтлек җыя белмәгәннәр...

Айлар үтә, еллар үтә. Чыга Әбүбәкер төрмәдән. Җәйге көнне прошпекттан барганда каткан такыясын салып бер ишек пыяласына карап тора: кара сакалы агара башлаган, куе чәче сирәгәйгән. Үзе эчтән шатланып куя: әле ярый Себергә олактырмаганнар, шушында, санатлы пайтәхеттә генә утыртканнар! Югыйсә бит, егетләр, кире килеп йөреп булмас иде...

Бер графта ат караучы булып, өс-башын бераз төзәтеп алгач, йомышчы Әбүбәкер янә санатка бара, теге шома битле обер-секретарьны янә бер күреп кайта да хезмәтчеләр өендә каләмен тотып бер почмакка хат язарга утыра.

Озак кына баш ваткач, кыска гына сүз сырлап, исемен теркәп куя: «Нигә ни кирәк, ни булса, ни була. Әбүбәкер Биккенә угылы».

Хатны түләп алулы итеп, энесе Мөхәммәтҗан ахун исеменә җибәрә.

VI

Мөхәммәтҗан ахун Балтачка киткән булган икән, Күгәрченнән бер малай ат менә дә артыннан чаба.

– Ахун абзый, сөенче! Шәкерт бабайдан хат килгән!..

Йомышчы «хадук»ларыннан өмет өзгән авыл картлары тагын Күгәрченгә җыела.

Хикмәтле хатны укыйлар, кулын таныйлар. «Була» сүзен күргәч, сүнгән дәртләре кабынып китә! Алты авыл, дәфтәрләргә тамгалар тездереп, икенчели акча җыя...

Ярый, җыйдылар, инде ничек җибәрергә? Йомышчы белән, дисәң, аңа янә юллык акча кирәк... Юлда үзен таласалар?..

Эшлияче-камытчылар – Күгәрчендә, чүлмәкчеләр – Олы Көл белән Гремячийда, дугачылар – Тегермәнлектә, көмешчеләр-коемчылар – Балык Бистәсендә... Ә бит менә генә торган Урахча русында тимерче-калайчылар бар!..

Күгәрченнән бер карт тимерче алачыгына килеп керә.

– Драстуй, Ыстапан Басилич! Адин харуши кумган ыздилай!..

Алты авыл картлары җыйган сумаларын яңа комган төбенә тыгызлап салалар да, өстеннән икенче төп каплап ямыйлар, – тот та су тутыр, тәһарәт ал!

Китә мөселманның гөнаһсыз комганы почтовый белән Санкт-Петербургка... императорский санаттан алты авыл болынын йолып алып кайтырга...

VII

Әбүбәкер ишектән килеп кергәч тә, кесәсенә бер сугуы була, авыр гәүдәле обер-секретарь ялтыр креслосыннан сикереп тора, шома гына хәрәкәт белән бикле шкафын ачып, яңадан күчереп язган карарны китереп чыгара.

– Бир... Мә укы...

Йомышчы язуны сабырсызлык белән бер күз йөгертеп чыга, икенчегә аерым юлларын кайта-кайта күздән кичереп укый.

Кәгазьне кыштырдата-кыштырдата дүрткә бөкләп, керләнгән кульяулыгына төреп куен кесәсенә тыккач, шинеле өстеннән бер сыйпап ала да, кинәт авыр сулап: «Менә бит, малай, ә!..» – дигән сымаграк, чал кергән башын чайкап тора. Аннары, хөкемдарны бар дип тә белмичә, ялтырап яткан паркет идәнле бу бүлмәне, алтын рамдагы император портретын, онытмаска кирәк әле бу алтын сарай кетәкләрен, дигән сыман, үткен күзләре белән бер сөзеп карап чыга да, берсүзсез, җиз тоткалы биек ишекне киң ачып, горур кыяфәт белән чыгып китә.

VIII

Әбүбәкер карарны исән-сау алып кайтып җиткергән. Шуның рәхмәте белән генә алты авыл крестьяннары кансыз алпавытның тырнагыннан ычкынып калганнар...

Күгәрчендә өлкәннәр әле дә сөйлиләр, элек, Йомышчы Әбүбәкер якты дөньядан киткәч, авылның кайбер динлерәк картлары, иртәгә Керәүшә тамагына печәнгә төшәсе дигән көнне кичке намазда горур Йомышчы рухына өчәр рәкагать дога кылганнар, имеш: авыр туфрагы җиңел булсын, янәсе, нәсел-ыруының рәхмәте артсын...

...Комган төбенә ышереп хөкемфәрма сенатка взятка җибәргән авыллар хәзер, әлбәттә, күптән инде колхоз авыллары. Җир аларга Ленин Декреты буенча бирелгән – һичнинди түләүсез мәңге файдалануга... Күрше алпавытларының җир биләмәләре дә киселгән аларга.

Гражданнар сугышы фронтларында бу авылларның һәркайсыннан дистәләрчә, хәтта йөзләрчә ир-егет Совет власте өчен сугышкан. Берәвесе әле унҗиденче елны штурм белән Зимнийны алганда ятып калган, диләр.

Суша Күгәрчененә килгән саен, басуларын-кырларын бер карап әйләнгәч, мин авылның зиратына, музейханәгә кергәндәй кереп, кабер ташларын бер карап чыгам. Карт каеннар арасындагы сырлап-бизәп язылган ташларда борынгы болгарларның таш язу алымнары төсмерләнә.

Ярчылган-кыйпылган, ауган ташлар да бар анда. Язуларын яшел мүк сарган, кырып чистартмыйча аерырлык түгел. Зәетовлар үзләре бер оядарак җирләнгәннәр. Йөз дә ун яшь яшәгән Биккенә карт ташы бар, Мөхәммәтҗан ахун ташы бар, аның улы, заманында губернада дан тоткан педагог мәгърифәтче Ризаэтдин учительнең дә ташы бар.

Ризаэтдиннең кече улы Исмәгыйль Зәетов хәзер Мәскәү университетының география факультеты педагогы, илнең күренекле бер галиме. Исмәгыйль ага беркөнне үз фатирында миңа бронзадан эшләнгән Нефертити башын күрсәтте. Язулы. Каһирәдән килеп укыган бер гарәп егете диссертациясен яклагач бүләк иткән. Исмәгыйль ага ул яшь галимнең фәнни җитәкчесе булган икән. Йомышчы Әбүбәкернең нәселдәше...

Әбүбәкернең үзенең кабер ташын тапмадым.

Ташы булыр иде, башы ерак юлларда югалган, диләр.

Кайсы якларга, җыенның нинди йомышы белән соңгы сәфәренә киткән ул, кай җирләрдә гомере өзелгән – боларын миңа беркем дә әйтә алмады.

1970

НЫРСЫ ЯГЫ МӘЗӘКЛӘРЕ

Әхмәтҗанга рәхәт

Гыйләҗев Әхмәтҗан абый гомер буе ат җигеп фермада эшләде. Эшкә бик әрсез, авыр эштән курыкмый торган кеше иде. Малларга печән, силос, салам ташый. Төшке ашка өенә кайтып бераз ял иткәннән соң, кичке якта, чанасына йә арбасына сәнәген ташлап, тагын фермага юл ала. Берничә йорт аша яшәүче күршесе Нурулла абый мәктәптә каравылчы булып эшли. Беркөнне атына утырып киткән күрше Әхмәтҗан абый артыннан озак кына карап тора да бу капка төбендә утыручыларга зарланып ала: «Әхмәтҗанга рәхәт аңа, атка утырган, сәнәген салган, фермага бара. Менә каравылда читен, тегеләй ятып карыйсың, болай әйләнеп карыйсың. Бөтен гәүдәләр ватылып бетә».

Оҗмахка алып керәсе кәҗә

Нырсыда бөтен кеше дә «Әпел бабай» дип йөрткән (чын исеме Габделгани бабай) мәзәкчән генә кеше яшәгән. Бер елны ул корбанга кәҗә суярга уйлаган. Шуңа күрә кәҗәне, көтүгә кумыйча, арканда гына тота икән. Кәҗәсен арканлаган җирдән өенә алып кайтканда, тегесе киреләнә, аяк терәп каршы тора, ди. Бабайның тәмам ачуы чыгып, кәҗәгә ачулану сүзләре яудыра икән: «Ну, кәҗә, карчык белән мине оҗмахка алып кермәсәң, иманыңны укытам мин синең!»

Сугуын сукмый

Ике кулына ике чиләк тотып суга баручы Мөхәммәтхан абыйга күршесе очрый: «Нәрсә, Мөхәммәтхан абый, сугамы?» – ди бу. «Сугуын сукмый, ну эшләтеп үтерә инде, малай», – дип җавап бирә тирә-якта шаянлыгы, сүзгә кесәгә кермәве белән дан тоткан Мөхәммәтхан абый.

Теләче районы.

Чыганак: Нырсуар, Нырсы җире – шанлы изгеләр иле, Казан, «Ак бүре» нәшрияты, 2017, 203 б.

Нажия ГЫЙМАДИЕВА

Ал яулык, зәңгәр шәл, узган гомер бигрәк җәл...

«Түгәрәк уен»ның узган санында дөнья күргән «Хатын-кызның күрке – яулык» дигән язма (авторы Тукай районыннан Заһидә Нәбиуллина) яулык һәм шәлләр белән бәйле әллә никадәр истәлек-хатирәләремне уятты.

Шуларның берсе безнең гаилә белән бәйле.

Авыр сугыш еллары. 1943 елда Ленинград оборонасын кичкән әтием, яраланып, берничә ай буе Чита шәһәрендәге госпитальдә дәвалана. 1944 елның язында аны, яралары төзәлер-төзәлмәс хәлдә, туган ягына (Лаеш районының Саралан авылы) озаталар. Кайтыр юлы бик ерак була. Госпитальдәге олырак кына хәрби доктор яралары бихисап булган әтинең исән-сау кайтып җитә алуына икеләнә, борчыла. Аның сугышчыга ничек тә ярдәм итәсе дә килә. Тырыша торгач, юлына бераз азык-төлек бирдерүгә ирешә. Алар арасындагы берничә башлы шикәрне әти балаларына (анда аны 6 кызы көтә!) күчтәнәчкә дип уйлап куя. Доктор, яралары ачылып китү очрагын фаразлап, бәйләү материаллары белән дә ярдәм итә. Шул материаллар арасында шактый зур ап-ак җәймә дә (простыня) була. Кайту юлы бик авыр була, поездларга эләгү кыен, этеш-төртеш, шунлыктан, азык-төлектән тыш, бинт-йодлар да тотыла, әмма әти биштәрендәге ике шакмак шикәренә һәм ак җәймәсенә кагылмый. Җәймәне берничә тапкыр ипигә алмаштырыр хәлгә җиткән чаклары да була, әмма, күз алдына балалары килеп, яңадан биштәренә салып куя.

Шулай итеп, ул авылга, гаиләсе янына кайтып җитә. Кызларының берсе, төпчеге, фаҗигале рәвештә вафат булган... Төн вакыты булса да, әти биштәрендәге шикәрләрен кызларына ватып бирә. Әниебез әти алып кайткан җәймәдән 5 кызына өч почмаклы яулыклар (косынкалар) ясый, бераздан соң аларны зәңгәр төскә манып та бирә. Җәймәнең озынча бер өлеше артып кала. Әни анысыннан үзенә яулык ясый (андый тар, озынча яулыкларны тастар дип йөрткәннәр). 1945 елда әни шул яулыкны бәйләп фотога төшкән.

Әни турында сөйли башлагач, тагын шуны да әйтеп үтәсем килә. Ул һәрвакыт ак, чиста яулыктан йөри иде. «Алмашка яулыгым юк, һаман бер яулыктан йөрим, әкаралганны бәйлисе килми. Иртән көтү куганда, һәркемне энә күзеннән үткәрәләр: хатын-кызга шунда бәя бирәләр. Җаен таптым: кичен яулыгымны юып элам, иртән сырлы бәләк белән үтүклим дә көтү куарга чыгам. Тора-бара яулыкны кызларым ук юып куя башладылар. Урамда да шәйләгәннәр, ахры, яулыкларымның «күплегенә» гаҗәпләнүчеләр дә булды. Бар иде заманалар... Барысын да кешегә сөйләп йөреп булмый. Хәзер яулыкларның ниндие генә юк?!» – дип сөйли иде ул. Олыгая башлагач, әни ачык җирлеккә зур ачык чәчәкләр төшкән яулыкларны яратып бәйли иде. Кунакка барганда, җилкәсенә энисеннән калган ефәк шәлен дә сала иде. Фотода әнием Шамил атлы оныгының игезәк кызлары тугач, алар бүләк иткән шәльяулыктан (1983 ел).

Яулыклар белән бәйле нинди генә вакыйгалар юк икән уйлап карасаң! Шулай бер вакыт 87 яшьлек Зәкия апамның фотоларын карап утырам. Зәкия апамның каенанасы – Миннегайшә кодагый әбинең фотосына юлыктым. Мине ире сугышта һәлак булган тол хатынның байлар бәйли торган зур затлы яулыгы кызыксындырды. Мондый яулык аңа ничек килеп эләккән икән? Тарихы гыйбрәтле булып чыкты.

Кодагый әбинең Рабига исемле кызы, ир баласы белән, иреннән аерылып әниләре янына кайта. Үзе авыл кибетендә кибетче булып эшли. Бер вакыт авылга рабкооптан ревизор килеп төшә. Ул (фамилиясе Спиридонов булырга тиеш диләр) тирә-юнь авыллары кибетләрен дә тикшерәчәк икән, әмма фатирда безнең Саралан авылында торачак. Агентны (авыл халкы тикшерүчеләрнең барысын да шулай дип йөрткән) байлар нәселеннән булган Мозаффар Фатыймаларына урнаштыралар. Тикшерүченең кибеттә эшләүче яшь хатынга – Рабигага күзе төшә, властеннан файдаланырга өметләнсә дә, хатынның исе китми. Агент Рабиганың энисе аша эш итәргә уйлый. Тик ничек? Бу сорауга җавап табыла: хатынның энисенә бүләк бирергә! Әмма андый бүләк башкаларда

булмасын. Кайдан алырга соң андый бүләкне дип аптырап йөргәндә, җае да табыла. Бер көнне фатир хуҗасы Фатыйма апаның сандыгы бикләнми кала. Өйдә кеше-кара юк чакта агент сандыкны ачып карый: яулыкларның ниндие генә юк анда! Агент өстә яткан чәчәкле зур яулыкны сайлый. Инде аны тапшырасы гына кала.

Сабан туйлары якынлаша. Җаен туры китереп, агент Миннегайшә апа янына килә, аның кызына яхшы эшләгәне өчен рабкооптан бүләк бирүләрен әйтеп, яулыкны тапшыра. Рабига бик ышанып та бетми бу сүзләргә. Шулай да яулыкны калдыра, әнисенә бәйләп йөрергә куша.

Миннегайшә апа яулыкны Сабан туена бәйләп чыга. Бу көнне авыл бәйрәменә фотограф та килгән була. Ул искитәрлек матур яулык бәйләгән апаны оныгы белән карточкага төшерә. Вакыйга шулай шатлык белән генә тәмамланса икән ул. Юк шул. Миннегайшә апаның башындагы яулыгын Фатыйма апаның кызы Мәрзия күреп ала һәм бу турыда әнисенә җиткерә. Алай гына да түгел, Миннегайшә апаны караклыкта гаепләп, бөтен кеше алдында фаш итәргә өнди. Һәр нәрсәне уйлап эшләргә өйрәнгән Фатыйма апа кызына алай эшләргә ярамавын, Миннегайшәнең андый хатын булмавын аңлата. Алар Миннегайшә апаны читкә чакырып алалар. Ул исә хәлне сөйләп бирә һәм башындагы яулыгын, берсүзсез салып, хуҗасына тапшыра. Яулык, билгеле инде, фотода мәңгеләшә. Тиздән теге ревизор да авылдан китеп югала.

Калын шәлләр белән бәйле истәлекләрем дә бар икән әле.

Монысы инде икенче кодагый әбием, әтинең сеңлесе Рабига апамның (без аны «нәнә апа» дип йөртә идек) каенанасы Бәдриҗамал фотосы белән бәйле.

Әсәт җизни сугышның башыннан ахырына кадәр фронтта була. Өенә 7 елдан соң гына әйләнеп кайта. Белоруссия сазлыкларында үпкәсенә салкын тидерә ул. Озак кына кыр госпитальләрендә дәвалана. Аннары тагын сугыш юлларын дәвам итә. Ләкин авыруы һәрвакыт үзен сиздерә тора. Дәвалануның да нәтиҗәсе күренми. Бер белорус хатыны аны үзенчә дәваларга тырыша: аякларына үзе бәйләгән оекбашларны кигезә, калын шәлен бирә, салкын тиюдән сакланыр өчен, шәлне һәрвакыт үзе белән йөртергә куша. Чынлап та күп салкыннарда җылыта аны бу калын шәл. Җизни шәлне үзе белән алып кайтып әнисенә бирә. Кодагый әби улының бүләген кергән бер кешегә күрсәтеп мактана. Кунакларга баргач та: «Әсәдуллам сугыштан алып кайткан бүләк», – дип, горурланып сөйли торган була. Шәл юрган вазифасын да башкара: онықларын мунчадан шул шәлгә төреп алып чыгалар, йоклаганда өсләренә дә ябалар.

Миннегайшә кодагый оныгы Роберт белән. 1952 ел.

Бәдриҗамал кодагый (уңнан беренче), оныгы Нурания (артта), апасы (исеме Хөснижамал булырга тиеш, артта шәл бөркәнгән) һәм улы Әсәдулла гаиләсе белән. 1951 ел, февраль.

Шәл белән бәйле тагын бер вакыйганы искә төшереп үтәсе килә. Минем әниемнең әнисе, 18 яшьлек улы белән, кулак тамгасы тагылып, Магнитогорск шәһәренә озатыла. Әби бер елдан соң кайта, ә Хәбибулла абый гомере буе металлургия комбинатында эшли. 30нчы елларда илдә стахановчылар хәрәкәте киң колач ала. Алдынгы стахановчыларга бүләкләр тапшыралар. Хәбибулла абый да лаек була ул бүләккә. Аңа зур калын шәл бирәләр. Шәл аларга шулай ук озак еллар хезмәт итә. Авылдан сөрелүләренә 40 ел булганда, Хәбибулла абый туган якларына кайтып килә. Шул вакыт ул өч апасына бүләк итеп матур яулыклар алып кайта. Минем әнигә теге калын шәлне дә алып кайтырга онытмый. Хәзер ул шәл миндә саклана.

Заманалар үзгәрә, тормышлар ямьләнә. Хәзер инде язып яулык бәйләүләр өлкән әбиләргә генә күчә бара. Алар ап-ак яулык белән бергә иңнәренә ап-ак шәлләрен дә салырга онытмыйлар. Ак тәскә беркайчан да тап төшермәгән апа-әбиләр...

Мари иле моңнары

Әлеге җырлар Татарстан Республикасының мәдәният министрлыгы каршындагы Татар фольклорын җыю, саклау, өйрәнү һәм пропагандалау дәүләт үзәге тарафыннан 1996 елда Мари Эл Республикасының Бәрәңге районына (Параньгинский район) оештырылган экспедициядә (экспедиция җитәкчесе К.М. Хөснуллин) язып алынган иде.

Әлеге районда яшәүче татарларны фәнни әдәбиятта «бәрәңге татарлары» дип атыйлар. Аларны мәдәни үзенчәлекләре җәһәтеннән казан татарларының казан арты төркеменә кертеп карыйлар. Территориаль яктан беркадәр аерымланган хәлдә яшәүләренә карамастан, бәрәңге татарларының сөйләме Дөбъяз татарлары сөйләменә бик якын.

Бәрәңге татарларының килеп чыгышы әле тулысынча өйрәнелмәгән булса да, кайбер мәгълүматлар буенча, алар әле территория Мәскәү дәүләтенә кушылганчы ук казан татарлары марилар арасында оештырган сәүдә колониясенең бүгенге буыны дип уйларга нигез бар.

Экспедиция язмалары арасында Портянур авылында яшәүче Гөлсылу Ситдыйковадан язып алынган мәгълүмат бар. Гөлсылу ханым аларда XX гасыр башы Сабан туйларындагы яшьләр уеннарының берсе – «Урта казык уены» турында сөйли. Елдан-елга үткәрелеп килгән яшьләр уеннары исә, гомумән, казан арты татарларының бәйрәм мәдәнияте өчен характерлы үзенчәлек булып тора.

Этнограф, тарих фәннәре кандидаты Рәмзия Гыйният кызы МӨХӘМӘДЕВА

Озату җыры



Килә болыт, килә болыт, килә болыт күкерәп,
Авыр булса да хәсрәт, күтәрә яшь күкерәк.

Урсам уракларым үтми сәчкән каты җирләргә,
Җибәрсәм сәламем җитми киткән ерак илләргә.

Карурманда бик күп йөрдем төлке эзләре белән,
Үзгәрттең син күңелеңне кеше сүзләре белән.

Портянур авылында Былбылилназ Абдулхак кызы Абдуллинадан
Котдус Мирзасалих улы Хөснуллин язып алган.

Портянур авылы көе



Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җырлыйк әле җырларны шул,
Сахраларга чыгып чәчәм
Башымдагы моңнарны.

Җырласак та, уйнасак та
Гармун кулларыбызда шул,
Алсу гөлләр чәчәк атсын
Йөргән юлларыгызда.

Алма пешкән, өзелеп төшкән,
Күгәрчен башын тишкән шул,
Матур кызлар сайлый-сайлый,
Чәчләренә ак төшкән.

Гөлсылу һәм Мөбарәк Ситдыйковлардан
Котдус Мирзасалих улы Хөснуллин язып алган.

Компьютерда Дания Арсланова җыйды.

Зөлкатә

(Башы 22нче биттә)

Олы Нырсы үзенең бик борынгы, бай тарихы белән танылган авыл. Әлбәттә, анда кереп чыккан кыска арада гына бу авылның тарихын күзаллап, авыл тормышын тулысынча күреп, аңлап бетерергә мөмкин түгел. Бу сәяхәтебездә безне кызыксындырган урын – авыл янындагы Изгеләр зираты иде.

Олы Нырсы һәм Бичер авыллары арасында урнашкан борынгы зиратны бу якта «Зөлкатә» дип йөртәләр. Чыганаклардан күренгәнчә, Зөлкатә (Зөлхи ата) XVII гасырда яшәгән Зөлмөхәммәт исемле тарихи шәхес. «Зөлка ата», «Чүлкә ата» дип тә йөртелгән бу кешенең Тәтеш-Буа тирәләрендә яшәгән Богдан Чеменеев исемле морзаның улы булуы билгеле.

«Кайбер риваятьләрдә Изгеләр зиратында Зөлмөхәммәтнең өч кызы җирләнүе турында искә алына, – дип сөйләде безне озата йөрүче авыл китапханәчесе Ләйсән Гыйниятова. – Казан алынгач, Зөлхи ата Нырсы якларына килә. Тик монда да дин хакына каты сугышлар була. Дошманнар килгән чакта Зөлхи атаның намазлык өстендә утырган кызларын – Шаһидәбану, Заһидәбану, Сәгыйдәбануны урыслар кылычтан үткәрәләр. Бу хәлгә ярсыган Зөлхи ата ир-атларны канлы көрәшкә күтәрә. Изге сугышта шәһит киткәннәрне шушы зиратка хөрмәтләп күмәләр, соңыннан халык бу каберлекне «Изгеләр зираты» дип йөртә башлый».

Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, әлеге вакыйгалардан соң Зөлхи ата Нырсы авылыннан күчеп китә, хәзерге Әлки районының яңа Чаллы авылына нигез сала. Аның уллары Идрис белән Юныс шунда туып үсә, алар да әтиләре шикелле үз чорларының атаклы суфи шәехләре булган. Халык арасында «Хәлфә бабай», «Шәкерт бабай» дип йөртелгән Идриснең дәвалаучы булуы да мәгълүм. Халык аларны изгеләр дәрәҗәсенә күтәргән.

Изгеләр зиратында бүгенге көндә өч кабер ташы сакланган. Аның икесе югарырак якта, калын тимер рәшәткә белән уратып алынган. Бу ташлар эпиграфик истәлекләрне өйрәнүче галимнәребез, шул исәптән күренекле галим, академик, филология фәннәре докторы М. Әхмәтҗанов тарафыннан укылган. Аның билгеләвенчә, әлеге зираттагы ташларда искә алынган мәрхүмнәрнең исемнәре Казан ханы Сәхиб Гәрәй тарафыннан 1523 елның 3 гыйнварында Тарханлык ярлыгы бирелгән затларның исемнәре белән туры килә. «Бу ике таш бер үк нәсел вәкилләренә куелган, – дип яза М. Әхмәтҗанов. – Ташларның беренчесе һиҗри 847, милади 1443 елның июнь аенда вафат булган Йосыф Шәйех углы кабере өстенә куелган. Ташның үлчәме 20х59х110 см. Ташбилгегә гарәп һәм татар телләрендәге язмалар уелган. Ташбилгенең «тимпан» дип аталган өске йөзлегендә алтыпочмаклы Давид йолдызы уеп ясалган. Ташның түбәсендә «җан кошы» өчен су җыела торган уенты да уелган. Ташбилгедәге ун юлның алтысы гарәп телендә, ул Коръән аятләреннән һәм хәдис үрнәкләреннән гыйбарәт. Калган дүрт юлдагы текст татар телендә бирелә: «... Тарих сәкиз йөз кырык йттидә, сәфәр айының горрәсендә (календаренда. – М.Ә.) ирде, Йосыф ибне Шәйех дарел-фанидин дарел-бакыйа рихләт кыйлды. Гафир (гафу итүче) Аллаһ ля вә ля-вәлядин (тудыручыларны. – М. Ә.)». («Нырсуар, Нырсы җире – шанлы изгеләр иле», Казан, «Ак бүре» нәшрияты, 2017, 15-16 битләр.)

Ташбилгегә уелган алтыпочмаклы йолдыз безне гаҗәпләндерде. Ни өчен андый билге уелган соң бу ташка? Мондый билгеле кабер ташларын Кырымда, Чуфут-кала янындагы караимнар зиратында күргән идек. Анысы аңлашыла, телләре төрки булса да, караимнар яһүди дине тарафдарлары. Ә монда?.. Бу соравыбыз ачык калды.

Икенче ташбилге 1472 елның 6 декабрендә вафат булган Мөхәммәт углы Әйүб кабере өстенә куелган.

Астарак тимер рәшәткә белән уратып алынган каберлектә, сигез баласы белән бер ана күмелгән, диделәр. Аның өстендә дә ташбилге сакланган. Изгеләр зиратында инде башка ташбилгеләр юк, кабер урыннары да билгеле түгел.

Шактый зур мәйданны биләгән зират өстендә рәт-рәт булып утырган агачлар игътибарыбызны җәлеп итте. Алар бер дә аерым кабер өсләренә утыртылган агачларга охшамаган иде. Әлеге агачлар турында сораштыра башлагач, вакытында Изгеләр зиратын карап-тәрбияләп торган гаҗәеп кызыклы шәхес турында белдек.

«Нурмөхәммәт бабай утырткан агачлар ул, – диделәр безгә. – Заманында бу зиратны Сәлмән хәзрәт тәрбияләп торган. Аның

вафатыннан соң зиратны алай карап торучы булмый, урыны-урыны белән коймалары авып төшкән зиратка маллар кереп йөргән.

Узган гасырның 70 нче елларында Олы Нырсыга Уфа якларыннан Нурмөхәммәт Мәннәпов дигән кеше кайтып төпләнә. Зәйтүнә исемле хатынга йортка кереп яши башлый. Иң элек ул чишмәләрне чистарта, аннан картаеп ауган агачларны зираттан чыгарып, яндыра. Тик кемнәрдер, Изгеләр зиратында башбаштаклык кылып йөри, дип аны гаеплиләр, хәтта иптәшләр суды оештыралар. Суд материаллары Олы Нырсы җирлеге архив документлары арасында әле дә саклана икән. «Ул агачлар черегән, күбесенә аву куркынычы яный. Берне киссәм, йөзне утыртам бит мин, – ди Нурмөхәммәт Мәннәпов судка җавабында. – Зинһар дип үтенеп сорыйм, минем бу эшемне гаеп күрмәгез». Нурмөхәммәт бабай беркемнән ярдәм сорамыйча, зиратны койма белән әйләндереп ала, коймаларны буяп та куя. Нырсы урманыннан үсентеләр алып төшеп, зират эченә рәт-рәт итеп утырта».

Чыгышы белән Нурмөхәммәт бабай Балык Бистәсе районының Олы Тегермәнлек авылыннан булган икән. Өйләнгән, хатыны белән бер кыз, дүрт малай тәрбиялəп үстергәннәр. Изгеләр зираты белән ул әле 1960 еллар башында ук кызыксына башлаган. Зираттагы ташларны әйләндереп алган тимер рәшәткәләрне 1962-1963 елларда Уфадан пароход белән алып кайтуы турында уллары Рәшит белән Мәлик сөйләгәннәрдән мәгълүм.

Изгеләр зираты янында гына челтерәп аккан чишмәләр дә гади генә түгел, сихәтле чишмәләр икән. Кайсы күз-колак авыруларына, кайсы кул-аяк сызлауларына дәва, диделәр. Чишмәләр барысы да матур итеп корылып алынган, авыл халкы аларны караπ-чистартып тора. Халык арасында өч чишмә турында да риваятьләр сакланган.

Изгеләр чишмәсе

Әлек бу урында Бичерхан дигән бик зур кирмән-кала булган. Бик тырыш, уңган халык яшәгән анда: иген иккән, күн эшкәрткән, чүлмәк ясаган. Бервакыт Бичерханга басурманнар һөҗүм иткәннәр. Халык, Зөлхи ата җитәкчелегендә, диннәрен саклап шәһит киткән. Шәһәрне саклап һәләк булганнарны хөрмәтләп күмгәннәр. Алар арасында Зөлхи атаның кызлары Шаһидәбану, Сәгыйдәбану, Заһидәбану да булган. Алар күмелгән урында бәреп чыккан чишмәне «Изгеләр чишмәсе» дип атый башлаганнар.

Акчишмә

Нырсы белән Бичер авыллары арасында булганга, бу чишмәне халыкта «Бичер чишмәсе» дип тә йөриләр. Акчишмә тирәсендә элек Ак күл дә булган дип сөйлиләр. Акчишмәнең суы башка чишмәләрнеке белән чагыштырганда аграк. Элек монда тегермән булган, ул ике авылга игелекле хезмәт күрсәткән. Хатыны үлеп, бердәнбер малае читкә чыгып киткәч, тегермәнче бабай тегермәндә берүзе яшәгән. Кышкы салкында ул шунда ялгызы туңып үлгән. Аннан соң инде бу тегермән дә җимерелгән.

Озак еллардан соң олыгайган бер ят кешенең тегермәнче кабере янында елап утыруын, Акчишмә тирәсендә йөрүен күрәләр. Бу – тегермәнченең улы була. Ул Акчишмәнең тирәягын чистартып, шунда таралып яткан ак ташлар белән чишмәне әйләндереп ала, як-якка да ак ташлар җәя.

Гайсә чишмәсе

Борын заманда Карабаян белән Нырсы арасында аккан чишмә янында ике авыл яшьләре Кичке уенга чыга торган булганнар. Нырсы егете Гайсә белән Карабаян авылы кызы Бану нәкъ менә шунда очрашып, бербересенә гашыйк булганнар.

Шулвакытта Карабаян авылында бик зур фаҗига булган, авыл халкын көчләп чукындыра башлаганнар. Бануның әтисе, кызым булса дә үз динебездә калсын, дип, Бануны тизрәк Нырсыга кияүгә бирергә ашыккан.

Ул вакытта Карабаянда бик зур базар булган. Базар көнне Гайсә Бануның кулын сорарга киткән. Бәхетсезлегенә, юлында Карабаян көмешкәчеләре очрап, аны да эчерткәннәр. Кайтыр юлда Гайсә ат арбасында йоклап киткән. Чишмә турысында, сазлыклы җирдә йөгәнсез ат кисәк борылып, арбасын аударган, Гайсә арба астында калып, томаланып үлгән. Сөйгәнен югалтудан җаны бәргәләнгән Бану көн дә чишмә буена килеп, Гайсәне сагынып елый торган булган. Шуннан бирле бу чишмәне «Гайсә чишмәсе» дип йөртәләр.

Дөнья өзгән безнең лә араны...

«Түгәрәк уен» журналының 2015 елның 3 нче санында ялкынлы педагог, язучы, галим, фольклорчы Әхмәтфазыл Әхмәткәрим улы Туйкинның «Җырлар әхтәрисе» дигән җыентыгында дөнья күргән халык җырларының бер өлешен укучыга җиткергән идек. Бүген без сезгә әлеге талантлы шәхесебезнең үзе иҗат иткән шигырьләре басылган «Нардуган» исемле китабыннан берничә үрнәк тәкъдим итәбез.

«Нардуган» – Фазыл Туйкинның безгә мәгълүм булган бердәнбер шигырь китабы. Ул Уфада, 1915 елда, бертуган Кәримовларның «Шәрекъ матбагасы» нәшриятендә басылып чыга. 24 биттән торган бу китапка 16 шигырь кертелгән. Аларның эпиграфлары барысы да көй исемендәге халык җырларыннан алынган.

«Урал тавына» дигән шигырьнең ахырына «К. Т.» дигән тамга куелганлыктан, бу шигырьне Ф. Туйкинның бертуган абыйсы Кәбир Туйкинныкы дип фаразлый алабыз. Бәлки шуңа күрә дә китапның тышлыгына «Туйкин» дип фамилияләре генә язылгандыр да...

Китапның төзелешен, ягъни шигырьләрнең тәртибен, шигырь юлларының бирелү формасын, кайбер сүзләрнең ул вакыттагы әйтелешен, мәсәлән: «Ак Идел» («Агыйдел»), «Башмак» көенә («Башмагым»), «Тәфкилеф» көенә («Тәфтиләү»), «Алтын сач» көенә («Алтынчәч») һ.б.ларны автор язганча калдыруны дөресрәк булыр дип санадым. Беренчедән, алар безгә яхшы аңлашыла, икенчедән, мондый сүзләрнең борынгырак әйтелешен белү, күңелебездә яңарту – үткәнебезгә һәм мөхтәрәм язучыларыбызга ихтирам кебек тә тоела. Ә менә кайсы җәягә алынган, кайсы алынмаган шигырь исемнәрен, шул шигырьләргә тәкъдим ителгән, шулай ук төрлесе төрлечә бирелгән көйләрне, ягъни китапның мөхәррире күреп бетермәгән урыннарын, бер стильгә кучерүне кирәк дип таптым.

Фазыл да, Кәбир Туйкин да халык өчен бихисап күп эшләгән, әмма икесе дә нахакка рәнҗетелгән шәхес культы корбаннары. Алар, архивларда сакланган кайбер хатларыннан күренгәнчә, гомерләренең соңгы 20 елында (Ф.Туйкинның 1925 елда дөнья күргән, балалар өчен язган 12 битлек «Салих бабай» хикәясен исәпкә алмаганда) язганнарын, җыйган фольклор үрнәкләрен, гербарий, төзегән дәреслек һәм башка хезмәтләрен халыкка, укучыга җиткерә алмый газапланалар. Шул сәбәпле, бик күп иҗат эшләре югала да.

Кадерле укучым! Әби-бабаларыгызның шәхси китапханәләрендә, сез белгән укымышлыларның архивларында ханбикәбезгә багышланган «Сөембикә»; сәнәкчеләр тарафыннан вәхшиләрчә әзәрлекләнгән укытучылар хакындагы «Мәгариф корбаннары» (бу пьесаның икенче исеме «Соңгы каракош» дип аталуы, авторларының да башка фамилиядә булуы ихтимал), авыл байлары турында язылган «Мусабай» исемле сәхнә әсәрләре очраса, «Түгәрәк уен» журналы редакциясенә хәбәр итүегезне үтенәбез. Бу пьесалар сәхнәләрдә бер яки берничә тапкыр уйналган. Аларның язылып тәмамлануы хакында да матбугатта мәгълүматлар бар, якташлары күңелендә дә хатирә-истәлекләр саклана. Әмма, ни кызганыч, әдәби мирасыбызның Туйкиннар калдырган байлыгы бүгенгә кадәр тулысынча табылмаган. Билгеле, Туйкиннарның югалган хезмәтләре алар гына да түгел. Абыйлы-энеле Кәбир һәм Фазыл Туйкиннар тарафыннан өч китап итеп язылган, зур тарихи кыйммәткә ия булган «Төрек тарихы»ның да икенче һәм өченче кисәкләре юк.

Гомумән, халкыбызның тарихына, язма мирасына битараф булмаган укучыларыбыз, нинди генә кулъязма, дәфтәр, китап итеп төпләнгән чыганаклар кулыгызга килеп керсә дә югалтмасагыз, редакция белән элемтәгә керсәгез иде!

Ихтирам белән, «Нардуган» китабын гарәп графикасыннан гамәлдәге язуга күчерүче һәм бу кечкенә генә мәкалә-мөрәҗәгатьнең авторы: язучы, шагыйрә Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА.

Сабанчы карт

(«Башмак» көенә)
Башмагымның башы башка,
Басмас идем, һай, вак ташка,
Алданамын башым яшькә,
Бирче, зинһар, башмагымны.

Җырлыйм әле сузып-сузып,
Моңлы көйләр белән өзеп,
Һай! Гомерем китте узып,
Яшь чагында уйламыйча.
Карт булсам да мин, һаман да
Җырлап җибәрәм сабанда,
Түзми күңелем бу заманда
Җырламыйча, моңланмыйча.
Искә төшә әллә ниләр,
Минем хәлемне белмиләр,
«Әнә җырлый җүләр», – диләр,
Тик әйтәләр уйламыйча.
Яшь чакларда белмибез дә,
Юк, белерсез әле сез дә,
Дөнья басса тезегезгә,
Түзалмассыз җырламыйча.
Әле сезгә бар да яхшы,
Дөнья йөзе дә бик якты,
Юк, ул менә шулай таптый,
Азып йөрсәң, уйламыйча.
Мин дә шулай йөргән идем,
Сез күргәнне күргән идем,
Әллә ниләр белгән идем,
Түзмим инде җырламыйча.

Ямьле җәй

(«Зиләйлүк» көенә)
Биек кенә тауның итәгендә
Утыртып үстергән талым бар.
Кеше ярларында ни гамем бар,
Зиләйлүк,
Сандугачтин артык ярым бар.

Идел буйларында киң болында,
Елкыларым утлый чабында.
Оҗмахларың торсын бер ягымда,
Шул болында йөргән чагымда.
Шунда инде менә төрле кошлар
Өзеп-өзеп кенә сайрыйлар.
Су өстендә йөзгән аккошлар да
Моңлы тавыш белән шаулыйлар.
Гөрләп кенә торган калын әрәмәдә
Пешеп килә төрле җимешләр,
Аллы-гөлле үскән чәчәкләрдән
Аңкып тора тәмле хуш исләр.
Аргы башта, шунда бер тугайда
Тезелеп кенә печән чабалар.
Чаба торгач, алар туктыйлар да
Моңландырып чалгы яныйлар.
Шунда берсе моңлы тавыш берлән
Җырлый башлый менә өздереп.
Башкалар да бергә кушыла да,
Җибәрәләр өзеп, сыздырып.
Менә шунда хозур, әй, күңелле,
Югаласың, чынлап, үзеңнән.
Искә төшсә шунда ямьле җәйләр,
Татлы яшьләр ага күземнән.

Урал тавына

(«Ишан» көенә)
Ишан углы булып тудым,
Шуның өчен иркә булдым.
Атам ишан хәзрәтдин
Туган өчен рисвай булдым.

Урал тавы синең буең,
Ак Идел һәм Уфа суың
Бар да ямьле, бар да шанлы,
Шунда гизә минем уем.
Шунда тудык, шунда үстек,
Җәен җәйләүләргә күчтек,
Карлыгачтай куанышып,
Чагыл җирдә урман кистек.*
Умарта һәм куй үрчеттек,
Болыннарда җылкы көттек,
Кымыз савып бал ачыттык,
Кунак килсә, якын иттек.
Ул чакта без тик тормадык,
Сине мактап күп җырладык.
Моңлы көйгә курай уйнап,
Туй-тамашаны зурладык.
Бездән читләр көнләштеләр,
Синең берлән серләштеләр,
Бездән битәр юлдаш булып,
Ян-яныңа җирләштеләр.
Тавың-ташың җимерделәр,
«Менә чыга тимер», – диләр.
«Алтын-көмеш, ак алтын», – дип,
Куанышып сикерделәр.
Инде сине җимерсеннәр,
Каның эчеп симерсеннәр,
Бездән яшерен сереңне ачтың,
Тиеш җәзаңны бирсеннәр.

К.Т.**

* Чагыл – калкулык
** Бу тамга китаптагы башка җырларда юк. «Урал тавына» дигән әлеге җырның авторы Кәбир Туйкин булырга тиеш дип уйлыйбыз.

«Алмакай»да аулак өй

Хөрмәтле «Түгәрәк уен» хезмәткәрләре! Сезнең журнал кулыбызга килеп кергәч, сөенеп укып чыктык, бик бай материал тупланганын күрдек. Әби-бабайларга да, кечкенә балалар өчен дә күп кызыклы язма бар. «Әбекәй чәе»н укыгач (2018, №1), без дә үзебезнең балалар бакчасында үткәрелә торган бәйрәмнәребез турында язарга булдык. Укып карагыз әле!

«Бәби туе»

Балаларны рухи яктан бай, иманлы, әхлаклы, халкыбызның гореф-гадәтләренә ихтирамлы шәхес итеп тәрбияләү безнең бурыч. Шуңа күрә татар халкының милли бәйрәмнәрен даими үткәреп торабыз. Көзен – «Сөмбелә», язын – «Нәүрүз», җәен – «Сабантуй»ны балалар да, ата-аналар да көтеп ала. Балалар һәм ата-аналар белән уртак бәйрәмнәр, чаралар үткәрү гаилә һәм балалар бакчасы, тәрбиячеләр арасындагы бәйләнешне ныгыта.

Хәзерге вакытта көн кадагына суга торган мәсьәлә ул – ана телебезне саклап калу. Шуны күз алдында тотып, без, татар төркемендә эшләүче тәрбиячеләр, балаларда туган телгә мәхәббәт уяту өчен ата-аналар белән төрле эш алымнары кулланабыз. Безнең төркемгә йөрүче барлык балаларның да әти-әниләре татарлар. Шуңа күрә ана телен онытмыйча, көндәлек тормышта кулланырлык итеп бергәләп өйрәтүне, ныгытуны бурыч итеп куйдык.

Күптән түгел төркемебездә «Бәби туе» үткәрдек. Бәйрәмебезгә әбиләрне, әниләрне дә кунакка чакырдык. Кызлар – бәби итәкле алъяпкычлар киеп, ап-ак яулыклар бәйләп, малайлар – түбәтәй киеп килгәннәр иде бу көнне бакчага. Бәйрәмдә балалар бәбине котлап, теләкләр теләделәр, юаткыч шигырьләр дә сөйләделәр. Ә бишек җырларына әниләр, әбиләр дә кушылып җырлады. Алар үзләренең бала тибрәткән чакларын искә төшерделәр. «Бәби»не йоклаткач, бергәләшеп «Түбәтәй» уенын уйнадык. «Җәза» үтәгәндә тизәйткечләр, санамышлар, мәкаль, табышмаклар әйтештек. Бәби туена килгән Зөләйха әби «Тукмак әйләндерү» уенын оештырды. Анда кызыклы мәзәк сөйләү, үртәвечләр әйтү дә булды. «Челтәр элдем читәнгә» җырын җырлаганда, Аделия исемле кызның әнисе матур итеп баянда уйнады. Кунакка килгән Асия әбиебез балаларга файдалы киңәшләрен бирде: «Кадерле балалар! Һәрвакыт менә шулай акыллы, тәүфыйклы булыгыз, әти-әниләрегезнең сүзен тыңлагыз! Бәбиләр туып, бәйрәмнәр булып торсын. Балаларыбызны, оныкларыбызны милли рухта тәрбиялик, милли йолаларыбызны онытмыйк!» – диде ул.

Ә соңыннан барлык кунаклар «Бәби чәе» белән сыйландылар, «Иң тәмле милли ризык» күргәзмәсенә алып килгән ризыклардан авыз иттеләр.

«Мин бит — татар малае!»

«Татар малае», «Татар кызы» диган бик матур конкурс шәһәребездә еш уздырыла. Балалар бакчаларында тәрбияләнүчеләр бу конкурска югары дәрәҗәдәге әзерлек белән киләләр.

Бу конкурста безнең 118нче «Алмакай» балалар бакчасыннан Кәрим Нәсифуллин катнашып, үзенең чын татар малае булуын раслады. Ул дуслары белән кыска гына спектакль күрсәтте. Шәһәрдән кайткан Кәрим авыл кызларын үзенең саф ана телендә сөйләшүе, җырлавы белән таң калдырды. Коега су алырга килгән кызлар, Кәримнең дус малайлары кыска әкиятләр сөйләп, такмак, сынамыш, санамыш, мәкаль, табышмаклар әйтеп күрсәттеләр. Кәрим матур җырлавы белән дә һәркемне сокландырды. Коеның серле, изге суы аша Сөембикә-ханбикә пәйда булып, татар халкы, милләт балалары, туган теле белән горурлануын белдерде. «Туган телем – татар теле, гасырлардан гасырларга тапшырылып та, үз моңын, үз аһәңен югалтмаган. Шушындый бай әчтәлекле, матур бәйрәмнәр, бәйгеләр аша үзенең мәңге яшәвен күрсәтә. Киләчәктә туган телем тагын да үсәр, чәчәк атар әле минем», – диде ул тамашачыларга. Кәримебезнең, аның чыгышында катнашкан балаларның сәләтен жюри уңай бәяләде, тиешле бәя бирде. Ул «Иң матур сәхнә образын күрсәтүче» диган исемгә лаек булды.

Әкиятне үзебез язабыз

Төркемебездәге балаларның иҗади сәләтләрен үстерү максатыннан, «Без – театр артистлары» дигән матур кичә үткәрдек. Абдулла Алишның «Куян кызы» әкиятен үзгәртеп яздык һәм сәхнәләштердек. Балалар бик күңелле чыгыш ясадылар, иң мөһиме – куян кызын итекләрен салмаска күндерделәр! Соңыннан, театр хезмәткәрләре – режиссер, артист, костюм тегүче, рәссам, музыкантлар турында сөйләштек. Әкият барысына да ошады, хәтта китап булып та «басылып чыкты». Моңа чаклы инде безнең «Шалкан», «Теремкәй», «Өч аю», Габдулла Тукай шигырьләре буенча кыска спектакльләр куйганыбыз бар иде.

«Аулак өй»гә җыелдык

Аулак өйләрне көз көне кыр эшләре тәмамлангач, кыш айларына кергәндә үткәргәннәр. Ул – кызларның уңганлыкларын күрсәтү урыны да, күңел ачу чарасы да булган.

Безнең бакчадагы бәйрәмдә дә кызлар чигү чигеп, җеп эрләп, бәйләп, үзләренең һөнәрләрен күрсәттеләр. Ә инде көтмәгәндә әби кайтып кергәч, «аулак өй»гә килүчеләр югалып калганнар иде. Юкка борчылганнар икән, әби аларга үзләре яшь чакта уйнаган күңелле уеннарны өйрәтте, хатирәләрен яңартып сөйләде. Егетләрне дә кунакка чакырдылар. «Йөзек салыш», «Миңлебай», «Орчык тәгәрәтү» уеннарын бик кызыксынып уйнадылар. Җырлы-биюле «Зәңгәр чәчәк», «Чума үрдәк, чума каз», «Талы-талы» уеннары, малайлар-кызларның кара-каршы әйтешеп, такмаклар җырлаулары килгән кунакларга да ошады. Әти-әниләр, әбиләр үзләре дә кушылып уйнадылар, җырладылар, бергәләп күңел ачтылар.

Эш сөючән, тырыш татар халкына хөрмәт хисләре тәрбияләү өчен дә уңышлы фольклор бәйрәме булды бу. Бәйрәм чәй өстәле артында дәвам итте.

Яр Чаллы шәһәренең 118нче «Алмакай» балалар бакчасы тәрбиячеләре
Гөлфания НИКИТИНА, Асия ХУҖИНА, Алия КАДЫЙРОВА, Ләйсән ӘХМӘТҖАНОВА

Теләче бәбиләренә театр

Бүгенге интернет заманында китап укучылар кими дип борчылсак та, без Теләче балалар китапханәсенә балаларның бик теләп йөрүенә сөенәбез. Узган ел безнең Теләче районы балалар китапханәсенә 781 укучы килеп, алар 16 меңнән артык китап һәм башка басмалар алып торган. Китап укучылар бездә вакытлы матбугат белән дә танышып бара, аларга ике дистәдән артык газет-журнал тәкъдим итәбез. Фондта бүгенге көндә унбер меңнән артык китап-журнал, электрон һәм аудиовизуаль әсбап исәпләнә. Китапханәдә балаларга китап укырга гына түгел, уйнарга, рәсем ясарга, иҗат белән шөгыльләнергә дә мөмкинлекләр бар.

Балаларны могҗизалы китап иленә тарту өчен әледән-әле яңа алымнар уйлап табарга тырышабыз. Шундый кызыклы чараларыбызның берсе – район балалар китапханәсенә кунакка бәбиләрне дәштек. Өч яшькә кадәрле балалар өчен безнең китапханәдә эшләп килүче «Гөрләвек» курчак театры «Бәби театр» дигән кичә әзерләгән иде. Быел Татарстанда Лев Толстой елы булуын истә тотып, балалар өчен бу язучының «Өч аю» исемле әсәрен сәхнәләштердек.

2005 нче елдан бирле уңышлы гына эшләп килүче «Гөрләвек» курчак театры клубына ун бала йөри. Аларның күбесе Теләче урта мәктәбенең башлангыч сыйныф укучылары. «Өч аю» күренешендә дә аларның дүртесе – Азалия һәм Зәринә Харисовалар, Камилә Мөхәммәтшина, Мәрьям Галәвиева катнашты. Шунысы игътибарга лаек, клубка йөрүче балалар курчак театры өчен декорацияләрне үзләре әзерли, курчакларны да үз куллары белән тегәләр. Булган материалларны өйдән алып киләбез, шулардан курчак театры өчен кирәкле әйберләрне ясыйбыз. Безгә йөрүче балалар бик булганнар, алар тегә, чигә, җырлый, бии, артистлык осталыгын да үзләштерәләр. Атнага бер тапкыр җыелабыз, рәхәтләнеп аралашабыз, көлешәбез. Елга ике тапкыр яңа спектакль әзерләп Теләченең балалар бакчаларында күрсәтәбез.

«Өч аю» әкиятен кечкенә балалар бик кызыксынып игътибар белән күзәтеп утырды. Сабыйлар курчаклар уйнаганына карап куанса, әниләре үзара аралашты. Районда яслегәчә яшьтәге балалар өчен күңел ачу урыннары юк дәрәҗәсендә, шуңа да клубның эшчәнлеге дәвамлы булсын, курчак театрына йөрүче балаларыбызга иҗади уңышлар телим!

Любовь Михаил кызы ЗАКИРОВА,
«Гөрләвек» курчак театры клубы эшчәнлеген алып баручы,
Теләче балалар китапханәсе мөдире

Сөйкемле Шүрәле кайда яши?

Ул авылның, – һич онытмыйм, – һәр ягы урман иде,
Ул болын, яшел үләннәр хәтфәдән юрган иде.

Тукай, 1907 елда, бала чагының бер өлеше узган Арча районындагы Кырлай авылын менә шулай тасвирлап язган. Кырлай авылында Тукайның иң җылы хатирәләре сакланып кала, ул монда чын гаилә җылысын тоя. Әле хәзер дә күпкә үзгәрмәгән Кырлай авылы. Һаман шулай «рәт-рәт тора, гаскәр кеби, чыршы, нарат». Өчиледән ятим Тукайны үзенә алып кайткан Сәгъди абый йорты да, кечкенә Апуш уйнап йөргән бакча да шул килеш тора. Шүрәлеләрме?! Бүген дә бар алар монда! Г. Тукай исемендәге Дәүләт әдәби-мемориаль музей комплексында шүрәлеләр дә, Тукай әсәрләрендәге башка кызыклы геройлар да урын алган! Алар барысы да «Сөйкемле Шүрәле» IX Халыкара иҗади эшләр конкурсына килгән кул эшләрендә гәүдәләнгән геройлар.

Татарстан һәм Россиянең башка төбәкләрендә яшәүче мәктәп укучылары бу эшләрне укытучылары, әти-әниләре белән бергәләп тудырган. Конкурска барлыгы 340 эш кабул ителгән, иң-иңнәре өченче турга узып җиңүче итеп сайланган. Быел «Сөйкемле Шүрәле» конкурсында Башкортостан республикасыннан, Ульян, Мәскәү, Волгоград өлкәсе Волжский шәһәреннән килгән эшләр дә урын алган. Тукай әсәрләрен кайда да яратып укыйлар һәм беләләр!

Музей юлындагы агачлар арасыннан капчык тотып килеп чыккан Кәҗә белән Сарык оештырган квест та Тукай иҗатына багышланган иде. . Балаларны Су анасы да сынап карады, озын бармаклы шаян Шүрәле дә белемнәрен тикшерде. Ә аннары рәсем ясау һәм керамика буенча иҗади мастер-класс узды.

«Сөйкемле Шүрәле» конкурсының йомгаклау өлешен нәкъ Кырлай авылында уздыру үзенә күрә матур бер гадәт. Иҗатка гашыйк балаларның Тукай рухын тоеп, Шүрәлеләр яшәгән урманнарны күреп китүе дә бит әле ул!

Зәбәрҗәт.

Нурлатча тутырган тавык

Татар халкының бик күп милли ризыгы белән мин киявгә чыккач кына таныштым. Ә кияүгә мин – Нурлат ягы егетенә чыктым. Нурлат халкында милли сый-нигъмәтләр байтак: зиннәтле тутырма дисеңме, авызда эреп торган дөге бәлешеме, тәмле калын җаймәме. Минем өчен бар да яңа, үзгә, тансык иделәр. Ә шулай да, иң еш әзерләнеп, үз кадерен белеп кенә, өстәлнең түренә узучы ризык – тутырган тавык булды. Аның тарихын һәм пешерү серләрен иремнең әнисе, минем әнкәй – Фәридә Садыйковадан белештем.

Әнкәй – Нурлат районы Бикүле авылы кызы. Гаиләдә 13 нче бала. Һәм, игътибар, иң кечкенәсе ул түгел! Пешекче белеме бар. Үз авылы егетенә кияүгә чыгып, 3 бала үстереп, Аллага шөкер, матур үрнәк тормыш алып бара. «Һәй, кайсы авылда юк инде мондый хатын!» – диярсез сез! Ә мин сезгә: «Юк!» – диярмен. Чөнки ул гади йорт хуҗабикәсе генә түгел. Төп Йорт – Төп Нигез хуҗабикәсе. Бу зур статусны аклау – көн дә, төн дә, күп санлы кунакларны каршы алырга әзер тора белү дигән сүз. Әзер генә дә түгел, аларны һәрчак татарның зиннәтле сыйлары белән каршы алу һәм озату. Ассызыклап әйтәм, бер-ике кунакны гына түгел, берьюлы егермене-утызны...

Тутырган тавык турындагы беренче хатирәләрен сораштым. «Балачакта тутырган тавыкның сирәк һәм бик зур вакыйгалар нисбәтеннән генә әзерләнгәне хәтеремдә. Гадәттә аны елга берничә тапкыр гына ясый идек, бәлки 3-4 туры килгәндер. Берсе җәй көне Үзбәкстаннан әтинең туганнары кунакка кайткач. Без аларны тутырган тавык белән сыйласак, алар безне пылау пешереп гаҗәпләндерә иде. Шулай ук көтүгә чыккан көнне дә, һичшиксез мунча ягылып, тутырган тавык ясалганы истә калган. Ник шулай сирәк дисәгез, без үскәндә йомырка салучы тавыкны сую бик кызганыч хәл, малны әрәм итү санала иде. Хәзер рәхәт, махсус бройлер-тавыклар үстереп була, тутырган тавык табыннан төшми диярлек», – ди әнкәй.

Сүз уңаеннан, тутырган тавык – чын авыл табыгыннан күпкә тәмлерәк чыга, билгеле. Ләкин, авыл тавыгының бер тискәре ягы бар – фотога төшәргә яратмый ул. Тиресе ефәктәй юка – кагылдың исә ертылырга тора. Фотосурәт ясыйбыз дип кенә, шәһәрнекен алмадык инде, кул бармады. Тавыгы да үзебезнеке – газиз Нурлатныкы, туган авыл Бикүле һавасын сулап, Бикүле суын эчеп, әнкәй биргән җимне ашап үскәне булсын дидек.

Кирәк була:

1. Бер тавык түшкәсе
2. 20-25 йомырка
3. 500 мл авыл каймагы
4. Тоз

Эш барышы:

1. Тавыкның астын кисеп, эчен чистарткан-
нан соң, әйбәтләп юып, суын саркытабыз. Аскы өлешен махсус җеп белән ямап тегәбез.

2. Тавыкның тиресен тәненнән аерып, төрле җирләрендә куышлыклар ясап чыгабыз. (Тире ертылмасын өчен бик төгәл эш итәргә кирәк.)

3. Тавыкны тутыру өчен катнашма әзерлибез. Йомырка һәм авыл каймагын, тәменчә тоз өстәп, әйбәтләп туглыйбыз.

4. Катнашманың бер өлешен тавыкның муен тиресеннән эченә тутырабыз (муены алдан алынган була), икенче бер өлешен, махсус шприц белән, төрле урыннардан тире астына җибәрәбез. Муенын җеп белән бәйлибез. Ә тиредәге тишеккә тимибез. Суга салгач ул үзе куырылып килә.

5. Шаулап кайнап торган суга салып, башта 1,5 сәгать тавыкның бер ягын, аннары тагын 1,5 сәгать икенче ягын кайнатабыз.

6. Әзер тутырган тавыкны матур итеп кисәкләргә бүлеп, пешкән бәрәңге белән бизәп, табынның түренә куябыз. Тутырган тавык кайнап чыккан шулпага исә кулдан киселгән токмачы салып, аш итеп бирәбез.

Энҗе САДЫЙКОВА,
Казан

Нурлатча тутырылган тавыкны
әзерләүче аш-су остасы
Фәридә Садыйкова

Гаилә бәйрәмнәренә әзерләнгән табынның иң түренә затлы ризык булып токмач ашы белән бергә тутырган тавык чыгарыла. Бу күркәм гадәт безгә әби-бабайлардан калган. Элекке вакытларда авылларда өмә белән өй күтәргәндә хуҗаларга киндер тастымалга төреп ипи һәм тутырган тавык алып килә торган булганнар.

Сатуда бәя ирекле

ИНДЕКСЫБЫЗ– 16987

Илнар Хәнипов фотосы.

Арышлар серкә очыра, –
Кыр өсте яшькелт рәшә.
Тын гына,
Тибрәлеп кенә
Җир белән Күк сөйләшә...